МУНИЦИПАЛЬНОЕ АВТОНОМНОЕ ДОШКОЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ «ЦЕНТР РАЗВИТИЯ РЕБЕНКА – ДЕТСКИЙ САД № 83 «ФЕЯ»
423832, Республика Татарстан, город Набережные Челны, Бульвар Касимова, д. 7

ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ АВТОНОМИЯЛЕ МӘКТӘПКӘЧӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ «ТЫЛСЫМЧЫ КЫЗ» 83 НЧЕ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ – БАЛАНЫ ҮСТЕРҮ ҮЗӘГЕ»
423832, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Касимов урамы, 7 йорт

Телефон/факс +7 (8552)-34-91-71, +7 (8552)-34-68-05, e-mail: sad083@inbox.ru

«СОГЛАСОВАНО»
Ст. медсестра _____ Шайхиева С.Ф.

«24» *августа* 2022г.
Ст. воспитатель ____Шляхтина Ю.А.
«____» ____________ 2022г.

Введено в действие
приказом заведующего
от 24.08.2022 № 456

«УТВЕРЖДАЮ»
Заведующий МАДОУ
«Центр развития ребенка – детский сад №83 «Фея»
____________ Юлчурина Ю.В.
«24» *августа* 2022г .

Рассмотрено и утверждено
на педагогическом совете
от 24.08.2022
Протокол № 1

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

## Өлкән төркем (5 яшьтән 6 яшькә кадәр) №3

## 2022/2023 уку елы өчен

**Тәрбияче :**

**Мухаметова Р.Ф.**

**Сакаева Г.Р.**

**ш. Яр Челны, 2022 г.**

# Эчтәлек

**Кереш**.


1. **Максатчан бүлек.**

1.1.Аңлатмалы язу.

1.1.1. Программаны тормышка ашыру максаты һәм бурычлары

1.1.2. 5-6 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре

1.1.3. Зурлар төркемендә эшчәнлегенең төп юнәлеше

1.1.4. Программаның принциплары

1.2. Максатчан юнәлешләр

2. **Эчтәлек бүлеге**

2.1.Белем бирү эшчәнлегенең эчтәлеге

2.1.1.Социаль-коммуникатив өлкәсе

2.1.2.Танып белү өлкәсе

2.1.3.Сөйләм үстерү өлкәсе

2.1.4.Нәфасәти өлкәсе

2.1.5.Физик өлкәсе

2.2. Гаилә белән үзара аралашу

3. **Оештыру бүлеге.**

3.1.Зурлар төркемендә көндәлек режим

3.2.Үстерешле предметлы тирәлекнең үзенчәлекләре

3.3.Материаль-техник һәм методик кулланма

3.4. Көндәлек режим

3.5. Турыдан- туры белем бирү эшчәнлегенең расписаниесе

3.6. Традицион вакыйгалар, бәйрәмнәр, чаралар

**Кереш.**

– Федеральный закон от 29.12.2012 № 273-ФЗ «Об образовании в Российской Федерации» (с изменениями от 14.07.2022г.).

– Федеральный закон от 03.08.2018 г. №317 –ФЗ «О внесении изменений в статьи 11 и 14 Федеральный закон «Об образовании в Российской Федерации».

– Федеральный государственный образовательный стандарт дошкольного образования (Утвержден приказом Министерства образования и науки Российской Федерации от 17 октября 2013 г. N 1155).

– Комментарии к ФГОС дошкольного образования Минобрнауки России Департамента общего образования от 28 февраля 2014 года № 08-249.

– Приказ Министерства просвещения РФ от 31 июля 2020 г. № 373 «Об утверждении Порядка организации и осуществления образовательной деятельности по основным общеобразовательным программам – образовательным программам дошкольного образования».

– Постановление Правительства РФ от 15 сентября 2020г. №1441 «Об утверждении Правил оказания платных образовательных услуг».

– СП 2.4.3648 – 20 «Санитарно – эпидемиологические требования к организациям воспитания и обучения, отдыха и оздоровления детей и молодежи», утвержденный Постановлением Главного государственного санитарного врача Российской Федерации от 28.09.2020 №28 об утверждении санитарных правил. Зарегистрирован в Министерстве юстиции РФ от 18.12.2020 №61573.

– Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 28.01.2021 №2 «Об утверждении санитарных правил и норм СанПиН 1.2.3685-21 «Гигиенические нормативы и требования к обеспечению безопасности и (или)безвредности для человека факторов среды, обитания» (вместе с СанПиН 1.2.3685-21 «Санитарные правила и нормы..»).

– Постановление Главного государственного санитарного врача РФ от 27.10.2020 г. №32 «Об утверждении санитарно-эпидемиологических правил и норм СанПиН 2.3/2.4.3590-20» Санитарно-эпидиомологические требования к организации общественного питания населения.

– Санитарно-эпидемиологические правила СП 3.1/2.4.3598-20 «Санитарно-эпидемиологические требования к устройству, содержанию и организации работы образовательных организаций и других объектов социально инфраструктуры для детей и молодежи в условиях распространения новой коронавирусной инфекции (COVID-19)», утвержденный постановлением Главного государственного санитарного врача РФ от 30.06.2020 №16, с изменениями от 24.03.2021 г. (Постановление Главного государственного санитарного врача РФ №10 «О внесение изменений).

– Закон Республики Татарстан «Об образовании» от 22.07.2013г № 68-ЗРТ (принят Государственным Советом 28.06.2013 г).

– Закон Республики Татарстан «О государственных языках Республики Татарстан и других Языках в Республики Татарстан» (изменения и дополнения от 28.07.2004 г № 44-ЗРТ; от 12.06.2014 г № 53-ЗРТ).

– Устав ДОУ;

– Основная образовательная программа ДОУ;

– Рабочая программа воспитания ДОУ

## 1. Максатчан бүлек.

### 1.1. Аңлатмалы язу.

Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы (алга табаПрограмма) «Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт таләпләре»нә (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.11.2009 елда 655 нче карарынигезендә расланган) нигезләнеп төзелде.Программада 3 яшьтән 7 яшькә кадәр булган балаларга төбәкнең климатик, милли-мәдәни, демографик, социаль-экономик шартларын исәпкә алып, белем бирү процессында катнашучылар тарафыннан формалаштырыла торган белем бирү эчтәлеге чагылдырыла.

Программа нигезендә мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөстәкыйль рәвештә мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасының вариатив өлешен эшли, раслый һәм тормыш-
ка ашыра; шуның белән балаларның физик, социаль һәм акыл үсеше хокукларын (Бала хокуклары турындагы Конвенция,1989), барлык балалар өчен мәктәпкәчә баскычтан башлан-
гыч мәктәпнең беренче сыйныфына укырга күчкәндә тигезмөмкинлекләрен тәэмин итә.
Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, мәктәпкәчә белем бирү өлкәсен-дә әйдәп баручы белгечләр хезмәтләрендә (Л. С. Высотский,П. Я. Гальперин, В. В. Давыдов, А. В. Запорожец, А. Н. Леонтьев,С. Л. Рубенштейн һ. б.) чагылыш тапкан фәнни тикшеренүләргә,гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчәмәгариф системасы эшчәнлеген көйләп торучы башканорматив-хокукый актлар положениеләренә нигезләнә.
Программа мәктәпкәчә яшьтәге балалар үсеше проблемасына мәдәни-тарихи якын килүгә туры китереп эшләнде,анда фәнни нигезләнү һәм гамәли кулланыш принциплары
берләштерелде. Программаны гамәлгә ашыру белем бирү процессын төзүнең комплекслы тематик принцибына, мәктәпкәчә 92 *Р. К. Шәехова* белем бирүнең бөтенлек һәм интеграция принципларына нигезләнде, балаларның яшьләренә туры килгән эш формаларын һәм эшчәнлек төрләрен исәпкә алып төзелде.
Программа белем бирү процессын эшкә ашыруны өлкәннәр һәм балаларның уртак эшчәнлеген, балаларның мөстәкыйль эшчәнлеген үз эченә алган ике төп оештыручы модель
ярдәмендә тәэмин итә; 5 яшьтән 6 яшькә кадәр булган балаларга белем биргәндә яшь үзенчәлекләренә тәңгәл килерлек укыту моделен күздә тота, мәктәпкәчә гомуми белем бирүнең үрнәк программалары белән бәйләнешне тәэмин итә.
Программа балада һәрьяклы (физик, шәхси, танып белү,рухи, эстетик) үсешне арттыруга юнәлтелә һәм милли культура,туган якны, туган (татар, рус) телне өйрәнү аша аның баетылуынкүздә тота.
«Милли культураны, үз халкыңның рухи байлыгын өйрәнү, аны шушы җирдә яшәгән башка халыклар культурасы белән баету, баланың культурага булган билгеләмәсе киләчәктә аңа бөтендөнья культурасын аңларга ярдәм итәчәк. Бары тик үз
халкының культурасына булган шундый киң караш, аны зуррак масштабтагы культура процесслары контекстларында кабул итү генә иҗади шәхес формалашуга һәм үсешенә нигез булып торачак, ул үз чиратында милли культураны пассив күзәтергә генә түгел, ә аңа шәхсән үз өлешен кертергә, культура барлыкка килү процессында катнашырга мөмкинлек бирәчәк» (Ф. Ф. Харисов).
Программада психилого-педагогик эшнең бурычлары дүрт юнәлеш буенча бүленеп бирелгән: физик, социаль-шәхси, танып белү-сөйләм, нәфис-нәфасәти үсеш юнәлешләре.
***«Физик үсеш» юнәлешенә*** «Сәламәтлек», «Физик культура», «Куркынычсызлык» белем бирү өлкәләре керә, аларда сәламәт яшәү рәвеше формалашуга нигез салына. Татар халык
мәдәнияте һәм зирәклеге аша гасырлар буена формалашкан барлык кыйммәтләр мәктәпкәчә мәгариф системасының бер өлеше булып тора.
***«Социаль-шәхси үсеш» юнәлеше*** эчтәлеге нигезендә баланың туган телдә өлкәннәр һәм яшьтәшләре белән һәр *Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы* 93 үсеш этабына хас булган үзенчәлекле формада аралашуы тора. Баланың аралашу һәм башка төрле эшчәнлеге традицияләрне үзләштерүгә, үзаң үсешенә нигез булып торган гражданлык хисләре башлангычына, туган иленә, туган ягына, гаиләсенә мәхәббәте формалашуга төп шарт булып тора. Бу юнәлешкә«Социальләштерү» һәм «Хезмәт» белем бирү өлкәләре керә.
***«Танып белү-сөйләм үсеше» юнәлеше*** эчтәлегендә татар(рус) теленә тирән кызыксыну, туган телдә аралашуга теләк уяту бурычы куелды. Балалар матур әдәбияты, уку-укыту методик комплекты, аудио-, видеоязмалар, мәгълүмати-аралашу технологияләре авазларның дөрес әйтелешенә, билгеле күләмдә сүзлек байлыгына, сөйләмнең сәнгатьлелегенә нигезсалырга ярдәм итәчәк.
Тарих, культура, архитектура, туган якның табигате белән танышу өлкәсендә махсус танып белү бурычлары куелды.
Милли кыйммәтләр һәм белем бирү системасы интеграциясе – мәктәпкәчә белем бирү эчтәлегенең, аның максатлары,кыйммәтләре, мәгънәви юнәлешләренең даими камилләшүе
ул. Баланың танып белү-тикшеренү эшчәнлегенең эчтәлегенә милли культура элементларын кертү югары дәрәҗәдәге милли үзаңлы һәм рухи культуралы шәхес формалашуына китерә.

Интеграция – үзмаксат түгел, ә бәлки төбәк белем бирү системасының яңа халәткә күчүгә ихтыяҗы. Бу юнәлешкә «Танып белү», «Аралашу», «Матур әдәбият уку» белем бирү
өлкәләре керә.
***«Нәфис-нәфасәти үсеш» юнәлешендә*** милли культура чаралары ярдәмендә баланың дөньяга эстетик карашы формалашуы һәм сәнгати үсеше берлектә карала. Мәктәпкәчә мәгариф системасына милли культураны кертү милли культура элементлары булган музыка, сынлы сәнгать, театр, фольклор, халык җырлары, биюләре, уеннары аша тормышка ашырыла. Бу юнәлешкә «Иҗади сәнгать», «Музыка» белем бирү өлкәләре керә. 94 *Р. К. Шәехова*
Программа мәктәпкәчә балачакның яшь үзенчәлекләренәкарап бирелгән бүлекләрдән тора.
1. Аңлатма язуы.
2. Программаны гамәлгә кертү һәм үзләштерү буенча өлкәннәр һәм балалар эшчәнлеген оештыру.
3. «Сәламәтлек», «Физик культура», «Куркынычсызлык»,«Социальләштерү», «Хезмәт», «Танып белү», «Аралашу»,«Матур әдәбият уку», «Музыка», «Иҗади сәнгать» белем
бирү өлкәләрен үзләштерү буенча психолого-педагогик эш эчтәлеге.

### 1.1.1 Программаны тормышка ашыру максаты һәм бурычлары

**Максат:** әйләнә-тирә белән танышуда нигез буларак, яшь үзенчәлеге буенча бурычлар һәм проблемаларны чишү, башка балалар һәм өлкәннәр белән актиив аралашу процессында балаларда культура тәҗрибәсе туплау, өзлексез белем алуга һәм мөстәкыйльлеккә әзерлек булдыру.
**Бурычлар:**
- милләтенең, теленең, социаль чыгышының нинди булуына карамастан, һәр балада аны яратуларына ышаныч, тормыш өчен җайлы шартлар тудыру;
- шәхси һәм яшь һәм үзенчәлеге буенча балаларның һәрьяклы үсеше өчен уңайлы шартлар тудыру;
- балада социаль-әхлакый, физик, интеллектуаль, эстетик сыйфатларүстерү;
- кеше эшчәнлегенең төп формаларында үзен-үзе ачу һәм иҗат итү сәләтен, ихтыяҗын формалаштыру, дөнья белән берлектә үзен-үзе танып белү, аның белән әңгәмә алып баруга әзерлек;
- баланың гомуми шәхси культурасын, шул исәптән сәламәт яшәү рәвешенең кыйммәтен, белем алу эшчәнлегендә алшартны, инициативасын, мөстәкыйльлеген һәм җаваплылыгын, актив тормыш позициясен формалаштыру;
- һәр баланың сәләтен һәм иҗади потенциалын үстерү;
- гуманлык кыйммәтләре һәм идеалы, иректе кешенең хокуклары нигезендәбаланың башка балалар, өлкәннәр һәм әйләнә-тирә белән үзара йогынтысын оештыру;
- балаларда Ватанга патриотик хис һәм мәхәббәт, рухи-әхлакый һәм социокультура кыйммәтләре нигезендә аның уңышлары өчен горурлану хисе тәрбияләү;
- шәхси һәм яшь үзенчәлеге, психо-физиологик үзенчәлекләр буенча социокультура мохите формалаштыру;
- гаиләнең һәм җәмгыятьнең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә гаиләнең һәм балалар бакчасының тәрбияви-сәламәтлек ресурсларын берләштерү;
- гаилә белән үзара партнерлык мөнәсәбәте урнаштыру, психологик һәм педагогик ярдәм күрсәтү, белем һәм тәрбия бирүдә ата-аналарның компетентлылыгын күтәрү;
- балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, максат, бурыч, алымнар, мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч гомумбелем бирү дәрәҗәсендә күчүчәнлекне булдыру.

### 1.1.2 5-6 яшьлек балаларның шәхси һәм яшь үзенчәлекләре

Мәктәпкәчә яшьтәге чор баланың шәхес булып формалашуында әһәмиятле роль уйный Алты-җиде яшьтәге балалар үзен һәм башкаларны белергә омтыла, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтне аңлый башлый. Аларның сүзлекләрендә инде намуслылык, кайгыртучанлык, әдәплелек кебек сүзләр күбрәк урын ала. Балалар уенындагы мөнәсәбәтләр эчтәлек һәм интонация ягыннан алган рольгә туры килүче сөйләм белән үрелеп бара. Аларның реаль мөнәсәбәтләре вакытындагы сөйләм рольдәге сөйләмнән аерыла. Балалар социаль

мөнәсәбәтләрне үзләштерә һәм олыларның төрле эшчәнлекләрендәге буйсынучанлык позициясен аңлый башлыйлар. Бер төрле рольләр аларны башкалары белән чагыштырганда күбрәк җәлеп итә.
Бу яшьтә сынлы сәнгать белән кызыксынучанлык аеруча көчәя. Алар бик еш рәсем ясый башлыйлар. Рәсемнәр эчтәлекләре ягыннан күп төрле: аларда уйлап чыгарылган ситуацияләр, тормыштан алган тәэсирләр, китапларга иллюстрацияләр чагылырга мөмкин. Рәсемнәр композиция чишелешенең оригинальлеге белән аерылырга, хәрәкәтсез, үсештәге мөнәсәбәтләрне чагылдырырга да мөмкин.
Конструкцияләү бу яшь өчен шартларны анализлый белүләре белән характерлана. Балалар агач конструктор детальләрен кулланалар һәм атыйлар. Булган материал белән корылманың детальләрен алыштыра алалар. Үрнәк төзелешне гомуми ысул белән тикшерә беләләр. Конструкцияләү эшчәнлегесхема нигезендә үзләре уйлап яки шарт буенча эшкә ашырыла.Күмәк эшчәнлек барышында конструкцияләү барлыкка килә.
Балалар берничә тапкыр бөкләп, кәгазьдән, шулай ук табигый материалдан конструкцияли алалар. Алар 2 ысулны үзләштерә: 1. Табигый материалдан сәнгати образ тудыру(бу очракта балалар табигый материалларны төрле детальләр белән тулыландырып,ербөтен образ тудыралар; 2.сәнгати образдан чыгып табигый материал табу (бу очракта бала образны тудыру өчен кирәкле табигый материал сайлый. Төсне, форма, зурлыкны. предметларның төзелешен аңлау, кабул итү формалаша.
Балаларның күзаллаулары системалаштырыла. Балалар төп төсләр һәм аларның төсмерләрен генә түгел, ә арадаш төсмерләрнең төсләрен дә, шулай ук турыпочмак, овал, өчпочмакларның формаларын да аералар. Бер дистә предметны зурлыклары буенча рәткә тезеп куя алалар.
Ләкин балалар объектның пространстводагы урынын билгеләгәндә әгәр дә объектның пространстводагы урыны туры килмәсә, авырыксынырга мөмкиннәр. Әгәр озынрак бормалы юлның башлангыч һәм соңгы нокталары арасындагы ара туры юлның башлангыч һәм соңгы нокталары арасындагы ераклыктан кыскарак булса да, балалар тарафыннан туры юл озынрак итеп кабул ителә.
Бу мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен кабул итү сәләтенең төрле ситуацияләрдә, бигрәк тә бер үк вакытта берничә капма-каршы билгеләрне истә тотарга кирәк булган очракта, аерым авырлыклар тудыруын күрсәтә.
Мәктәпкә әзерлек төркемендә образлы фикер йөртү үсеше дәвам итә. Балалар күрсәтмә планда биремне чишәргә генә түгел, хәтта объектны үзгәртергә, аның нинди эзлеклелектә бер-берсе белән бәйләнешкә керү мөмкинлеген күрсәтергә һ.б. да сәләтле. Ләкин болар бары тик балалар адекват фикерләү чараларын кулланган очракта гына дөрес булачак. Бу чаралар арасыннан күрсәтмә модельләштерү процессында туучы схемалаштырылган күзаллауларны, балаларның объект билгеләре системасы турындагы күзаллауларын чагылдыручы комплекслы күзаллаулар, шулай ук төрле объект һәм күренешләрнең үзгәрү стадиясен чагылдыручы күзаллаулар, ел фасылларының, көн белән төннең алышынуы, объектларның төрле йогынты нәтиҗәсендә зураюы һәм кечерәюе, үсеше турындагы күзаллауларны һ.б.атарга мөмкин. Моннан тыш, логик сөйләмле фикерләүнең нигезе булган гомумиләштерү сәләте камилләшә бара. Объектлар төркемнәргә үзгәрергә мөмкин булган билгеләре буенча берләштереләләр. Төркемнәрне логик берләштерү һәм тапкырлау операцияләре дә формалаша башлый.
Бу яшьтә уйлап чыгару сәләте үсү балаларга шактый оригиналь һәм эзлекле киңәйтелгән хикәяләр уйлап чыгарырга мөмкинлек бирә. Балаларның әлеге сәләте бары тик бу юнәлештә махсус эш алып барганда гына актив рәвештә үсәчәк.
Балаларның игътибар тотрыклылыгы үсә. Алар шулай ук игътибарларын кирәк юнәлешкә бора һәм башкага күчерә ала башлыйлар. Ирексез игътибардан аңлы игътибарга күчү күзәтелә.
Сөйләм, шул исәптән аның аваз ягы камилләшү дәвам итә. Балалар сызгырулы, чыңылдаулы һәм сонор авазларны дөрес әйтә башлыйлар. Шигырьләр укыганда, сюжетлы-рольле уеннар вакытында һәм көндәлек тормышта фонематик ишетү сәләте, сөйләмнең сәнгатьлелеге үсә, грамматик төзелеше камилләшә. Балалар барлык сүз төркемнәрен

кулланалар, сүз уйлап чыгару белән актив шөгыльләнәләр. Сүз байлыклары арта. Синоним белән антонимнар актив кулланышка керә.Бәйләнешле сөйләм үсә. Балалар эчтәлекне дә, рәсемнәр буенча да иң мөһим генә түгел, ә детальләрне дә кертеп сөйли ала башлыйлар.

Бу яшьнең казанышлары түбәндәгеләр белән характерлана: уен эшчәнлегендә рольләр бүлешү; уен пространствосын төзи белү; югары нәтиҗәлелеге белән аерылып торган рәсем эшчәнлегенең алга таба үсеше; конструкцияләүдә үрнәкне карап гомумиләштерә белү. Зиһенгә алу объектларның катлаулы формаларын анализлау белән характерлана; фикерләү чараларын (схемалы, комплексны күзаллаулар, циклы үзгәрешләр турында күзаллаулар) үзләштерү белән бергә фикер йөртү сәләте дә үсә, гомумиләштерү күнекмәләре, уйлап чыгару сәләте, тотрыклы игътибар, сөйләм үсә.

**Региональ компонент:**

- Закирова К.В. «Воспитание и обучение в детском саду». Программа обеспечивает организацию образовательной деятельности в татарских группах.

Задачи воспитания и обучения по НРК: знакомить детей с музыкой, живописью, литературой, искусством народов Поволжья (Россия, Татарстан, Чувашия, Башкортостан, Удмуртия, Марий Эль, Мордовия). Развивать интерес к культурному наследию народов Поволжья.

Воспитывать патриотические чувства, любовь к родному краю, Родине, к родному языку; желание разговаривать народном языке.

**- Обучение государственным языкам РТ:**

- Зарипова З.М. Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү программасы. «Идел-Пресс», 2013

- Гаффарова С. М. «Изучаем русский язык». Методическое пособие для воспитателя. Методические рекомендации, конспекты занятий, игры и упражнения, «Хәтер», 2011;

- Зарипова З.М. «Туган телдә сөйләшәбез»Методическое пособие для ДОУ

Төркемнең төп эш юнәлеше экологик тәрбия белән балаларны табигать, сәнгать, нәфасәти эшчәнлекнең төрле төрләре белән таныштыру процессында төрле юллар белән тормышка ашырыла: төркемдә һәм саф һавада иҗади танып белү, интегральләштерелгән эшчәнлекләр, музыка белеме, мөстәкыйль эшчәнлек, шәхси эш.

Максат: экологик тәрбияне хәзерге заман социумына яраклашкан шәхес итеп, һәр балага иҗади һәм гармонияле үсеш бирерлек, балалар белән ата-аналарны эстетик матурлыкка тартырлык итеп оештыру.

**Бурычлар:**

**үстерешле:**

- балаларның экологиягә, культурага, танып белүнең төрле төрләренә омтылышны үстерү;
- иҗади активлыкны стимуллаштыру;

**белем бирү бурычы**: -
балаларда табигатьнең матурлыгын чынлыкта күрә белүне, дөньяви эстетик үсешне формалаштыру;

**тәрбияви бурыч**:

- балаларда табигатьне аңлый, саклый белергә, матурлыгын күрергә мохтаҗлык, рухи сыйфатлар тәрбияләү.

**Көтелгән нәтиҗә:**

1.Балаларда дөньяви эстетик үсешне, табигатьнең матурлыгын чынбарлыкта күрә, аңлый белүне формалаштырдык.

2.Балаларның һәм ата-аналарның рухи-әхлакый һәм иҗади сәләтләренендәрәҗәсен күтәрдек.

Мәктәпкә әзерлек төркемендә Программаны тормышка ашыруның төп юнәлеше – балаларның танып белү, сөйләм, социаль-коммуникатив, сәнгати-нәфасәти, физик үсешенә шартлар тудыру. Төркемдә белем бирү процессы комплексны һәм яңа буынның парциаль программалары нигезендә башкарыла. Программаның беренче планына белем бирүнең үстерешле функциясе куела. Программа балага гуманлы-шәхси позициясендә төзелгән һәм аның һәрьяклы үсешенә, рухи һәм гомумкешелек кыйммәтләре, компетенциясе, сәләте формалашуга юнәлгән. Программада балаларга белем бирүдә

каты регламентация юк. Программада уен эшчәнлеге аерым урын алып тора,  белем һәм тәрбия бирү процессы комплексы бирелгән.
Программаның төп максаты – күчүчәнлек принципын тормышка ашыру һәм белем бирү системасы концепциясенә яраклаштырып мәктәпкәчә яшьтәге балаларга тәрбия һәм белем бирү. Әлеге программаның аермалылыгы шунда: мәктәп һәм мәктәпкәчә белем бирүнең өзлексез булуы проблеманы чынлыкта тормышка ашыра.
Программа Россия мәгариф академиясе тарафыннан тәкъдим ителгән.

**1.1.4. Программаның принциплары**

Россиянең төп бердәм мәктәпкәчә белем бирү программасының ФДББСка яраклашуы түбәндәгеләрдә күренә:

- балачакның үзенчәлеге;
- кешелекнең гомуми үсешендә мәктәпкәчә чорның уникаль булуы;
- өлкәннәр һәм балаларның гуманлы аралашуы;
- баланың шәхесен хөрмәт итү;
- балаларның спецификасын исәпкә алып, белем бирү процессын уен, танып белү, эзләнү, иҗади активлык формасында тормышка ашыру.

Программаны тормышка ашыруның төп принцибы- яшь үзенчәлегенә туры килү. Мәктәпкәчә чорда ул уен, тәҗрибәләр ясау, проектлау, коллекция туплау, әңгәмә кору, проблемалы ситуацияләрне чишү һ.б.Әлеге эш төрләре мәҗбүри эшчәнлекне таләп итми, ә бәлки Программа балалар һәм педагогларның бердәм эшчәнлеге, шулайук балаларның мөстәкыйль эшчәнлекләре аша тормышка ашырыла.

Интегральләштерү принцибы-предметлы белем бирү программасын төзүгә альтернатив. Һәр белем бирү өлкәсендәге бурычлар башка өлкәләрне тормышка ашырганда да үтәлә ала.Тәкъдим ителгән белем бирү өлкәләре шартлы, ул материалны системалы оештыру өчен бирелгән.

Проблемалы белем бирү принцибы – билгеле бер авырлыкларны җиңү өчен бурычларны үтәү, сорауларга җавап эзләү. Бала өчен проблеманың практик мәгънәсе булу бик мөһим. Проблеманы чишеп, бала дөньяның күптөрле, үзгәрүчән булуын белә.

Ситуатив принцибы – белем бирү процессында балаларның кызыксынучанлыгын исәпкә алуга юнәлгән.

### 1.2 Максатчан юнәлешләр.

Бала төрле эшчәнлектә мөстәкыйльлек күрсәтә: уен, аралашу, танып белү-эзләнү эшчәнлегендә, конструкцияләүдә һ.б.; шөгыль һәм эшчәнлектә иптәшләр сайлый. Бала үзенә, башкаларга, төрле эш төренә уңай карый ала, үзен-үзе хөрмәт итә. Яшьтәшләре, өлкәннәр белән актив аралаша, уеннарда катнаша, сөйләшә, башкаларның фикерен исәпкә ала, борчыла, шатлана. Үзенең эмоциональ халәтен тота белә, үз-үзенә ышана, бәхәсләрне чишәргә омтыла, якын кешеләренең эмоцияләренә җавап бирә, әйләнә-тирәдәгеләргә булышырга әзер тора; әкият, хикәя, әсәр геройлары белән бергә борчыла, сәнгать әсәрләре, музыка, табигать дөньясына эмоциональ тәэсир итә, матурлыкны күрә белә, хайваннарга, үсемлекләргә сак карый. Баланың күзаллавы үсеш алган, уеннарның төрле төрен белә, шартлы һәм реаль ситуациянеаера. Бәйләнешле сөйләм телен җитәрлек дәрәҗәдә белә, фикерен әйтә. Баланың эре һәм вак моторикасы үсеш алган, хәрәкәтчән, чыдам, төп хәрәкәт төрләрен белә, үз хәрәкәтен контрольдә тота. Ихтыяр көче бар, төрле төр эшчәнлекнең кагыйдәләрен саклый, “нәрсә яхшы, нәрсә начар” күзаллавы буенча үзенең һәм башкаларның башкарган эшләрен бәяли. Бала кызыксынучанлык күрсәтә, сорау бирә, сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше белән кызыксына, мөстәкыйль рәвештә кешеләрнең кылган эшләренә, табигать күренешләренә бәя бирергә тырыша, тәҗрибә ясарга һәм күзәтергә омтыла. Бала тарих һәм культура белән кызыксына, башка милләт культурасына толерант карый.  Табигать, социаль дөнья, үзе турында башлангыч белемгә ия. Балалар әдәбияты, тере табигать, табигать белеме, математика, тарих һ.б. буенча иң гади күзаллавы бар. Эшчәнлекнең төрле өлкәләренә һәм белеменә таянып, үзе төрле ситуациядән чыга ала. Бала кагыйдә, үрнәк, гади алгоритм (3-4 адым) буенча эшли белә, өлкәннәр ярдәмендә авырыксынган сорауларны чишә,

сәбәпләрен ачыклый һәм танып белү бурычын формалаштыра, ирешелгән нәтиҗәне һәм шартны теркәп куя.

## IIЭчтәлек бүлеге.

### 2.1. 1 Социаль-шәхси үсеш

### «Социальләштерү» белем бирү өлкәсе

«Социальләштерү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларның социаль характердагы беренчел күзаллауларын үзләштерү һәм балаларны социаль мөнәсәбәтләр система-сына кертү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.Балаларда патриотизм хисләре; үзен туган шәһәре (авылы), республикасы, иленең гражданины итеп тану; шәһәр, республика, ил символикасына (флаг, герб, гимнга) хөрмәт белән карауны һәм горурлану хисе тәрбияләү. Иҗтимагый чыгышы, расасы, теле, дине, җенесе һәм яшенә карамыйча, янәшәдә яшәүчеләргә (балаларга, өлкәннәргә) уңай мөнәсәбәт, түземлек (толерантлык); башка кешеләрнең хисләре, фикерләре, теләкләренә, карашларына хөрмәт тәр- бияләү, үзенең башкалар фикере белән риза булмавын дәлилли яисә үз позициясен яклый белергә өйрәтү. Башка ил, этнос халыклары белән позитив аралашуның, хезмәттәшлек итүнең мәгънәсен аңлату.Якындагы социумда үз урыны, теге яки бу төркемдәге кешеләргә нинди мөнәсәбәттә булуы (балалар бакчасындагы төркем яисә бию булачак гимназист һ. б.) турында күзаллаулар формалаштыру.
Гаилә тарихына (карт бабай, бабай, карт әби, әби) карата 175Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы)кызыксыну тәрбияләү. Гаиләң белән горурлану хисләре, гаилә әгъзаларының уңышларына сөенү, бүләкләрен игътибарсыз калдырмау күнекмәләре тәрбияләү.Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре, нәфис һәм муль-типликацион фильмнары, әйләнә-тирәдәге тормыш турын- дагы күзаллауларын сюжетлы-рольле һәм режиссёрлык уен-нарында иҗади куллануларына булышлык итү.
Балаларның сәхнәләштерү һәм кую өчен Идел буе ха-лыкларының әкиятләрен, шигырьләрен, җырларын, биюләрен мөстәкыйль сайлап алуларын хуплау; куелачак спектакльгә кирәкле атрибутлар һәм декорацияләр әзерләргә, үзара вазифаларны билгеләргә һәм рольләр бүлешергә булышу.
Театральләшкән эшчәнлектә театрның төрле төрләрен (бибабо, бармак, курчак, рәсемнәр һ. б. театрлар) куллану. Сәхнә сәнгатенә карата кызыксыну үстерү. Коллективта сүзле уеннар уйнарга омтылышларын хуплау. Идел буе халыклары уеннарын уйнау тәҗрибәсен баету.

| Название праздника (события) | Краткая информационная справка | Рекомендуемое время проведения праздника (события) | Форма проведения праздника | Подготовка к празднику |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| **Исәнме, балалар бакчасы**<br><br>**Сау бул, җәй!**<br><br>**Белем бәйрәме** | 1 нче сентябрь-яңа уку елы. 1 нче сентябрь 1984 нче елдан үткәрелә башлый. Ел саен бу көн мәктәпләрдә билгеләп үтелә. Белем көне беренче тапкыр мәктәпкә баручы балалар өчен иң көтеп алынган бәйрәм. | **Сентябрьнең 1 нче атнасы** | - группага экскурсия;<br><br>- “Без балалар бакчасында” бәйрәмендә катнашу.<br><br>“Көз мизгелләре” дигән уен программасы. Чәй өстәле.<br><br>-”Мин җәйне ничек уздырдым” шөгыле.<br><br>Мәктәпкә бару: “Сау бул, җәй!”<br><br>-Мәктәптә “Беренче кыңгырау” бәйрәмендә катнашу (тантаналы чарада катнашу, бүләкләр тапшыру).<br><br>-Балалар бакчасында”Белем бәйрәме”. | 5-6 яшь<br><br>Мәктәп турында беренчел күзаллау( Дәрес,билге,мәктәп әсбаплары, укучының көндәлек режимы) Укытучы хезмәте.<br>-С/р –уеннар( “Мәктәп”, “Кибет”,(мәктәп кирәк-яраклары сату)<br>-бәйрәм турында әңгәмә<br>-ял итү, тәнәфестә хәрәкәтле уеннар<br>Тема буенча матур әдәбият уку.<br>-мәктәп әсбаплары белән танышу.<br>- мәктәп әсбаплары турында табышмаклар<br>-“минем абый ничек мәктәпкә җыенды” хикәя төзү<br>-мәктәп турында җырлар тыңлау һәм өйрәнү.<br>-беренче класс балаларына хезмәт бүлмәсендә бүләкләр әзерләү, сюжетлы-рольле уеннар өчен атрибутлар. |
| **Минем өем (Гаилә).** | Гаилә, гаилә йолалары турында беренче күзаллау.Авыл белән таныштыру. Туган шәһәр белән танышу, урамдагы матурлыкны күрә белү,туган ягы өчен горурлык хисе тәрбияләү.<br>Юл йөрү кагыйдәләре белән беренчел танышу, җәяүле өчен юл | **сентябрьнең 2 нче атнасы** | -әңгәмә:” Әти-әни”, “Без тату гаилә”,”Син кем белән яшисең”, “Мин әниемне яратам”, “Минем әби иң яхшысы”<br>-с\р-уен “Гаилә”<br>-гаилә рәсемнәреннән күргәзмә “Өйдә ничек уйныйбыз” фотоальбомы(урамда йөргәндә | **5-6- яшь**<br>**-с/р уен”Автобуста бару”, “Юл”, “Юл сакчысы”**<br>**- тема буенча тәрбиячеләр белән әңгәмә**<br>**Тема буенча рәсемнәр карау**<br>**Матур әдәбият уку**<br>**Д/уен”Үз билгеңне тап”,”Светофор”,”Юл кагыйдәләре”,** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Минем шәһәр** | кагыйдәләре.<br>Туган шәһәр турында балаларның белемнәрен арттыру, хезмәт кешеләре белән таныштыру. | | куркынычсызлык кагыйдәләрен кертеп)<br>“Минем шәһәр” панно.<br>-юлга сәяхәт<br>-Күңел ачу” Шәһәрдәшләрне сөендерү”.<br>-ГАИ хезмәткәрләре белән очрашу<br>Курчак театры “Белмәмешкә булышабыз”<br><br>-викторина” Туган шәһәр турында күп белүчеләр”<br>-Рәсем күргәзмәсе”Минем туган шәһәр” | **“Игътибар, юл”**<br>**-светофор белән танышу өчен максатлы юл чатына йөрү**<br>**-тема буенча табышмаклар**<br>**-тема буенча викторина**<br>**“Юл билгеләре”,”Светофор кагыйдәләре” коллекция туплау**<br>**-“Урамда” уеннары өчен кул эшләре**<br>**-автоүзәк һәм светофор төзү**<br>**Фильмнар карау тема буенча** |
| **«Туган ягым Татарстан»** | Хайваннар дөньясы турында беренчел күзаллау.Хайваннар дөньясы белән кызыксынуны булдыру.<br>Көнкүреш җиһазлары, кирәк-яраклары белән таныштыру.<br>Якыннарыңның һөнәрләре белән таныштыру.<br>Гаиләдә бер-берең турында кайгырту<br>“Кемнең өе нинди?”, “Әйберләр дөньясына сәяхәт”<br>Туган якка яхшы караш тәрбияләү, аның табигате, мәдәнияте, байлыклары белән таныштыру | **сентябрьнең 3 нче атнасы** | -әңгәмә” Урманда яшәүчеләр”<br>-китап күргәзмәсе, бәйрәм темасына рәсемнәр<br>Күңел ачу”Минем өем Татарстан”<br>Викторина”Туган як белгечләре”<br>ГЦДТ га экскурсия<br>Бәйрәм “Туган якта күңелле дус яшибез”<br>Рәсем күргәзмәсе “Казан-Универсиада” | **5-6 яшь.**<br>( НРК буенча) |
| **Уңыш.** | 27 нче сентябрь- яңа бәйрәм”Тәрбиячеләр көне”<br>Бу бәйрәмнең максаты: балалар бакчасына игътибарны арттыру.<br>Мәктәпкәчә яшь-бала тормышында | **Сентябрьнең 4 нче атнасы** | -“Без бакчага барабыз” – әңгәмә.<br><br>-Бәйрәм темасы буенча күргәзмә.<br><br>-Ачык ишекләр көне: “Табигать | **5-6 яшь**<br>Тәрбияче һөнәренә, балалар бакчасына һәм хезмәткәрләренә яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү, һөнәргә беренчел караш булдыру. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Тәрбиячеләр көне** | иң җаваплы чор, бу яшьтә бала шәхес буларак формалаша, сәламәтлегенә күбрәк йогынты ясала. Баланың тормышында һәм язмышында тәрбияченең түземлелеге зур роль уйный.<br>Тәрбияче ярдәмендә балалар тирә-юнь белән танышалар. | | байлыкларыннан күргәзмә.<br><br>-“Көз безгә нәрсә бирә?”- күңел ачу.<br><br>-“Безнең бакчада” – фотокүргәзмә.<br><br>-“Бакчада”- викторина. | -педагогик ситуация һәм чишү юллары.<br>-Проект эше (балалар бакчасының макетын төрле вак материаллардан төзү).<br>-Балалар бакчасы турында музыкаль импровизация.<br>-балалар бакчасы буенча тематик экскурсия (аш бүлмәсе, табиб бүлмәсе, кер юу бүлмәсе, спорт бүлмәсе h.б.)<br>- “Минем яраткан бакчам” – рәсем ясау.<br>Коллектив эш: “Матур чәчәк гөлләмәсе- безнең тәрбиячеләргә”, чәчәк рәсеме яки аппликациясе ясап, уртак гөлләмәгә җыю.<br>“Безнең группа” балалар һәм тәрбиячеләрнең портретын уртак портретка туплау, “балалар бакчасы” уенына атрибутлар ясау.<br>“Кайда булдык- әйтмибез, нәрсә эшләдек- күрсәтәбез”- һөнәр сайлау уены, төрле һөнәр кешеләренең хис-кичерешләрен төрле рәвештә күрсәтү.<br>Балалар бакчасында эшләүчеләр турында табышмак уйлап табу һәм чишү. |
| **Көзге буяулар (табигать күренешләре)** | Табигатьне яратырга һәм сакларга өйрәтү, көзге табигать күренешләре белән танышу.<br>Табигатькә сак караш тәрбияләү.<br>Көзге табигатьнең матурлыгын күрә белергә өйрәтү, һава торышын күзәтү.<br><br>Уен барышында бер-берең белән дус-тату уйнарга өйрәнү.<br>Балаларга тирә-юньнең матурлыгын күрә белергә, табигатькә сак караш тәрбияләргә өйрәтү. | **октябрьнең 1нче атнасы** | -Балалар белән кайсы ел фасылы булуы турында әңгәмә<br>-<br>көз турында рәсем(кул эшләре, аппликация)<br><br>-күргәзмә”Көзге буяулар”<br><br>-күргәзмә”Тормыш матурлыгы, табигать һәм сәнгать”<br><br>Шөгыль “Көз” | **5-6 яшь**<br>**-с/р уен”Кием кибете**“,”Гаилә”<br>-Табигатьне күзәтү<br>-тема буенча тәрбияченең сөйләме<br>-табышмак уйлап табу һәм чишү тема буенча<br>-“Алтын көз” Левитан картинасы карау<br>-бәйрәм темасы буенча матур әдәбият уку<br>-Чайковскийның “Ел фасылы” әсәрен тыңлау<br>-Хезмәт бүлмәсе(бергәләп “Көзге мизгелләр” дигән коллаж әзерләү, “Көз бәйрәменә” чакыру ) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Көз турында белемнәрне арттыру. Бербөтен вакыт итеп көз турында күзаллау, үсемлекләр һәм хайваннарның көзгә яраклашуы, көзге үзгәрешләр турында өйрәтү.<br>. | | -урманга, паркка, рәсемнәр күргәзмәсенә сәяхәт<br><br>-көзге гөлләмә күргәзмәсе<br><br>-“Алтын көз” бәйрәме<br><br>-“Көзге моңнар” күңел ачу<br><br>-көз турында рәсем һәм кул эшләре күргәзмәсе | -“Уңышны җый” уйнау<br>-гаилә белән “Көзге гөлләмә”күргәзмә<br>-мәйданчыкта чәчәк орлыклары, коры яфраклар җыюны оештыру |
| **Хайваннар дөньясында** | 1931 нчеелдаФлоренциядә Бөтен дөнья киңәшмәсендә 4 нче октябрьБөтен дөнья хайваннар көне дип игълан ителә. Бик күп илләр бу сәясәткә кушылдылар һәм төрле чаралар үткәрергә әзерлекләрен әйттеләр.Рәсәйдә бу көн 2000 нче елдан кертелде .Хайваннарны яклау көне максатыннан бик күп чаралар үткәрелә. Йорт хайваннары тоту буенча Рәсәй АКШ тан соң 2 нче урында тора. Рәсәйдә һәр 3 нче кеше йорт хайваннары асрый. | **октябрьнең 2 нче атнасы** | -хайваннар б-н танышу<br><br>-күргәзмә(хайваннар рәсеме)<br><br>-викторина” Хайваннар дөньясында”<br><br>-зоопарк төзү<br>Йорт хайваннары рәсемнәренә күргәзмә<br>Шөгыль “Аквариум”<br>-зоопаркка экскурсия<br>-рәсем күргәзмәсе<br>-викторина”Хайваннар дөньясында”<br>-зоопарк төзүне тәмамлау<br>-йорт хайваннары рәсемнәре күргәзмәсе | **5-6 яшь**<br>**Ха**йваннарны безнең кечкенә дусларыбыз икәнлеген төшендерү<br>-мультфильмнар буенча с/р-уеннар уйнау, кинолар карау<br>-“Хайванны таны”хәрәкәтле уен<br>-проект эшчәнлеге( хайваннарга игътибарлыһәм сак булырга өйрәтү, хайваннар юлда булуын билгеләүче юл билгеләре ясау, “Кыргый хайваннар”, “Хайваннар күчерү урыны” дигән макет ясау)<br>-хезмәт бүлмәсе(бәйрәм темасы буенча рәсе һәм кул эше)<br>-коллекция төзү(“Рәсәй җәнлекләре”, “Туган як җәнлекләре”, “Рәсәйнең һәм туган якның Кызыл китабы”)<br>-йорт хайвннары күргәзмәсе оештыру, язучы-рәссамнар китапларын күрсәтү(Е.Чарушин, В.Ватагин, В. Чижиков)<br>-бәйрәм темасы буенча төрле китаплар уку<br>-хайваннар яраланса, нәрсә эшләргә кирәк |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | дигән темага әңгәмә<br>-тема буенча табышмак уйлап табу һәм чишү<br>-хайваннарны кайгыртырга өйрәнү<br>-йорт хайваннары турында сөйләү |
| **Табиб Айавыртада кунакта**<br><br>**Бөтендөнья табиблар көне** | Табиб һөнәре иң олы һөнәргә керә. Бөтендөнья сәламәтлек оешмасы Табиблар көнен билгеләп үтү өчен указ чыгарды.1971 нче елдан “Табиблар бар җирдә” дигән бөтен ил табиблар оешмасы булдырылды. Бу оешма илдә төрле афәтләр булганда ярдәм итәргә һәрвакыт әзер торырга тиеш, ул 80 илгә ярдәм итә, аларның мөнәсәбәтләре нинди булуга карамастан. | **октябрьнең 3 нче атнасы** | -с/р-уен”Хастаханә”, “Шифаханә”<br>-музыка һәм спорт буенча күңел ачу<br>-шәфкать туташы бүлмәсен экскурсия<br>“Әтәчкәй өчен витамин” күргәзмә<br>Шөгыль “Тән төзелеше белән танышу”<br>-с/р уен”Хастаханә”, “Шифаханә”<br>-Шифаханәгә экскурсия | **5-6 яшь**<br>Табиб һөнәре турында беренче күзаллауны тудыру , аның әһәмияте , тоткан урыны, кирәкле һөнәр икәнен аңлату(авыруларга ярдәм итә, хәлләрен җиңеләйтә)<br>-әдәбият әсәрләренә таянып с/р уеннар уйнау<br>-тема буенча табышмак уйлап табу һәм чишү<br>-бәйрәм эчтәлеге буенча төрле китаплар уку<br>-тәрбиячеләрнең табибларның бүленеше турында сөйләү(күз табибы, хирург һ.б.)<br>-бәөрәм эчтәлеге буенча үстерелешле уеннар уйнау<br>- табиб бүлмәсенә экскурсия<br>-“Кем беренче авыручыга ярдәм итә?” көч сынашу<br>-викторина “Нәрсә, кайда, кайчан?” тема буенча фикерләү уены<br>- котлау открыткалары, плакатлар ясау, с/р уеннар өчен әйберләр ясау |
| **Транспорт** | Траспорт турында беренчел күзаллау булдыру, юл йөрү кагыйдәләрен белү, транспортта үз-үзеңне тота белү кагыйдәләрен искә төшерү, төрле транспортларны таный белү.<br>Транпортның ни өчен кирәклеген аңлату, су, һава, җир транспортлары | **Октябрьнең 4 нче атнасы** | -төрле транспорт чаралары белән танышу(йөк һәм җиңел)<br>-эчтәлек буенча китаплар, аль-бомнар карау<br>-«Транспорт»с/р уеннар<br>-транспортны күзәтү<br>-“Транспорт” коллаж төзү<br>Шөгыль “Минем урам” | 5-6 яшь<br>-с/р уен”Шәһәр урамында”,” Самолет”,”Янгын сүндерү машинасы”,”Автобуста сәяхәт”, “Корабта сәяхәт”<br>-эчтәлек буенча тәрбияче белән әңгәмә,<br>-төрле төрдәге транспорт чараларын карау<br>-транспорт турында табышмаклар ятлау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белән таныштыру. Зур шәһәрләрдә юлда йөргәндә үз-үзеңне тота белү, кагыйдә буенча йөрү.<br>Транспортның җәмгыять өчен әһәмиятен ачыклау. | | Табышмаклар кичәсе<br>-“Белмәмеш юлда” курчак театры<br>- шөгыль “Тыныч урам”<br>-транспорт төрләре дигән күргәзмә<br>-викторина” Транспорт” | -“Белмәмешкә юлны чыгарга булыш” уен оештыру<br>-“Без автобуста”, “Урамда үз-үзеңне тоту кагыйдәләре” авыр хәлдән чыгу юлларын табу<br>-матур әдәбият уку<br>-бергәләп төзү”Автобус безнең урамда”, “Машинам өчен гараж |
| **Дуслык**<br><br>**Халыклар дуслыгы көне** | 4 нче ноябрь Халыклар дуслыгы көне, 1612 нче елда Кузьма Минин һәм Дмитрий Пожарский җитәкчелегендәге гаскәр 4 нче ноябрьдә Кытай шәһәрне яулап алалар, Мәскәү шәһәрен азат итәләр . Бу сугышта төрле ил халыклары, төрле дин кешеләре булуы халыкларның берләшүен күрсәтә. Алексей патша указы буенча 1649 нчы елдан Изге Ана иконасы көне билгеләп үтелә башлый.<br><br>. | **ноябрьнең 1 нче атнасы** | -милли бәйрәм<br><br>-күңел ачу( халык уеннары)<br><br>-кул эшләре һәм рәсемнәр күргәзмәсе<br><br>-“Халыклар дуслыгы”-күңел ачу<br><br>-Рәсәй турында рәсемнәр күргәзмәсе | 5-6 яшь<br>Бердәм Рәсәй турында беренчел күзаллау, аның күп телле милләт булуын аңлату.Төрле милләт кешеләренә карата ягымлы булырга кирәклеген әйтеп үтү.<br>-“Рәсәй милләтләре” әңгәмә оештыру<br>-Рәсәй халык әкиятләрен , матур әдәбият уку<br>-уеннарны сәхнәләштерү, хәрәкәтле уеннар<br>-бәйрәм эчтәлеге буенча шигырьләр ятлау.<br>-К.Минин һәм Д. Пожарский сурәтләрен карау<br>-проект эшчәнлеге”Рәсәй иле буенча сәяхәт”<br>-коллекция туплау(хайваннар дөньясы, үсемлекләр, күренекле урыннары)<br>“милли киемнәр” рәсем һәм кул эшләре<br>-Рәсәй халкының җырларын һәм биюләрен тыңлау, өйрәнү |
| **Көнкүреш кирәк-яраклары** | Көнкүреш крәк-яракларының кеше тормышында тоткан урыны, әһәмияте.<br>Кайбер көнкүреш кирәк-яраклары белән танышу(җиһазлар, савыт-саба), аларның нәрсәдән ясалганлыгын күрсәтү. | **2-я неделя ноября** | -көнкүреш кирәк-яраклары турында әңгәмә<br>-эчтәлеге буенча предметлы-үстерелешле әйләнә-тирәне баету<br>- эчтәлеге буенча атналык нәтиҗә | **5-6 яшь**<br>-с/р уен «Өй, гаилә”, “Кунаклар каршылыйбыз”, “Электр җиһзалары кибете”<br>-эчтәлеккә туры китереп табышмаклар, мәкальләр өйрәнәбез<br>- эчтәлеккә туры китереп тәрбияче белән |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Өйдәге ут жиһазларының кирәклеге, алар белән ничек кулланырга , сак булырга өйрәтү. Тирә-юндәге әйберләргә кызыксыну уяту. Алар белән эшләү күп вакытны алмый дигәнне төшендерү. | | ясау<br>-дидактик уен эчтәлеге буенча<br>-кул эшләре һәм рәсемнәр күргәзмәсе<br>Шөгыль "Төркем белән танышу"<br>-уенчык ут җиһазлары күргәзмәсе<br>- "Җиһазлар фабрикасы" уен "Минем өем" түгәрәк өстәл | әңгәмә<br>- эчтәлеккә туры китереп рәсемәр карау<br>- китап уку<br>-кул эше һәм рәсем ясау( Телевизор һ.б.)<br>-шырпы кабыннан җиһаз төзү |
| **Дөрес итеп аралашу.** | "Бөтендөнья исәнләшү көне" 1973 нче елдан бирле билгеләп үтелә. Аны абыйлы-энеле америкалылар уйлап чыгарганнар, илдә салкын сугыш барганда илләр арасында тынычлык теләп,төрле илләргә хатлар җибәргәннәр. Алар хатларында бары тик кем белән булса да исәнләшергә һәм үәлләрен сорашырга чакырганнар.<br>Бу фикер ил башлыкларына бик ошаган, шул көннән алып 21 ноябрь бәөрәм көне буларак билгеләп үтелә | **ноябрьнең 3 нче атнасы** | -с/р уен"Кунакта", "Рәхим итегез"<br>-үз кулларың белән ясалган открыткалар, котлау язылган рәсемнәр тапшыру<br>Шөгыль "Театр бинасына бару"<br>-авазлар аша котлау | **5-6 яшь**<br><br>Бер-берең белән аралашканда ягымлы итеп сөйләшү, матур сүзләр куллану, кешеләр белән аралашканда дустанә мөнәсәбәт булдыру<br>- с/р уен "Туган көн" ,"Балалар бакчасы кунаклар каршылый"<br>- укылган әсәрне бер-берең белән эчтәлегенең мәгънәсен бүлешү , исәнләшү кайсы илдә ничек үтә-милли күренешләрне бүлешү.<br><br>- уен (интернет аша исәнләшү, кул биреп , баш киемен салып, "хайваннар исәнләшүе", "Роботлар исәнләшүе" ," Шаярып исәнләшү")<br>- эчтәлеге буенча театр сәхнәләштерү<br>-бергәләп котлау открыткалары, курчаклар, төрле кул эшләре ясау<br>-бәйрәм эчтәлеге буенча җырлар өйрәнү һәм җырла |
| **Әниләр көне** | Әниләр көне 1998 нче елның соңгы якшәмбесеннән Рәсәй президенты | **ноябрьнең 4 нче атнасы** | -шигырь бәйгесе "Кадерле әнием өчен котлау сүзләре" | **5-6 яшь**<br>Әниләргә карата хөрмәт, аңа булышу |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тарафыннан кертелде hшм үткәрелә башлады. Бу бәйрәм әниләрнең армый-талмый эшләүләренә рәхмәт йөзеннән үткәрелә башлады. Бу бәйрәмгә бер кеше дә битараф кала алмый.Бу көнне әниләргә рәхмәт сүзләре әйтәсе килә. | | -рәсем күргәзмәсе “Минем әнием”<br>-әниләр белән спорт бәйрәме Әниләр көнен үткәрү<br>-“Әниләр көне” дигән үстерелешле шөгыль<br>-“Әни сурәте сәнгатьтә” шөгыль | теләге, аны кайгыртасы килүне тәрбияләү<br>-с/р уен “Гаилә”<br>-“Минем Әнием” портрет күргәзмәсе<br>-проект эшчәнлеге<br>-кул эше : әниләр өчен бүләк ясау, “Гаилә” с/р уен өчен үз кулларың белән атрибутлар ясау<br>-спорт уеннарына әниләр белән бергә әзерләнү<br>--җырлы-биюле композиөия әзерләү<br>-уен ( автобустан чыкканда әниләргә кул бирү, ишек ачу , кирәкле әйберсен илтеп бирү)<br>-өй эшләрендә булышу, авырган вакытта булышу |
| | | | | |
| **“Исәнме, кыш”** | Кыш турында беренчел күзаллау, бергәләп эшләүдән тәм табу, балаларның сәламәтлекләрен кайгырту, белемнәрне ныгыту. Төрле уен формаларына кызыксыну уяту.<br>Уен барышында кагыйдәләрне бозмыйча дус-тату уйнау, бер-береңне этмичә, уенчыкларны тартып алмыйча уйнарга өйрәнү.<br>Уен барышында сөйләм телен үстерү, сүзлек запасын баету.<br>Балалар белән бергәләп hав торышын күзәтү. Кыш көне җылы итеп киенәләр.өйләр җылытыла,балалар шугалакта шуалар.<br>Кыш көне көнне күзәтү, матурлыгын күрә белү. Алган | **декабрьнең 1 нче атнасы** | -бәйрәм эчтәлеге буенча күңел ачу үткәрү<br>-кыш турында әңгәмә<br>“Кышкы ял урыны” панно ясау<br>Шөгыль “Кем кышка ничек әзерләнде?”<br>-кыш турында шигырьләр уку<br>-кыш турында рәсемнәр күргәзмәсе<br>-“Нәрсә, кайда, кайчан?” | 5-6 яшь<br>-кыш турында әңгәмә<br>-кышны күзәтү<br>-кыш турында рәсемнәр карау<br>-матур әдәбият уку<br>-кыш турында табышмаклар уйлап табу hәм чишү<br>-кыш турында шигырь ятлау<br>-“Кышкы мизгелләр” , “Кышлаучы кошлар” кул эшләре<br>-кыш турында җырлар тыңлау hәм өйрәнү |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белемнәрне системалаштырып кышкы айларның исемнәрен өйрәнү, бюездә кышлаучы кошларны таный белү. | | | |
| **“Уңган куллар”**<br><br>**Осталар шәһәре** | Балаларда сәнгать һәм иңади сәләтләрне формалаштыру , алдан алынган белем һәм сәләтләрен камилләштерү, барлык эштә актив һәм теләп эшләүне булдыру.<br>Шәхси ошау ягыннан кечкенә төркемнәргә бүленеп бер-береңә карат яхшы мөгаммәләдә булу<br><br>Балаларга үз куллары белән Яңа елга бүләкләр ясарга, төркемне бизәргә булышу, бергәләшеп эшләү күңелле икәнлеген күзаллауны булдыру<br>Һөнәр турында белемнәрне тирәнәйтү.Төрле һөнәр ияләренә карата мәхәббәт тәрбияләү | **декабрьнең 2 нче атнасы** | - “ Без осталар һәм булганнар” бәйрәмендә катнашу( бхләкләр тапшыру)<br>-әңгәмә “ Сез зурларга ничек булышасыз?”<br>Яңа ел открыткалары әзерләү<br>Шөгыль “ Безнең тормышта бәйрәмнәрнең роле<br>-” Кыш бабайның остаханәсе” уен<br>-с/р уен- “Кулинар фабрика”<br>- “Осталар шәһәре” күңел ачу | **5-6 яшь**<br>-дидактик уен”Бу кемгә кирәк?” ,”Үзең яса”, “Дөрес сайла”<br>-с/р уен-“Гаилә”, “Балалар бакчасы”, “Чәчтарашханә”, “ Кыш бабайның остаханәсе”<br>-шигырләр һәм матур әдәбият уку<br>-Һөнәрләр турында табышмаклар чишү<br>-эш турында мәкальләр өйрәнү<br>. |
| **“Куркынычсыз лык әлифбасы”** | Куркынычсызлык кагыйдәләре осталыкларын формалаштыру һәм үстерү, урамда һәм юлда куркынычсызлык кагыйдәләрен дөрес үтәүне тәрбияләү, бер-береңне һәм зурлар сүзенә колак салу. Юл йөрү һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен ныгыту. Фаҗигага эләккәндә бер-береңә булышу теләге уяту. Иптәшләрең һәм зурлар белән билгеле булган кагыйдәләрдән чыкмаска өйрәтү, куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәтү. | **декабрьнең 3 нче атнасы** | -юл йөрү кагыйдәләре турында әңгәмә<br>-рольле уен “Машина һәм светофор”<br>-“Куркынычсызлык әлифбасы” атналыгына нәтиҗә<br>-күңел ачу<br>-Шөгыль “Боз”<br>-курчак театры “Белмәмешкә булышабыз”<br>-күңел ачу “ Буратинаның сәяхәте”<br>-диафильм карау “Юл йөрү кагыйдәләре” | **5-6 яшь**<br>-с/р уен “Өй”, “ Ашыгыч ярдәм”, “Коткаручылар”, “ Юл сакчылары”<br>-эчтәлек буенча әкият сәхнәләштерү,<br>-эчтәлек буенча рәсемнәр карау<br><br>- педагогик хәл “ Ишектә таныш түгел кеше” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -викторина -“Куркынычсызлык әлифбасы” | |
| **Яңа ел** | Христиан дини календарь буенча Яңа Ел бәйрәме элек җир эшләре башланыр алдыннан март азагында билгеләп үтелгән. Юлий Цезарь Яңа ел бәрәмен 1 нче январьгә күчерә. | **декабрьнең 4 нче атнасы** | -Яңа ел кичәсе<br><br>-карнавал<br><br>-матур костюмнар балы | Бәйрәмгә әзерләнгән вакытта “Куркынычсызлык” укыту өлкәсенә игътибарлы булырга кирәк. Яңа ел күңелле гаилә бәйрәме(бу каникуллар, театрлар,сәяхәтләр өчен рәхәт вакыт), ел башлана ( үзгәрешләр турында сөйләшү) Яңа ел-балаларның иң яраткан бәйрәмнәре. |
| **Кызыклы кыш** | Күңел ачуда актив катнашу, хәрәкәтле уеннарга кызыксыну уяту, бергәләп эш-гамәлләрне башкару, рольләргә бүленеп уйнау, дус-тату булу. Бер-берең ярдәм итү. Уенга шатлык хисләре уяту. Уенда кагыйдә буенча уйнау( качу, Битләрне каплап уйнау, баш өстен өй ясау).Йөгергәндә, сикергәндә, һ.б җитезлек , хәрәкәтчәнлекне арттыру.<br>Башка халык уеннарына кызыксыну уяту, раштуа бәйрәмнәрендә уйнала торган өен төрләре белән таныштыру. Сәламәтлекне ныгыту һәм кәефне күтәрү<br><br>. | **Гыйнварның 2 нче атнасы** | -хәрәкәтле уеннар<br><br>-көйгә уен хәрәкәтләре<br><br>-урамда хәрәкәтле уеннар<br><br>-“Кар бөртекләре”рәсем күргәзмәсе<br>-кар белән уеннар<br><br>-матур әдәбият уку<br><br>-спорт эстафетасы<br><br>-күңел ачу “Кышкы урманга сәяхәт”<br><br>-балалар эшләнмәләре”Кызыклы кыш” | **5-6 яшь**<br>- кышкы күренешләр турында табышмаклар чишү<br>-кыш турында шигырьләр ятлау, уку<br>-кыш турында рәсемнәр карау<br>-рәсем ясау |
| **Әкияттә кунакта** | Матур әдәбияткә ,халык аваз иҗатына уңай караш формалаштыру. Әкият геройлары | **Гыйнварның 3 нче атнасы** | - день открытых дверей «В гос-тях у сказки» | **5-6 лет**<br>--эчтәлек буенча әкият сәхнәләштерү,<br>-эчтәлек буенча рәсемнәр карау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | белән танышу. Әкиятне азагына хәтле тыңлап бетерү, геройлары белән уйнау, тәрбияче белән бергәләп әкиятне сөйләү,әкиятне сөйләүдән генә аңлау.<br>Дуслык турындагы күзаллауны киңәйтү.<br>Халык авыз иҗатына кызыксыну уяту.<br>Халыкның сәнгаткә карашын үзгәртү, башка халык сәнгатенә хөрмәт тәрбияләү.<br><br>. | | -рәсемнәр күргәзмәсе “Минем яраткан әкият героем”<br><br>-төзү”Теремкәй”<br><br>-хәрәкәтле уеннар<br>-бармак уеннары<br><br>-матур әдәбият уку<br><br>-әкият сәхнәләштерү<br><br>-курчак театры<br><br>-“Әкиятләр иленә”сәяхәт<br><br>“Теремкәй” әкиятен күрсәтү<br><br>-күңел ачу “Әкият геройлары”<br><br>Шөгыль “Әкият рәсемнәре”<br>-китапханәгә экскурсия<br><br>-курчак театры<br><br>-күңел ачу”Китапның туган көне”<br><br>-күңел ачу” Нәрсә ярамаган, шул яраган” | -“Яңача әкият” геройларны уйнау<br>-кул эшләре |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Мин дөньяны танyйм**<br><br><br><br>**Бакча балалары өчен фән атналыгы** | Табигатьтәге төрле күренешләр белән беренчел танышуны формалаштыру, “Борынгы” дөнья һәм аның яшәүчеләре белән танышу.<br>Тикшеренүләр аша баланың интеллектуаль үсешен булдыру, күптөрле эшчәнлеген логик яктан үстерү.<br>Балаларга яңа белем бирү һәм элек алганнарны ныгыту | **гыйнварның 4нче атнасы** | -динозаврлар фотосы күргәзмәсе<br><br>-борынгы дөнья яшәүчеләре өчен өорт төзү<br><br>-викторина<br><br>Шөгыль“Фән серләре”<br><br>-тәҗрибә бәйрәме<br><br>-экологик сәяхәт<br><br>-“Безнең өй-җир шары”-д/у<br>-“Белмеш”-конкурс<br><br>-“Рәсәйнең бөек кешеләре”-кичә | **5-6 яшь**<br>Тирә-юнгә уңай караш тәрбияләү.Баланың танып белү өлкәсен баету<br>-“Сәяхәт” с/р -уен<br><br>-эчтәлек буенча рәсемнәр карау<br>- танып белү өлкәсе буенча әңгәмә, уку<br>-күзәтү һәм тәҗрибә үткәрү<br>-проект эшчәнлеге( рәсем күргәзмәсе, гөлләмәләр ясау)<br>-табышмаклар чишү |
| **Минем гаиләм** | Гаилә, патриотик хисләр, гендерлык, гражданлык табыну хисләрен формалаштыру, гаилә турында беренчел күзаллауны булдыру, гаилә эчендәге гореф-гадәтләрне саклау. | **февральнең 1 нче атнасы** | -хәрәкәтле уеннар “Шаян гаилә”<br><br>-гаилә рәсемнәре күргәзмәсе<br><br>-“Йорт хайваннары”ситуатив сөйләшү<br><br>-“ Без өйдә ничек уйныйбыз”фотоконкурс<br><br>Шөгыль “Минем гаиләм”<br><br>-“Әти, әни һәм мин –спорт гаиләсе”<br><br>-әңгәмә” Мин һәм минем гаиләм”<br><br>Шөгыль “Гаилә шәҗәрәсе” | **5-6 яшь**<br>Гаилә турында беренчел караш формалаштыру, горе-гадәтләрне барлау<br>-с/р уен “Сәяхәт”, “Бакчага бару”<br>-проект эшчәнлеге(шәҗәрә агачы төзү)<br>-хезмәт (гаилә кешеләре өчен бүләкләр ясау)<br>-гаилә белән бергәләп уйнау кичәләре оештыру, төркемдә булышу, төрле конкурсларда көч сынашу<br>-гаиләдә туган проблемаларны бергәләп чишү юлын эзләү<br>-ял иткәндә, эштә, бакчада бергә төшкән фоторәсемәр күргәзмәсе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Халык авыз ижаты**<br><br>**Туган тел бәйрәме** | Туган тел атналыгы көне билгеләп үтү. Бу бәйрәм 2000 нче елдан билгеләп үтелә башлый. Безнең милләтебезне саклап калуда тел бик зур роль уйный. ЮНЕСКО фикере буенча 6000  телнең яртысы гына исән калырга мөмкин.<br>Шуңа күрә милләтебезне югалтмас өчен телебезне саклап калырга кирәк. | **февральнең 2 нче атнасы** | Татар халык уены “Йөзек салыш”<br><br>-“Себер бүлмәсе”( көнкүреше һәм киемнәре) экскурсия<br><br>-татар халык киемен карау<br><br>-“Тәлинкәләр “ күргәзмә<br><br>-Матур әдәбият уку<br><br>- милли бәйрәм<br><br>-кул эшләре күргәзмәсе<br><br>-табышмаклар кичәсе<br><br>-дидактик уен “Дөрес әйт”, “Рифмага сал”<br><br>-әдәби викторина (татар язучыларының әсәрләре) | **5-6 яшь**<br>-туган телгә кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләү<br>-әңгәмә<br>-чит телдә җырлыр һәм шигырьләр тыңлау<br>-туган телдә шигырь ятлау<br>-әдәби викторина<br>- Татарстан картасын карау, анда яшәүче кешеләр белән танышу<br>-милли киемнәр карау, эшләре белән танышу<br>-туган телдә әкиятләр уку<br>-проект эшчәнлеге(китап чыгару) |
| **Кечкенә эзләүчеләр** | Су һәм комның үзлекләрен тикшерү, төрле хәлдз була алуларын күзәтү..Су һәм җиргә сак караш тәрбияләү, кеше сәламәтлегенә йогынтысын әйтеп үтү.Тәҗрибәләр үткәрү, яңалык ачарга булышу. Тәҗрибәләр ясау өчен уңай караш тәрбияләү | **февральнең 3 нче атнасы** | -бәйрәм-тәҗрибә үткәрү (ком һәм су белән)<br><br>-“Яшәсен су” күңел ачу<br><br>-“Кояш һәм яңгыр” спорт бәйрәме<br><br>-Рәсем күргәзмәсе “ Диңгез дулкыннары”<br><br>-матур әдәбият уку | **5-6 яшь**<br>Үрнәк буенча эшләүне формалаштыру, әкият геройлары аша сюжетлы уйлап табу<br>-с/р-уен “Өй”, “Гаилә”, “Шифаханә”, “Балалар бакчасы”, “Мәктәп”<br>-сюжетлы картиналар, гаилә рәсемнәрен карау<br>-мәкаль, шигырь ятлау<br>-матур әдәбият уку<br>-эчтәлеге буеча җырлар тыңлау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -“Уеннар иленә сәяхәт” | |
| **Ватанны саклаучылар көне** | Бүгенге көндә бу бәйрәмне Кызыл Армия туган көн дип түгел , ә чын ир-атлар көне дип билгеләп үтүчеләр Рәсәйдә күбрәк.<br>Рәсәй Армиясе көне турында беренчел караш формалаштыру.<br>Сугыш техникасы: самолет, танк , ракета. | **4 февральнең 4нче атнасы** | -әти-әниләр белән чәй эчүне оештыру<br><br>-музыкаль-театральләштерелгән кичә<br><br>-сугыш техникасы төзү<br><br>-с/р-уен “Кунакта”, “Рәхим итегез”<br><br>-Әтиләргә бүләкләр тапшыру<br><br>-әтиләр белән спорт ярышы үткәрү<br><br>-сугыш техникасын төзүне тәмамлау<br><br>Үстерелешле шөгыль –“Ватанны саклаучылар” | **5-6 яшь**<br>Рәсәй армиясе турында беренчел күзаллауны формалаштыру, ир-атларның безнең туган илебез сакчылары икәнен аңлату<br>-хәрәкәтле һәм спорт уеннары, эстафеталар, конкурслар<br>-с/р уеннар” Чик сакчылары”<br>-сугыш техникасыннан коллекция туплау<br>-сугыш турында җырлар , биюләр карау<br>-проект эшчәнлеге(кечкенә предметлардан танк төзү)<br>-викторина<br>-“Минем әтием хәрби” сөйләм<br>-табышмаклар уйлап табу һәм чишү<br>-“Беренче ярдәм күрсәтү” буенча көч сынашу<br>-хезмәт (Плакат чыгару, сугыш темасына атрибутлар ясау); |
| **Дөнья буйлап яз килә** | Ел фасыллары турында кузалллау формалаштыру. Яз фасылы белән таныштыру: кар эри, боз сөңгеләре барлыкка килә, игътибарлылыкны арттыру,сөйләм,уен эшчәнлеген тәрбияләү,табигатькә ярату, яны саклау хисләре тәрбияләү.<br>Яз турында белемнәрне ныгыту, яз көне хайваннар дөньясы уянуы турында белемнәре киңәйтү Туган якка мәхәббәт тәрбияләү. | **мартның 1 нче атнасы** | - “Яз шәһәре “буйлап сәяхәт<br><br>-“Менә без нинди зурлар”күңел ачу<br><br>-ел фасыллары турында әңгәмә<br><br>-“Тамчы” рәсем күргәзмәсе<br><br>Шөгыль “Кыш бабай яз турында дөреслек эзләгән”<br><br>-яз турында шигырьләр уку | **5-6 яшь**<br>Терек һәм терек булмаган язгы үзгәреәләр турында белемнәрне формалаштыру.Яңа уянып килүче үзгәрешләргә шатлык хисләре уяту<br>-күзәтү<br>-матур әдәбият уку<br>-картина һәм рәсемнәр карау<br>-табышмаклар уйлап табу һәм чишү<br>-яз турында җырлар ятлау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -“Яз урамда” рәсем күргәзмәсе | |
| **Бөтендөнья Хатын – кызлар көне** | Борынгы Римда киядә булган хатыннар бу бәйрәмдә ирләреннән бик күп бүләкләр алганнар ,матур киемнәр кигәннәр. Башларына тәкыяләр үреп кигәннәр һәм өй җылысын саклаучы алиһә Веста янына чиркүгә барганнар. Беренче тапкыр бу көн 1911 нче елдан бөтендөнья көне буларак дүрт илдә бәйрәм ителә башлый-Австрия, Алман, Дания, Швейцария. Рәсәйдә бу көн 1913 нче елдан билгеләп үтелә башлый. 1975 нче елның 8 нче мартыннан бәйрәм чын статус алды. | **Мартның 2 нче атнасы** | - Хатын-кызлар көненә багышлап бәйрәм иртәсе үткәрү<br><br>-әниләр белән бергәләп кул эшләре ясау-күргәзмә үткәрү<br><br>-рәсемнәр конкурсы”Минем яраткан әнием өчен”<br><br>-чәй өстәле әзерләү<br><br>-һөнәрне ачучы әниләр рәсеме буенча күргәзмә<br><br>-әңгәмә | **5-6 яшь**<br>Хатын-кызларга хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләү. Аларга булышу теләге уяту<br>-Бәйрәмне югары дәрәҗәдә үткәрү өчен барлык әзерлекләр булдырылган |
| **ПДД Яшь җәяүлеләр** | Юл йөрү кагыйдәләре турында беренчел караш формалаштыру, ГАИ хезмәткәрләре һөнәре турында күзаллау, юл йөрү кагыйдәләрен саклау.<br><br>Юлда сак йөрү, Юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту. | **мартның 3 нче атнасы** | -“ПДД” атналыгына нәтиҗә<br><br>-дидактик уеннар<br><br>-җәяүлеләрне күзәтү<br><br>-спорт күңел ачу бәйрәме<br><br>-“Юл куркынычсызлыгы” әти-әниләр белән бергәләп кул эшләрен ясау<br><br>-ГАИ хезмәткәрләре белән очрашу<br><br>-“Юл” күңел ачу<br>- | **5-6 яшь**<br>**-с/р –уен “Автобуста сәяхәт” ,”Юл”**<br>-күзәтү<br>-матур әдәбият уку<br>-картина һәм рәсемнәр карау<br>-табышмаклар уйлап табу һәм чишү<br>-д/у-“Үз билгеңне тап” “Светофор”, “Юл билгеләре”<br>-таныпбелү өлкәсе буенча викторина<br>-“Урам “ кулдан макет төзү<br>-автоүзәк, светофор төзү<br>-диафильм карау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | курчак театры” Белмәмнш – җәяүле”<br>-<br>викторина “Җәяүле урамда”<br>-<br>рәсемнәр күргәзмәсе “Минем шәһәр урамым” | |
| **Үсемлекләр көне**<br><br>**Бөтендөнья Җир һәм су чыганаклары көне** | Бөтендөнья Җир көне көн белән төн тигезләшкән көнне билгеләп үтелә.<br>Рәсәйдә 1998 нче елдан официаль рәвештә билгеләп үтелә башлый.<br><br>22 нче марттан су чыганакларының туган илебез өчен ничек кирәклеген әйтеп үтәргә була | **мартның 4 нче атнасы** | -“Дөнья тирәли “ балалар бакчасы буйлап сәяхәт<br><br>-табигать почмагында үсемлекләрне карау<br><br>-чәчәкләр күргәзмәсе<br>-“Үсемлекләр илендә” фото күргәзмә<br>Шөгыль “Чәчәкләр утырту”<br><br>-тәҗрибә бәйрәме<br><br>-“Су булсын!” бәйрәм.<br>-викторина<br><br>-экологик сәяхәт<br><br>Шөгыль “Безнең өй- җир шары” | **5-6 яшь**<br>Кеше сәламәтлеге өчен кирәк булган су һәм җир чыганакларының файдасын аңлату<br><br>-с/р уен”Сәяхәт”<br>Уен-эстафета(“Урманда чүп җыю”)<br>-рәсемнәр карау<br>-әңгәмә- “Җир шарын һәм сулыкларны пычратсаң нәрсә була?“<br>- тәҗрибә үткәрү<br>-ташлар җыю( диңгез, сулыклар, һ.б)<br>-үстерелешле уеннар”Су нинди була?”.”Тылсымлы таяк”, “Үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы”<br>-китаплар уку<br>-проект эшчәнлеге<br>-блалар белән әңгәмә” Судан башка яшәп буламы?” “Пычрак су”<br>-“Җирдә нәрсә үсә?” әти-әниләр почмагына плакатлар макетлар ясау<br>-танып-белү буенча викторина<br>-су белән уеннар<br>-күңел ачу<br>-су турында җырлар тыңлау<br>-хәрәкәтле уеннар |
| **Этикет** | Үз-үзләрен кунакта, дусларының | **мартның 5 нче атнасы** | - сәяхәт “Мойдодырда кунакта” | **5-6 яшь**<br>Төп этикет кагыйдәләре белән танышу: |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | туган көннәрендә, халык бәйрәмнәрендә, балалар бакчасында әдәпле тоту кагыйдәләренә өйрәтү. Зурлар белән әдәпле сөйләшү, дусларың белән дус-тату булу кагыйдәләренә өйрәтү.Җәмгыятьтә үз-үзеңне тотарга өйоәнү<br><br>. | | -уенчык бүлмәсендә җыештыру<br><br>-“Төркемдә бер көн”<br><br>-“Без театрга килдек” инсцени-ровка ясау<br><br>-“Безнең гаилә бәйрәмнәре”- фоторәсемнәр күргәзмәсе<br><br>-“ Әбигә кунакка барабыз” инсценировка ясау<br><br>- “Яхшы эшлзр илендә” күңел ачу<br>-“Әдәплеләр шәһәре” | өстәл артында утыру, үз-үзеңне тотыш.<br>-с/р-уен “Гаилә”, “Кибет”. “Балалар бакчасы”<br>-матур әдәбият белән таныштыру<br>- өстәл артында утыру, үз-үзеңне тотыш турында әңгәмә<br>-педагогик торыш”Төркемгә яңа кыз килде, аңа туркемдә үз-үзеңне ничек тотарга кирәклеген аңлату<br>-рәсемнәр карау<br>-диафильмнар карау |
| **Кошларны каршылыйбыз!**<br><br>**Бөтендөнья кошлар көне** | Бөтендөнья кошлар көне 1906 нчы елдан үткәрелә башлый. 1 нче апрельдән Бөтендөнья кошларны саклау конвециясенә керү турындагы хатка кул куелды.<br>Бу вакытта кошларга оялар эленә**.** | **апрельнең 1 нче атнасы** | -кул эшләренә күргәзмә<br><br>-сәяхәт бакча буйлап<br><br>-күңел ачу “Кошлар сайравы” | **5-6 яшь**<br>Бөтендөнья кошлар көне буенча |
| **Балалар кита-бы атналыгы**<br><br>**Бөтендөнья ба-лалар китабы көне** | 1967 нчеелның 2 нчеапреленнән гГ.Х.Андерсенның туган көнендә Бөтендөньябалаларкитабыкөне билгеләп үтелә.<br><br>. | **апрельнең 2 нче атнасы** | -үз кулларың белән ясалган китаплар күргәзмәсе<br><br>-с/р-уен “Китап кибете”<br><br>-китапханәгә сәяхәт<br><br>-яраткан әкият геройлары белән танышу<br><br>-балалар язучылары белән очрашу | **5-6 яшь**<br>Китап уку теләге булдыру.<br>--с/р-уен “Китап кибете”, “Китапханә”<br>- китапханәгә, китап кибетенә сәяхәт<br><br>-әлифба белән танышу<br><br>-әңгәмә үткәрү<br><br>-прект эшчәнлеге( китапханә почмагы былдыру) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -күңел ачу” Рәхмәт сезгә, китаплар | -китапларны рәтләү<br><br>-әдәби геойлар җырларын тыңлау<br><br>-әдәби викторина |
| **Сәламәт буласыбыз килә**<br><br><br><br><br><br><br><br><br>**Бөтендөнья Сләмәтлек көне** | Сәламәтлек көне 1950 нче елдан үткәрелә.Бу бәйрәм кешеләр үзләренед сәламәтлекләрен кайгыртсыннар , аның яшәү чыганагы икәнен аңласыннар өчен үткәрелә.<br>Ел саен сәламәтлек саклаучылар нинди булса да бер теманы күтәреп чыгаралар “Синең канда-кеше гомере” ,” Йөгерү-озын гомер бирә”... | **апрельнең 3 нче атнасы** | -күңел ачу<br><br>-шәфкать туташы бүлмәсенә сәяхәт<br><br>-“Авырма!” көч сынашу<br><br>-“Сәламәт яшәү рәвеше” дигән китап күргәзмәсе<br><br>-“Кояш, һава, су” коллаж ясау<br><br>-“Әти-әни һәм мин-спорт гаиләсе” көч сынашу | **5-6 яшь**<br>Сәламәт яшәү рәвеше турында беренчел кузаллау<br>-көч сынашу бәйрәм уңаеннан<br>-бассейн , спорт комплексларына сәяхәт<br>-проект эшчәнлеге( сәламәтлек турында плакатлар, энциклопедияләр карау)<br>-эчтәлек буенча әңгәмә( сәламәтлекне ныгыту,. сәламәт кеше яшәеше, физик эшчәнлекнең кеше сәламәтлегенә йогынтысы)<br>-рәсем конкурсы” -“Әти-әни һәм мин-сәламәт гаилә”<br>-матур әдәбият уку<br>-танып-белү викторина<br>-төрле үләннәр белән танышу |
| **Галәмгә сәяхәт**<br><br><br><br><br>**Галәмчеләр көне** | 12 нче апрельне 1961 нче елда Рәсәй майоры Ю. А. Гагарин “Көнчыгыш” галәм корабында беренче тапкыр җир шарын әйләнеп чыга.Очыш 108 минут дәвам итә. 1968 нче елдан Галәм көне барлык илләрдә бәйрәм ителә башлый | **апрельнең 4 нче атнасы** | -“Белмәмеш айда”мультфильм карау<br><br>-беренче галәмче турында сөйләшү<br>-с/р уен”Галәмче”, “Галәм ракетасы”,<br><br>-ракета әвәләү<br><br>-галәм турында диафильм карау<br><br>-галәмгә багышланган рәсемнәр | **5-6 яшь**<br>Рәсәйнең күренекле галәмчеләре турында беренчел күзаллау формалаштыру,илең өчен горурлана белү<br>- с/р уен”Галәмче”, “Галәм ракетасы”,<br><br>-проект эшчәнлеге(ракета макеты төзү, )<br>- галәм турында җырлар тыңлау<br>-музыкалы импровизация кую<br>-ку эшләре ясау<br>-беренче галәмче турында мәглумат җыю, галәмче хатын-кыз турында китап чыгару<br>-әңгәмә үткәрү( Беренче галәмчеләр. Аларга багышлап куелган урам исемнәре) |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -ракета төзү | -балаларның күзаллауларына таянып хикәя төзеп сөйләүләре<br>-фотолар карау |
| **Яз һәм хезмәт бәйрәме** | Яз һәм хезмәт бәйрәме яз килүне белдерә.1 нче май бәйрәме һәнәр ияләренең бәйрәме<br><br>. | **майның 1 нче атнасы** | “хезмәт десанты”(мәйданчыкны җыештыру)<br><br>-табигатьне саклау акциясе үткәрү<br><br>-“Яз бәйрәме” күңел ачу<br><br>-һөнәр турында әңгәмә | **5-6 яшь**<br>Хезмәт, хезмәт кешесе турында беренчел караш формалаштыру.Яз кәефе булдыру.<br>-с/р уен хезмәткә багышланган<br>-хезмәт кешеләренә багышланганҗырлар тыңлау<br>-матур әдәбият уку<br>-мәкаль-әйтемнәр белән танышу<br>-зурларга булышу<br>-зурлар эшчәнлеген күзәтү<br>- һөнәрләр турында китап чыгару |
| **Җиңү көне** | Туган ил дигән төшенчәне аңлату, Җиңү бәйрәме белән таныштыру. Ветеранннарга хөрмәт күрсәтү, зурларны рәнҗетмәү.Безнең туган илебезне саклаучы хәрбиләргә хөрмәт тәрбияләү.<br><br>: | **Майның 2 нче атнасы** | -курсәткеч материаллардан күргәзмә<br><br>-“Әлемнәр” рәсем күргәзмәсе<br><br>-“ Җиңү бәйрәме белән “ дигән открыткалар ясау<br><br>-көч сынашу<br><br>-Бәйрәм кичәсе<br><br>-Җиңү ял үзәгенә сәяхәт<br><br>-геройлар турында фильм карау<br><br>-сугыш техникасына күргәзмә | **5-6 яшь**<br>-с/р уен “Ветераннар өчен кичәгә әзерләнү”, “Чик сакчылары”<br>-Җиңү көненә караган маркалар, значоклар белән танышу<br>-матур әдәбият уку<br><br>-батырлык турында мәкаль-әйтемнәр ятлау<br>- “ Җиңү бәйрәме белән “ дигән открыткалар ясау<br><br>-сугыш техникасына күргәзмә |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -“Минем бабам сугышта булган” фоторәсемнәр төшкән альбом ясау<br><br>Шөгыль”Җиңү бәйрәме иң олы бәйрәм” (сөйләм үстерү буенча) | |
| **ПДД<br>Юл йөрү кагый дәләре** | Юл йөрү кагыйдәләре турында беренчел караш формалаштыру, ГАИ хезмәткәрләре һөнәре турында күзаллау, юл йөрү кагыйдәләрен саклау.<br><br>Юлда сак йөрү, Юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту. | **майның<br>3 нче атнасы** | -“ПДД” атналыгына нәтиҗә<br><br>-дидактик уеннар<br><br>-җәяүлеләрне күзәтү<br><br>-спорт күңел ачу бәйрәме<br><br>-“Юл куркынычсызлыгы” эти-әниләр белән бергәләп кул эшләрен ясау<br><br>-ГАИ хезмәткәрләре белән очрашу<br><br>-“Юл” күңел ачу<br><br>-курчак театры” Белмәмнш – җәяүле”<br><br>викторина “Җәяүле урамда”<br><br>рәсемнәр күргәзмәсе “Минем шәһәр урамым”<br><br>-өстәл театры” Билгене тап һәм кирәк урынга куй”<br><br>-КВН “ Юл йөрү әлифбасы” | **5-6 яшь**<br>-с/р -уен “Автобуста сәяхәт” ,”Юл”<br>-күзәтү<br>-матур әдәбият уку<br>-картина һәм рәсемнәр карау<br>-табышмаклар уйлап табу һәм чишү<br>-д/у-“Үз билгеңне тап” “Светофор”, “Юл билгеләре”<br>-танып-белү өлкәсе буенча викторина<br>-“Урам “ кулдан макет төзү<br>-автоүзәк, светофор төзү<br>-диафильм карау |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Куркы-нычсызлык дәресләре** | Куркынычсызлык кагыйдәләре осталыкларын формалаштыру һәм үстерү, урамда һәм юлда куркынычсызлык кагыйдәләрен дөрес үтәүне тәрбияләү, бер-берeңне һәм зурлар сүзенә колак салу. Юл йөрү һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен ныгыту. Фаҗигага эләккәндә бер-береңә булышу теләге уяту. Иптәшләреңһәм зурлар белән билгеле булган кагыйдәләрдән чыкмаска өйрәтү, куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәтү. Табигаттә үз-үзеңне тота белү, куркыныч янаганда фаҗигадән кача белү, кемне дә булса коткара белүне ныгыту. | **майның 4 нсе атнасы** | -җәйге мәйданчыкка сәяхәт<br><br>-кул эшләре күргәзмәсе<br><br>-әти-әниләр өчен таләпләр" Җәйге куркынычсызлык"<br><br>-"Су белән уеннар" күңел ачу<br><br>Шөгыль " Бәла килсә ничек чыгарга?"<br><br>-викторина " Бәлагә юлыксаң..."<br><br>-"Сак бул!" күңел ачу | 5-6яшь<br>с/р уен "Өй", " Ашыгыч ярдәм", "Коткаручылар", " Юл сакчылары"<br>-эчтәлек буенча әкият сәхнәләштерү,<br>-эчтәлек буенча рәсемнәр карау<br><br>- педагогик хәл " Ишектә таныш түгел кеше"<br>-"Агулы гөмбәләр", "Гадәттән тыш хәлләр" тәрбияче белән әңгәмә |
| **Исәнме,җәй! Бөтендөнья балаларны саклау көне** | 1 нче июнь- иң олы бәйрәмнәрнең берсе. Беренче тапкыр бәйрәм 1950 нче елда билгеләп үтелә. ООН бу бәйрәмне иң үзенчәлекле көн итеп билгеләдә,бу көнне балаларның сәламәтлекләренә зур игътибар бирелә. Кечкенә балаларны зурлар саклый, кайгырта. Җәй фасылы турында белемнәрне ныгыту. | **майның 5 нче атнасы** | -балалар хокукларын яклау турында әңгәмә<br><br>-"Бала хокуклары" почмагы<br><br>-тәм-том ярминкәсе<br><br>-күңел ачу<br><br>-асфальтта рәсемнәр ясау<br><br>-"Балаларны саклау көненә" багышлап бәйрәм оештыру<br><br>Шөгыль "Җәй бүләге" | **5-6 яшь**<br>-с/р уен "Сәяхәт", "Юрист киңәше"<br>Үстерелешле уеннар "Ял иткәндә гадәттән тыш хәлләр"<br>-әңгәмә<br>-глобус, карта карау<br>- Юл билгеләрен искә төшерү"Балалар" , "Җәяүле кеше", Йөрү тыела"<br>;-проект эшчәнлеге ( кәгазьдән торна ясау, куркынычсызлык турында роликлар карау)<br>-өстәл уены "Дөрес-дөрес түгел"<br>-рәсем ясау асфальта<br>-матур әдәбият уку<br>-балаларга багышланган җырлар тыңлау<br>-юл йөрү кагыдәләренә багышланган викторина |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | -“Балачак иле”күңел ачу<br><br>-рәсемнәр күргәзмәсе “Без дуслар” | |
| **Бөтендөнья ба-ларны саклау көне** | 1 нче июнь- иң олы бәйрәмнәрнең берсе. Беренче тапкыр бәйрәм 1950 нче елда билгеләп үтелә. ООН бу бәйрәмне иң үзенчәлекле көн итеп билгеләде,бу көнне балаларның сәламәтлекләренә зур игътибар бирелә. Кечкенә балаларны зурлар саклый, кайгырта. Җәй фасылы турында белемнәрне ныгыту. | **1 июнь** | -балалар хокукларын яклау турында әңгәмә<br><br>-“Бала хокуклары” почмагы<br><br>-тәм-том ярминкәсе<br><br>-күңел ачу<br><br>- | **5-6 яшь**<br>-с/р уен “Сәяхәт”, “Юрист киңәше” Үстерелешле уеннар “Ял иткәндә гадәттән тыш хәлләр”<br>-әңгәмә<br>-глобус, карта карау<br>- Юл билгеләрен искә төшерү”Балалар” , “Җәяүле кеше”, Йөрү тыела”<br>;-проект эшчәнлеге ( кәгазьдән торна ясау, куркынычсызлык турында роликлар карау)<br>-өстәл уены “Дөрес-дөрес түгел”<br>-рәсем ясау асфальта<br>-матур әдәбият уку<br>-балаларга багышланган җырлар тыңлау<br>-юл йөрү кагыйдәләренә багышланган викторина |
| **Рәсәй көне** | Рәсәй көне 2002 нче елдан башлап үткәрелә .Ул иң яшь бәйрәмнәрдән санала.Рәсәй көне-азатлык бәйрәме, тынычлык бәйрәме булып санала. Бу бәйрәм-милли берләшү,Рәсәй өчен җаваплы халык булуыбызны күрсәтә | **12 июнь** | Халыклар дуслыгы көне буеча | **5-7 яшь**<br>-с/р уен “ Рәсәй буйлап сәяхәт”, “ Сайлаулар”<br><br>- туган як музеена сәяхәт<br><br>-проект эшчәнлеге(Рәсәй картасын ясау, авылны шәһәрне күрсәтү)<br><br>-Әңгәмә( Рәсәй башкаласы, символы, бәйрәмнәре, сайлаулар, күренекле кешеләр,урыннар,Рәсәй армиясе |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | - әдәбият белән танышу<br><br>-карта, рәсемнәр, репродукцияләр карау<br><br>-шигырьләр, җырлар өйрәнү, тыңлау, ятлау<br><br>-танып –белү буенча викторина<br><br>-хезмәт(Рәсәй әлеме, милли киемнәрен тегү)<br><br>-шәһәрләр һәм күренекле урыннары турында сөйләү<br><br>-табышмаклар төзү һәм чишү<br><br>Рәсәй гимнын өйрәнү |
| Бөтендөнья дуслар көне | Аристотель :”Дус ул бер җан, ике тәндә яшәүче”. Барлык халыклар дуслыгы элек-электән җитди мөнәсәбәтләргә бәйләнгән булган. Дуслар көне , нинди генә мөнәсәбәттә булуга карамастан, аларны хөрмәт итәргә өнди. | **июньнең 3-4 нче атнасы** | -“ Барлык ил балалары дуслыгы”плакатлар конкурсы<br><br>-төркем фотолары төзү “Без дус балалар”<br><br>-“Дуслык” күңел ачу | **5-7 яшь**<br>-әңгәмә.педагогик ситуация ( дуслар табу, дуска булышу, бүләкләр ясау, комплиментлар әйтү, игымлы итеп сөйләшү)<br><br>-“ Дус бәладә булыша” портрет ясау<br>-<br>эчтәлеге буенча уеннар уйнау<br><br>- “Нинди әкият герое белән дуслашыр идед?” әңгәмә<br><br>-дустың турында кечкенә генә хикәя сөйләү<br><br>-сүзле дидактик уенар “Дуслык сүзләре” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ГАИ Хезмәткәрләре көне | 60-нчы елларда безнең ил Бөтен дөнья юл йөрү конвенциясенә кушылды,ә беренче юл йөрү кагыйдәләре 1961 нче елның беренче гыйнварыннан кабул ителде.<br>ГАИ хезмәткәрләренең төп максаты җәяүлеләрнең һәм машина йөртүчеләрнең куркынычсызлыгы. | **Июльнең 1 нче атнасы** | -ГАИ хезмәткәрләре белән очрашу<br><br>-“ПДД”атналыгына нәтиҗә<br><br>-дидактик уен-викторина(юл йөрү кагыйдәләре буенча. | 5-7 яшь<br><br>-с/р -уен “Автобуста сәяхәт” ,”ГАИ”<br>-күзәтү<br>-матур әдәбият уку<br>-картина һәм рәсемнәр карау<br>-табышмаклар уйлап табу һәм чишү<br>-д/у-“Үз билгеңне тап” “Светофор”, “Юл билгеләре”<br>-танып-белү өлкәсе буенча викторина<br>-“Урам “ кулдан макет төзү<br>-автоүзәк, светофор төзү<br>-диафильм карау |
| **Рәсәй почтасы көне** | Почта турында белешмәләр меңеллык<br>язмаларда очрый,әмма почта бәйләнеше Бөек Петр заманыннан ук килә. 1994 нче елдан Рәсәй почтасы көне билгеләп үтелә. Почта хәзерге көндә тиз акча күчерү, фатир өчен түләү, посылка җибәрү, төрле түләүләр башкара. Почта хезмәткәрләре бик күп хатлар-гәҗитләр тарата. | **Июльнең 2-3 атналары** | -почта бүлекчәсенә сәяхәт<br>-с/р уен “Почта”<br>- Хат язу<br><br>- | **5-7 яшь**<br>Почта турында беренчел караш форма-лаштыру, кешеләр арасындагы бәйләнеш , почта хезмәткәрләренә яхшы мөнәсәбәт тудыру<br>-с/р уен “Почта”, “Интернет-кафе”<br>-эчтәлеге буенча табышмак төзү һәм чишү<br>-матур әдәбият уку<br>-хат, телеграмма карау<br>-почта хезмәткәре турында тәрбияче сөйләме<br>-открыткалар. Посылкалар ясау<br>-проект эшчәнлеге( хат язу, башка балалар бакчасына посылка салу)<br>-хезмәт(конверт ясау. Маркалар җыю, гәҗит-<br>.журналлар төзү)<br>-“Простаквашинодан хат” дигән темага мультфильм карау<br>-үстерелешле уеннар ”Һөнәрләр” , “ Туган |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | сүзен тап”. |
| **Физкультура эшчеләре көне** | Бу бәйрәм 20 нче гасырның уртасында” Сәламәт тәндә –сәламәт акыл “дигән фикер белән кереп калды. Спорт белән шөгыльләнүчеләр иң популяр кешеләр булып саналалар. Барлык бәйрәмнәр дә спортчылар белән үтә. Инстиут һәм университетларда спорт факультетлары ачыла башлады, соңрак физ-ра инстиутлары ачыла башлый. | **августның 1 нче атнасы** | -спорт чаралары,ярышу,уеннар,конкурслар | **5-7 яшь**<br>Физкультура сәламәтлекне саклаучы чараларының берсе буларак формалашуын күзаллау.<br>-с/р уен “Олимпиада”<br>-коллекция туплау( җәйге һәм кышкы уен төрләре)<br>-хәрәкәтле уеннар<br>-җырлар тыңлау<br>-“Олимпиада уеннары өчен яңа уен төрләре” уйлап табу<br>-проект эшчәнлеге( спорт костюмнары уйлап табу. Медаль өчен рәсемнәр ясау)<br>- физкультурага кагылышлы җырлар тыңлау<br>-“Минем яраткан спорт уеным” әңгәмә<br>-матур әдәбият уку |

**1.1«Социализация» укыту эшчәнлеге буенча перспектив план**

| ***Исеме*** | ***Содержание и объем игровых умений и навыков*** | ***Методикалымнар*** |
|---|---|---|
| | ***Сентябрь*** | |
| **«Гаилә»** | Алмаз өй эчен тәртипкә китерә Алмаз кунакларны каршы ала һәм өйгә керергә чакыра, өстәл артына утырта. . Кунаклар сыйланалар һәм хуҗага рәхмәт әйтәләр, туган көне белән котлап бүләк тапшыралар. Малайлар музыка коралларында уйныйлар, кызлар бииләр. Соңыннан зурлар малайларга уенчык машина , кызларга көзге белән тарак бүләк итәләр. Кунаклар сый-хөрмәт өчен рәхмәт әйтеп кайтып китәләр. Хуҗалар кунакларны озаткач өйдә тәртип ясыйлар. | **Әңгәмә "Үзеңнең гаиләң турында сөйлә, гаиләдә нинди милли традицияле бар" ," Гаилә нинди киемнәр кия".** **Матур әдәбият уку:** Дуйсенбаева А. «Елга буенда», «Җәй» |
| **«Кибет»** | Әни белән кыз кибеткә килеп ашамлыклар алалар. Сатучы берәмләп әйберләр сата, үлчәүдә яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр үлчи. Сатучы матур итеп сатып алучылар белән сөйләшә. | **Әңгәмә: "Нәрсә ул кибет?" Рәсем карау: "Кибет" темасына: балалар кибет турында нәрсә беләләр, ничек уйнап була, кибетле уйнау өчен нәрсә кирәк , эти-әниләр белән кибет өчен нәрсәләр ясап була.** |
| **«Машина йөртүчеләр»** | Диспечер машина йөртүчеләргә путевка битләре өләшә, машина йөртүче юлга чыга, машинасын тикшерә, бензин сала, вакытында йөкне илтеп тапшыра. | Матур әдәбият уку: В. Сутеев "Төрле тәгәрмәчләр". Әңгәмә: Кемнең эти-әнисенең машинасыбар? Кемнәр ул машина йөртүчеләр? Алар нәрсә эшлиләр? |
| **« Шифаханә»** | Авыру табибка кабул ителергә языла, үзенең авырулары турында сөйли, дәвалауларын сорый, рәхмәт әйтә. Табиб тыңлый, тамак төбен карый, рецепт язып бирә. | **Матур әдәбият уку: К. Чуковский "Айболит". Эшчәнлек: рецепт язып бирү, карточка, атрибутлар. Дарулар, даруханә кирәк-яраклары.** |
| | ***Октябрь*** | |
| **«Гаилә»** | Әни юа, кер үтүкли, бүлмә җыештыра, кызын ашата, йокларга яткыра. | **Матур әдәбият уку:** Д.Габе «Минем гаиләм», «Абыем» **Әңгәмә: "Кунакта нәрсә эшлибез", "Без нигә кунакка йөрибез", "Мәкальләрне аңларга тырышабыз",-әниләр турындагы мәкальләрнең мәгьнәсен аңлатабыз.** |
| **«Төзүчеләр»** | Заказчик төзүче фирмага заказ бирә, төзү урынын билгели, | **Матур әдәбият уку** С Баруздин «Кем өйне салган?» |

| | | |
|---|---|---|
| | кайда, нәрсә төзергә кирәклеген аңлата, рәхмәт әйтә. | **Әңгәмә: Кем өй төзи, нинди төзүче һөнәрләре беләсез?** |
| **Корпорация «Билайн»** | Кәрәзле телефоннарны рекламалау, сату нокталары, реклама буклетлары, төрле журналлар тарату. | **Матур әдәбият уку:**<br>К И Чуковский «Телефон»<br>Нәрсә ул "Билайн?" "Нәрсәгә кирәк кәрәзле телефоннар?" |
| **«Кибет»** | Машина йөртүче товар алып кайта, машинага төйи һәм , бушата, товарны ала һәм бирә , саный һәм кәгазьдә билгели. Сатучылар товарны алалар, киштәләргә тезәләр, сатып алучыларны кабул итәләр. | **Әңгәмә: кибеттә нәрсәләр алабыз?** |
| | **Ноябрь** | |
| **«Гаилә»** | Әти- машина йөртүче, бензин сала, кубикларны төзелешкә илтә. Әни гаиләне кайгырта, төшке аш әзерли , балаларны ашата, йокларга яткыра. Кыз чирләгән һәм әни аны табибка алып бара | **Рәсем карау.**<br>Әңгәмә: «Әти кайда эшли», "Берәрсе чирләсә нәрсә эшләргә?"<br>Б. Заходер «Машина йөртүче».<br>**Дидактик уен: "Бер сүз белән әйт"** |
| **«Төзелеш»** | Төзүчеләр өй , гараж төзиләр, бизиләр бәйрәмгә. | Рәсем карау. Уку:Б. Заходер «Төзүчеләр». |
| **«Ашыгыч ярдәм»** | Машина йөртүче авырулар өчен кирәк-яраклар һәм дарулар йөртә, табиб белән бергә ашыгыч ярдәм күрсәтә. | **Рәсем** «Ашыгыч ярдәм»<br>**Матур әдәбият уку:**К.Чуковский «Айболит» |
| **«Юл инспекциясе»** | Инспектор юл хәрәкәтен **билгели, документ тикшерә,кагыйдә бозучыларны тикшерә, штраф сала.** | **Әңгәмә:" Юл полициясендә кемнәр эшли?", "Нәрсә ул юл полицициясе?", " Юл полициясе ничек киенә?"** |
| | ***Декабрь*** | |
| **«Шифаханә»** | Күз табибы авыруларны кабул итә, күз күремен тикшерә, дәвалый, эшкә яраксызлык кәгазен бирә. | **Матур әдәбият уку:**<br>М Алимбаев «Кем дәвалый?»<br>**Дидактик уен:**<br>«Эшләү өчен нәрсә кирәк?» |
| **«Тегү йорты»** | Кием кисүчеләр үлчәм ала, кисә; Кабул итүче заказ ала, вакыт билгели; Тегүче тегә һәм кигертеп карый. | **Матур әдәбият уку:**<br>«Батыр тегүче» - Братья Гримм<br>**Дидактик уен:**<br>«Алсуны киендерәбез» |

| | | |
|---|---|---|
| **«Төзелеш»** | Эш бирүче төзүче фирмага заказ бирә, төзү урынын билгели, кайда, нәрсә төзергә кирәклеген аңлата, рәхмәт әйтә.<br>Дизайн ясаучы төзелеш өчен урын тәкъдим итә, эш бирүче белән төзелеш планын сөйләшә. | **Матур әдәбият уку:**<br>Б. Житков «Мин нәрсә күрдем».<br>М Жаманбалинов «Сез алтын куллы кеше»,<br>С Баруздин «Бу өйне кем төзегән?» |
| **«Гаилә»** | Әни белән кыз чыршы бизиләр, әни кыз белән чәчтарашханәгә баралар,кибеттә ашамлыклар алалар, төшке аш әзерлиләр, кунак каршылыйлар | Рәсем карау “Яңа елга әзерләнү”..<br>Уку: О.Высотская «Чыршы»<br>Д/у « Аюкайга кунак каршы алу турында сөйләү» |
| ***Гыйнвар*** | | |
| **«Машина йөртүчеләр»** | Диспечер машина йөртүчеләргә путевка битләре өләшә, машина йөртүче юлга чыга, машинасын тикшерә, бензин сала, вакытында йөкне илтеп тапшыра | Матур әдәбият уку: В. Сутеев “Төрле тәгәрмәчләр”. Әңгәмә: Кемнең этиәнисенең машинасыбар? Кемнәр ул машина йөртүчеләр? Алар нәрсә эшлиләр? |
| **« Шифаханә»** | Диспансеризация: авырлык һәм буйны үлчәү, првивка ясау, витамин бирү. | Шәфкать туташының эшен карау, медицина жиһазларын карау.<br>Д/у «Аюкайга безне ничек үлчәүләре турында сөйлик әле» |
| **«Зоопарк»** | Зоопарк буеча йөртүче андагы хайваннар турында сөйли, сакчы хайваннарның оялары ябыкмы икәнлеген тикшерә, чит кешеләргә аларны ашатырга ярамаганлыгын әйтә, зоопаркны саклый. Эшчеләр хайваннарны ашаталар.<br>Гид. Проводит экскурсии по зоопарку, рассказывает о зверях | **Матур әдәбият белән танышу:**<br>С Я Маршак «Читлектәге балалар»<br>**Әңгәмә:**<br>«Зоопарк нигә кирәк?», «Кем зоопаркка барды», «Сезгә нәрсә ошады?» |
| **«Китапханә»** | Китапханәче китап алучыларны каршы ала, формуляр ача, китаплар тәкъдим итә, төрле гәҗитләр белән таныштыра. | **Әңгәмә:**<br>**Китапханә турында нәрсә беләсез, нигә кирәк ул, үзеңне китапханәдә ничек тотасың?**<br>**Китап бик кыйммәтле нәрсә. Аны сакларга кирәклеген, ертырга ярамаганлыгын әйтергә кирәк?** |
| ***Февраль*** | | |
| **«Кафе»** | Кафега сок эчәргә, туңдырма ашарга киләләр, кадул итүче заказ ала, китерә. Алар бер-берсе белән итагәтьле сөйләшәләр. | Рәсем карау. Әңгәмә «Кайчан кафега бардыгыз?».<br>Д/у«Без кафега килдек» |
| **«Балалар бакчасы»** | Балалар бакчага киләләр, аларга анда иртәнге аш, төшке аш, кичке аш ашаталар, йоклаталар. | Рәсем карау<br>Әңгәмә «Безнең төркем», «Балалар бакчасында нәрсә эшлиләр?» |

| | | |
|---|---|---|
| **«Чәчтарашханә»** | Чәчтараучылар прическа ясый, шампун белән чәч юалар, фен белән киптерәләр, чәч кисәләр, ничә сумлык эш эшләгәнен язалар, чәчне тәрбияләү буенча киңәш бирәләр. | **Матур әдәбият уку:**<br>Б Заходер «Чәчтарашчы»<br>**Әңгәмә:** Чәчтарашчы һөнәре. |
| **«Ярдәм күрсәтүчеләр»** | Ярдәм күрсәтүчеләр диспетчеры кызыл утлары булган шомлы урыннарны билгелиләр, телефоннан хәбәрләрне алалар, кайсы оешмага эшне йөклисен билгелиләр. | **Әңгәмә: “Ярдәм оешмасы нәрсә аңлата?, Анда кем эшли?, Ни өчен анда иң җитезләрне генә алалар?”** |
| ***Март*** | | |
| **«Кибет»** | Машина йөртүче товар алып кайта, машинага төйи һәм , бушата, товарны ала һәм бирә , саный һәм кәгазьдә билгели.<br>Сатучылар товарны алалар, киштәләргә тезәләр, сатып алучыларны кабул итәләр. | **Әңгәмә: “Нәрсә ул кибет?”**<br>**Рәсем карау: “Кибет” темасына: балалар кибет турында нәрсә беләләр, ничек уйнап була, кибетле уйнау өчен нәрсә кирәк , эти-әниләр белән кибет өчен нәрсәләр ясап була** |
| **«Гаилә»** | 8 нче март бәйрәме үткәрү<br>Кунаклар сыйланалар һәм хуҗага рәхмәт әйтәләр, туган көне белән котлап бүләк тапшыралар.<br>Малайлар музыка коралларында уйныйлар, кызлар бииләр.<br>Соңыннан зурлар малайларга уенчык машина , кызларга көзге белән тарак бүләк итәләр.<br>Кунаклар сый-хөрмәт өчен рәхмәт әйтеп кайтып китәләр. Хуҗалар кунакларны озаткач өйдә тәртип ясыйлар. | **Әңгәмә: “Кунакта нәрсә эшлибез”, “Без нигә кунакка йөрибез”, “Мәкальләрне аңларга тырышабыз”,-әниләр турындагы мәкальләрнең мәгънәсен аңлатабыз.** |
| **«Шифаханә»** | Авыру табибка кабул ителергә языла, үзенең авырулары турында сөйли, дәвалауларын сорый, рәхмәт әйтә.<br>Табиб тыңлый, тамак төбен карый, рецепт язып бирә. | **Әңгәмә**<br>**Табиб һөнәре турында сөйләшү, рәсем буенча табиблар турында сөйләшү**<br>**Дидактик уен:**<br>«Кем нәрсә эшли?»<br>«Кемгә нәрсә кирәк эшләү өчен?» |
| **«Төзелеш»** | Прораб кирәк –ярак төзелеш материалларын сайлый, төзелештә барлык төзү материаллары булуы өчен җаваплы, эшчеләр өстеннән | **Беседы с детьми:**<br>Төзелеш эшчеләре: ташчы, штукатур, кранчы, буяучы, самосвалчы . Алар нәрсә эшлиләр, нинди машиналар аларга |

| | | |
|---|---|---|
| | идарә итә.<br>Төзелеш материалларын эшчеләр ташый, төзиләр. | булыша. Чем занимаются, какие машины помогают им в работе<br>**Дидактик уен:**<br>«Гараж төзибез», |
| ***Апрель*** | | |
| **«Чәчтарашханә»** | Чәчтараучылар прическа ясый, шампун белән чәч юалар, фен белән киптерәләр, чәч кисәләр, ничә сумлык эш эшләгәнен язалар, чәчне тәрбияләү буенча киңәш бирәләр | **Төрле журналлар карау:**<br>«Матур прическа», «Яңача кистерелгән чәч», «Лиза»<br>Матурлык салонын рәткә китерү.<br>**Әңгәмә: чәчтарашчы һөнәре турында,** |
| **«Балалар бакчасы»** | Бакчада чистарту: юлларны себерү, чүп-чарны җыештыру, чүп чиләгенә ташлау, чиста бакчада уйнау. | Шимбә өмәсен күзәтү.<br>Әңгәмә: “Без ничек бакчаны чистарттык” |
| **«Гаилә»** | Әти- машина йөртүче, бензин сала, кубикларны төзелешкә илтә. Әни гаиләне кайгырта, төшке аш әзерли , балаларны ашата, йокларга яткыра. Кыз чирләгән һәм әни аны табибка алып бара. | **Рәсем карау.**<br>Әңгәмә: «Әти кайда эшли», “Берәрсе чирләсә нәрсә эшләргә?”<br>Б. Заходер «Машина йөртүче». |
| **«Ашыгыч ярдәм»** | Машина йөртүче авырулар өчен кирәк-яраклар һәм дарулар йөртә, табиб белән бергә ашыгыч ярдәм күрс | **Рәсем** «Ашыгыч ярдәм»<br>**Матур әдәбият уку:**К.Чуковский «Айболит» |
| ***Май*** | | |
| **«Кибет»** | Менеджер кибеттә аласы товарга реклама ясый, саттып алучыларга кирәкле мәгълүмәт бирә, сатып алучылар акча түләп , алган әйберләрен сумкаларына тутыралар. | **Әңгәмә: “Нәрсә ул кибет?”**<br>**Рәсем карау: “Кибет” темасына: балалар кибет турында нәрсә беләләр, ничек уйнап була, кибетле уйнау өчен нәрсә кирәк , эти-әниләр белән кибет өчен нәрсәләр ясап була** |
| **«Тегү йорты»** | Кием кисүчеләр үлчәм ала, кисә; Кабул итүче заказ ала, вакыт билгели; Тегүче тегә һәм кигертеп карый. | **Әңгәмә:**<br>«Мода – ул кызыклы», «Модельер булып малайлар да , кызлар да эшли ала», «Модельер- ул кызыклы күлмәк фасоннары уйлап табучы» |

| | | |
|---|---|---|
| **«Китапханә»** | Китапханәче китап алучыларны каршы ала, формуляр ача, китаплар тәкъдим итә, төрле гәҗитләр белән таныштыра. Китап алучы формулярга кул куеп китап ала. | **Әңгәмә:**<br>**Китапханә турында нәрсә беләсез, нигә кирәк ул, үзеңне китапханәдә ничек тотасың?**<br>**Китап бик кыйммәтле нәрсә. Аны сакларга кирәклеген, ертырга ярамаганлыгын әйтергә кирәк.**<br>Д/у:”Сүзне әйтеп бетер” |
| **Корпорация «Билайн»** | Кәрәзле телефоннарны рекламалау, сату нокталары, реклама буклетлары, төрле журналлар тарату, телефон сатучылар яхшы телефон тәкъдим итәләр,телефонга акча салалар, телефонга паспорт ясыйлар.Сатып алучы телефон сайлый, акча түли, акча сала. Телефон ватылса рәтләүчегә илтеп бирәләр , ул карый, тәтли. | **Матур әдәбият уку:**<br>К И Чуковский «Телефон»<br>Нәрсә ул “Билайн?” “Нәрсәгә кирәк кәрәзле телефоннар?” |

**<u>«Хезмәт» белем бирү өлкәсе </u>(«Труд»)**

«Хезмәт» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда хезмәткә уңай мөнәсәбәт формалаштыру максатын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.
Татар халык әкиятләре («Өч кыз», «Үги кыз», «Һөнәрле үл-мәс» һ. б.) ярдәмендә хезмәт эшчәнлеге турында күзаллауларынформалаштыруны дәвам итү. Балаларның игътибарын әкияттә хезмәт итүче геройларга юнәлдерү. Балаларның эш барышларын Г. Тукай шигырьләрендәге («Кызыклы шәкерт», «Шаян песи» һ. б.) юллар белән бәйләү.
Туган шәһәрдәге (авылдагы) укытучы, нефтьче, сыер савучы һ. б. һөнәр ияләре турында күзаллауларын формалаштыру. Балалар бакчасы участогында тәрбияче белән эшләгәндә, балаларның актив катнашуын булдыру: яфраклар коелгач, кулларыннан килгәнчә участокны җыештыру, шәһәрдә яшәүче кошларга өстәмә азык бирү.Гаилә бәйрәмнәренә әзерләнгәндә, өлкәннәргә кулларын-
нан килгәнчә булышу, өйдә үз вазифаларын үтәүгә тарту.**<u>«Труд»</u>**
Образовательные задачи:

- расширять и систематизировать представления детей о труде и профессиях людей; показать связи между разными трудовыми действиями и их результатами в производственных цепочках;
- содействовать дальнейшему развитию интереса к содержанию и значению трудовой деятельности взрослых, углублять представление о социальной ценности труда и его результатов;
- продолжать приобщать к разным видам индивидуального и коллективного труда;.

содействовать овладению культурой трудовой деятельности: выполнять работу качественно, аккуратно, своевременно, ответственно; правильно использовать инструменты и материалы; замечать ошибки и быстро исправлять по своей инициативе; • знакомить со структурой трудовой деятельности: учить принимать и ставить цель, определять мотив, планировать последовательность действий, оценивать результат

| Укыту эшчәнлегенең формасы | |
|---|---|
| **Режим моментларда** | **Балаларның үзаллы эшчәнлеге** |
| **Балаларны оештыру формасы** | |
| Индивидуаль<br>Өлешчә группа белән<br>Группа белән | Индивидуаль<br>Өлешчә группа белән |
| • Бергәләп эшләү<br>• Күзәтү<br>• Тапшырылган эш<br>• Әңгәмә<br>• Уку<br>• Тематик яктан зурлар белән балаларның эшчәнлеге<br>• Карау<br>• Дежур итү<br>• Уен<br>• Экскурсия<br>• Проект эшчәнлеге | • Тиешле предметлы-үстерүле мөһитне булдыру<br>• Барлык төрдәге үзаллы балалар эшчәнлегендә |

**«Хезмәт» укыту өлкәсендә перспектив план**

| Тема | Эшчәнлек | Методик алымнар. Шөгыльгә материаллар. |
|---|---|---|
| I.Зурларның эше белән танышу.<br>. | Балаларга кешеләрнең хезмәте һәм һөнәре турында киңәйтеп һәм системалаштырып күзаллауларын булдыру. Алар арасындагы хезмәт гамәлләре һәм аларның нәтиҗәләрен җитештерү чылбырында күрсәтү. | Балалар бакчасында зурларның эшчәнлеген күзәтү.<br>Тәрбиячēнең зурлар хезмәте турында сөйләме.С/р уен: “Балалар бакчасы”, “Гаилә”, Яшелчәләр кибете”.<br>Логик экран белән эшләү. |
| «Пешекче». | Балалар бакчасында пешекченең эшчәнлеге :иттарткычта ит чыгара, котлет пешерә, яшелчәләр турый, аш пешерә, ботка пешерә. Пешекченең аш бүлмәсендә булышчылары- төрле машиналар . | Аш бүлмәсенә экскурсия.<br>Пешекченең рәсемен карау<br>Әңгәмә:” Аш бүлмәсендә без нәрсә күрдек?”<br>Д/у: “Нәрсәдән пешерелгән?”, “ Пешерер өчен нәрсә кирәк?”. |
| «Табиб». | Балалар бакчасы табибы һәм шәфкатҗ туташының эше: фонендоскоп белән тыңлый, температура үлчи, авырлык, буй үлчи, дарулар бирә, тырналган урынны буйый һәм бәйли.<br>. | Күзәтү<br>Медицина җиһазлары төшкән рәсемнәр карау .Әңгәмә:”Табиб бүлмәсендә без нәрсә күрдек?<br>С/р-уен:”Балалар бакчасы- табиб бүлмәсе”. |

| | | |
|---|---|---|
| «Машина Йөртүче». | Машина йөртүченең эше җәмәгать урыннарында: ашамлыклар ташый, кешеләрне йөртә, машинаны карап тора, бензин сала, рәтли, Юлда кагыйдәләрне бозмыйча йөри. | Максатлы йөрү: урамны, светофорны күзәтү.<br>Әңгәмә:” Шәһәр буйлап без нәрсәдә йүрибез?”, “ Кем безгә ашамлыклар ташый?”<br>Д/У:”Лото”, “Тап һәм әйт” .<br>Логик экран(“Һөнәрләр белән танышабыз”). |
| «Кер юу бүлмәсе». | Кер юучының балалар бакчасында эшчәнлеге- эзлеклелек, нәтиҗә.<br>. | Кер юу бүлмәсенә экскурсия.<br>Әңгәмә:”Без ничек кер юучыга булыша алабыз?” Продуктив эшчәнлек: сөлгеләрне алыштыру, курчак киемнәрен юу. |
| «Сатучы». | Сатучының эшләү рәвеше- эзлеклелек, нәтиҗә. | Кибеткә бару.<br>Әңгәмә:” Кибет киштәсендә нәрсәләр бар?”<br>С/р уен: «Кибет». |
| «Чәчтара-учы». | Чәчтараучының эшләү рәвеше- эзлеклелек, нәтиҗә. Үз эшеңә жаваплы карау. | Берәр баланың әнисенең чәчтараучы эшчәнлеген күрсәтү.<br>Чәчтараучы эше турында сөйләү.<br>Д/у: « Бантикны бәйлә», «Курчакның чәчен үрик”». |
| Кешеләрнең эше. | Әниләрнең эштә ничек авыр икәнлеген аңлату, эштә алар нәрсә эшләгәнен сөйләү, аларның эшен хөрмәтләү. | Гаилә әгъзәләренең кайда һәм нәрсә эшләүләрен сөйләү. Һәр кешенең бу җәмгыятьтә тоткан урыны.<br>Әңгәмә: “Безнең әниләр”<br>С/р уен: «Әниләр бәйрәме», «Гаилә». |
| «Музыка җитәкчесе». | Музыка җитәкчесенең эшчәнлеге- балаларга яхшы мөнәсәбәте. | Әңгәмә: Музыка җитәкчесенең эшчәнлеге<br>Д/у: «Эшләү өчен кегә нәрсә кирәк?».<br>Логик экран ( «Һөнәрләр белән таныәу») №1. |
| «Физкульту-ра җитәкче-се». | Физкультура җитәкчесенең эшчәнлеге- балаларга яхшы мөнәсәбәте | Әңгәмә : Физкультура җитәкчесенең эшчәнлеге:<br>Д/у: «Кем нәрсә эшли»Логик экран ( «Һөнәрләр белән таныәу») №5.. |
| **II. Үзаллы эшчәнлек.** | Зурларның хезмәт эшчәнлегенең эчтәлегенә һәм кирәклелегенә кызыксыну уятуны үстерүдә ярдәм итү, хезмәтнең нәтиҗәсе һәм социаль кыйммәтлелеге турында белемнәрне арттыру. | Рәсем карау. Әңгәмә. Уенчыклар белән уйнау.<br>Д/у. |
| 1.Туклану. | Чиста ашау, тавышланмыйча эчү. | Д/у «Карлсонга ничек дөрес ашарга кирәк икәнен әйтербез».<br>Уку:С.Капутикян «Маша ашый». |
| 2.Туклану . | Пычак, чәнечке, салфетка белән дөрес эшләү. | Рәсем карау.<br>Уенчык җиһазлары белән уйнау.<br>Әңгәмә: «Без ничек һәм кайчан салфетка кулланабыз». |

| | | |
|---|---|---|
| | | С/р уен: «Гаилә». |
| 3.Туклану. | Ашагач авызны чайкату. | Күрсәтү,күнегү,аңлатма.<br>Әңгәмә: «Ашагач нигә авызны чайкатырга кирәк». |
| 4. Киенү-чишенү. | Тиз дөрес итеп рәттән чишенә һәм киенә белү, кием шкафына киемнәрне дөрес урнаштыру, матур итеп төреп кую, төймәләрне каптыру,төймәләү. | Әңгәмә: «Кием-салымнарда тәртипсез-лек». Д/у: «Уенчыкларга безнең киемнәр кайда булырга тиеш-искә төшерәбез». |
| 5. Юыну. | Кечкенә төркемдә алган күнкмәләрне ныгыту. | Әңгәмә: «Юыну бүлмәсендә үзеңне ничек тотарга?».<br>Д/у: « Ничек кулны дөрес итеп сөртетргә кирәклеген күрсәтик». |
| 6. Юыну. | Үзеңнең тарагың белән чәч тарауны ныгыту. | Тәрбияченең шәхси-гигиена күнекмәләре турында сөйләме |
| 7.Юыну. | Кульяулык белән борын сөртү күнекмәләрен ныгыту., төчкергәндә читкә карау, авызны ябу | Тәрбияче сөйләме"Төчкергәндә һәм йөткергәндә без нәрсә эшлибез".<br>Д\у: «Аюкайга ничек дөрес төчкерергә кирәклеген сөйләү». |
| 8. Өс һәм аяк киемен тәртиптә тоту. | Өске кыяфәтне чиста тоту күнекмәләрен ныгыту. | Эшне күрсәтү. Өс киемнәрен тәртиптә тоту турында тәрбияче сөйләме. |
| 9. Эш урынын тәртиптә тоту. | Эш урынын тәртиптә тотуны ныгыту, йокыдан соң үз урыныңны җыештыру. | Эшне күрсәтү. Эш урынын тәртиптә тоту турында тәрбияче сөйләме. |
| **III. Хуҗалык көнкүреш хезмәте** | Индивидуаль һәм күмәк хезмәткә җәлеп итү. Мәдәният хезмәт эшчәнлеге өйрәнүдә ярдәм итү.:сыйфатлы, пөхтә итеп, үз вакытындаҗаваплы үтәү. Хаталарны табып үзе төзәтә белүне булдыру. | Күрсәтү,күнегү,аңлатма<br>Әңгәмә.<br>Д/у. |
| 1. Төркемдә тапшырылган эш. | Тузан сөртү, уенчыкларны урынына алып кую, тәртип урнаштыру. | Эшләп күрсәтү, аңлату, кушу.<br>Д/у: « Без булдырабыз». |
| 2.Мәйданчыкта тапшырылган эш | Мәйданчыктагы юлларны себерү, чүп җыю һәм түгү. | Әңгәмә: «Нигә эшләргә кирәк?».<br>Д/у: «Без яхшы эшли беләбез». |
| 3. Дежур итү. | Ашау бүлмәсендә дежур торуны ныгыту, ашап туйгач тәлинкәләрне җыеп алу. | Күрсәтү,күнегү,аңлатма<br>Әңгәмә.<br>Д/у: «Без хәзер дежур торабыз». |
| 4. Дежур итү. | Шөгылгә кирәкле әйберләрне әзерләү. | Д/у: «Шөгыльгә кирәкле әйберләрне без үзебез әзерлибез». |

| | | |
|---|---|---|
| 5. Зурлар белән бергә эшчәнлек. | Курчак киемен юарга өйрәтүне дәвам итү. | Эшләп күрсәтү.Әңгәмә: кеше өчен эшләүнең файдасы |
| 6. . Зурлар белән бергә эшчәнлек. | Уенчык савытларын рәтләү, китапларны ябыштыру. | Эшләп күрсәтү.Әңгәмә: кеше өчен эшләүнең файдасы |
| 7. . Зурлар белән бергә эшчәнлек. | Бакча яшеньдәге балалар-тату балалар. Тәрбияче белән бергә эшләүне дәвам итү. | Эшләп күрсәтү.Әңгәмә: кеше өчен эшләүнең файдасы |
| 8. Гендер буйсыну | Балаларны бер-берсен хөрмәтли белергә тиешлекләрен аңлату.<br>. | Тәрбияченең зурларны , кечкенәләрне, бер-береңне хөрмәтли белергә кирәклеге турында сөйләме. |
| 9. Гендер буйсыну. | Рәсем: «Минем йолдызлы гаиләм». | Туганнар, зурлар турында әңгәмә. |
| **IV.Табигать тә эш.** | Хезмәт эшчәнлеге тәртибе белән таныштыру, максатны куя белү,гамәлләр тәртибен планлаштыру,нәтҗәне бәяләү. | Рәсем карау.Әңгәмә.Д/у. Максатлы прогулка |
| Сентябрь | Зурларның бакчада һәм түтәлдә эшләрен күзәтү. Орлык ,чәчәк җыюда катнашу. | Д/у: «Түтәлдә нәрсә үсә?». |
| Октябрь. | Бакчаны кышка әзерләүне күзәтү. | Әңгәмә: «Көзге бакча». |
| Ноябрь. | Үсемлекләрне кышка әзерләүне күзәтү: куакларның җирен йөмшарталар, өсләрен ябалар, коелган яфракларны җыялар. | Әңгәмә: «Мәйданчыкны кышка әзерләү». |
| Декабрь. | Йорт хайваннары турындагы белемнәрне ныгыту, кешеләрнең кайгыртучанлыкларын искә төшерү, кар чистарткыч машинасын күзәтү. | Максатлы прогулка.Рәсем карау. Әңгәмә:"Йорт хайваннары турында нәрсә беләсез?" |
| Гыйнвар. | Урманчы хезмәте турында сөйләү: кар күп яуганда урмандагы хайваннарга печән һәм төрле азык илтәләр. | Рәсем карау. Тәрбияче сөйләме.<br>Уку: Е. Чарушин «Митяның дуслары». |
| Февраль.. | Җыештыручыларны күзәтү.( кар көри, комны юлларга сибә). | Урамга чыгу: кар көрәргә булышу. |
| Март. | Агачларны кисүне күзәтү. Берничә ботакны төркемгә алып кереп, яфрак яруларын күзәтү. | Ботакларны күзәтү.<br>Әңгәмә: «Ничек без ботакта яфрак ярганын күзәттек». |

| | | |
|---|---|---|
| Апрель. | Балалар белән бергәләп чәчәкләр түтәлендә эшләү. | Әңгәмә: «Балалар бакчада ничек эшләделәр». |
| Май. | Агач утыртуны күзәтү, үсемлекләрнең ничек үсүләре турында карашларын булдыру. | Әңгәмә: «Үсемлекләрнең ничек үсүләрен аңлату». |

**«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе**(«Безопасность»)

«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсе эчтәлеге үз тормышыңның куркынычсызлыгы нигезләрен һәм экологик аң (әйләнә-тирә дөнья куркынычсызлыгы) алшартларын формалаштыру максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

**Тормыш куркынычсызлыгы нигезләрен формалаштыру**

Балаларда мөстәкыйльлек, җаваплылык хисе үстерү; тормыш һәм сәламәтлекләрен саклау өчен, үз-үзеңне дөрес тотуның әһәмиятен аңлауларына ирешү.Таныш булмаган кешеләр белән мөмкин булган һәм очраклы очрашулар һәм аралашу барышында балаларда үзләрен ничек тотарга кирәклеге турында ачык күзаллау булдыру. Таныш булмаган кеше белән үзең генә калу һич тә ярамавына һәм куркынычлыгына игътибарларын юнәлтеп, балалар белән шундый очраклы очрашулар вакытында килеп чыккан хәлләрне бергәләп карау һәм фикер алышу.

**Юлларда хәвеф-хәтәрсез йөрү тәртибе формалаштыру**

Хәрәкәт юнәлешен (сүзле яки җаваплы) сигнал буенча алыштырып, «үзеңнән» һәм «үзеңә таба», бирелгән юнәлештә хәрәкәт итү; бер урыннан икенче урынга мөмкин булган күчешләр турында килешеп, әйләнә-тирәне үзләштерү; уен барышында объекттан (хәрәкәт итүче машина, поезд) хәрәкәт чагыштырмалылыгын билгеләргә өйрәтү.Әйләнә-тирәдәге предметларның бер-берсенә карата булган урыннарын мөстәкыйль ачыклый белүләренә ирешү: өстенә – өстендә, буенча – астында, сулда – уңда, артында – алдында, янында, янәшәсендә, арасында, уртасында, өстәрәк – астарак. Тирә-юньдәге кешеләр һәм предметлар арасында үзеңнең торган урыныңны билгеләү күнекмәләре үстерү.Светофорның төсләрен (ике яклы, җәяүле өчен), «Балалар», «Хәрәкәт тыела», «Җәяүлеләрнең хәрәкәте тыела», «Велосипедлар хәрәкәт итү тыела», «Велосипед юлы», «Хастаханә» һ. б. юл хәрәкәте билгеләренең зурлыгын, төсен һәм формасын, регулировщик таягының төсен ачыклау нигезендә, сенсор сиземләү күнекмәләре формалаштыру.Балаларга югары куркынычлык зоналары турында сөйләү. «Тайгак юл», «Куркыныч борылыш», «Юл эшләре», «Кыргый хайваннар», «Шлагбаумлы тимер юл чаты» һ. б. кисәтүче юл билгеләре белән таныштыру, аларның охшаш һәм аермалы якларына игътибар итү.Балаларны берничә полосалы хәрәкәт булган юлны чыгу алгоритмы белән таныштыру; юлларда, юл аркылы чыкканда, тәртипкә салына торган урам чатларын чыкканда ориентлашырга күнектерү. Балаларны «юл билгесе» төшенчәсе, юл чатларында җәяүлеләр хәрәкәтен тәртипкә сала торган «Җәяүлеләрнең җир асты юлы», «Җәяүлеләрнең җир өсте юлы» билгеләре белән таныштыру.

Хәрәкәтне сигналлар ярдәмендә җайга салучы инспекторы эшчәнлеге белән таныштыру, җәмгыять өчен аның хезмәтенең әһәмиятлелеген бәяләү күнекмәләре үстерү.Балаларның махсус транспорт чаралары билгеләнеше(«ашыгыч ярдәм» машинасы, «полиция» машинасы, «янгын сүндерү» машинасы һ. б.) турындагы белемнәрен ачыклау; сигнал тавышларына игътибар итәргә, аларны аера белергә өйрәтү; кайбер аерым очракларда махсус транспорт чараларының юл йөрү кагыйдәләрен бозу мөмкинлегенә игътибар иттерү. Метрода: вагонда (ишекләргә сөялмәү, чыгарга алдан әзерләнү), станциядә (бер юнәлештә хәрәкәт итү, тыелган сызыкка басмау), экскалаторда (уң якта басу, үз хәрәкәтеңне экскалатор хәрәкәтенә яраклаштырып керергә һәм чыгарга әзерләнү); турникетлар аша үткәндә үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләре белән таныштыру.

Метрода, юлларда, шәһәр (авыл) урамнарында үз-үзеңне куркынычсыз тотуның мөһимлеген аңларга ярдәм итү; әхлакый аралашу үрнәкләре («рәхмәт», «рәхмәтлемен сезгә», «гафу итегез», «рәхимле булыгыз», «мөмкин булмасмы» һ. б.) биреп, гади этикет кагыйдәләрен үзләштерергә булышу.Җәмәгать урыннарында үз кыланышыңны һәм башка

кешеләрнең үз-үзләрен тотышын күзәтү, чагыштыру, каршы кую, бәяли белү күнекмәләрен үстерү; балаларның юлларда з-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләрен үтәмәгән очракта килеп чыккан күңелсез хәлләрне, аларның башка кешеләрнең эмоциональ халәтенә йогынтысын аңлауларына ирешү.Үзең яшәгән җирлектә транспорт чараларының төрлелегендә ориентлашу күнекмәләрен үстерү: өйдән балалар бакчасына кадәр, үзәк мәйданга һ. б. җирләргә кадәр нинди маршрут автобусы белән барырга мөмкин, әти-әниләр нинди транспорттан файдалана һ. б. Балаларны машинада утырып йөрү кагыйдәләре белән таныштыру: балалар урындыгында (креслосында) утыру һәмкаеш белән эләктереп кую, машина йөртүченең игътибарын читкә юнәлдермәү, тәрәзәдән башны чыгармау, үзең белән очлы предметлар алмау; үз хәрәкәтләреңне контрольдә тотар-га өйрәнү.Баланы үз фамилиясен, тулы исемен, яшен әйтергә өйрәтү.
Тору урынының адресын, телефонын, якындагы тукталыш исемен әйтү һәм полиция хезмәткәренә ярдәм сорап эндәшү күнекмәләрен булдыру.Уңга һәм сулга борылышлар ясап, түгәрәк буйлап, елан-сымак, ике яки өч тәгәрмәчле велосипедта йөрергә өйрәнүне дәвам итү; үз хәрәкәтләрең белән идарә итә белергә, велосипедта, самокатта йөрү урыннарын билгеләргә өйрәтү.Балаларның хәрәкәтле уеннар, спорт һәм эстафета уеннары («Каршылыклы юл», «Күңелле ярышлар» һ. б.) оештыру инициативасын хуплау.Балаларга таныш булган юл билгеләрен, урам чатлары, тукталышлар, ике яклы хәрәкәт, төрле билгеләнештәге транспорт хәрәкәтен файдаланып, җәяүлеләр һәм пассажирлар булып уйнарга мөмкинлекләр бирә торган уен ситуацияләре тудыру һәм юл йөрү кагыйдәләрен үзләштерү өстендә эшләү.Танып белү бурычларын үтәгәндә модельләштерү ысулын куллану: күләм һәм киңлек бәйләнешләрен билгеләү («Бүлмә буйлап сәяхәт», «Бала кая киткән?» һ. б.).Чынбарлыкта булган, вербаль һәм вербаль булмаган уйлап чыгаруларга таянып, эчке программалаштыруның гади операцияләренә өйрәтү: ситуацияләрне уйнап күрсәтү, пространствода биналарның, транспорт чараларының, җәяүлеләр, юл билгеләренең урнашу макетын һәм моделен ясау күнекмәләре формалаштыру.
Алынган мәгълүматны (су, җир өсте, тимер юл, һава, җигүле транспорт) гомумиләштерергә һәм аны мөстәкыйль эшчәнлектә файдалана белергә өйрәтү («Нәрсә артык?», «Автоюллар лотосы», «Юл доминосы» һ. б.).
Балаларның проблемалы характердагы сораулар бирүләрен уплау, укыганнары буенча фикер алышуга теләк тудыру («Светофор эшләмәсә, нәрсә булырга мөмкин?», «Әгәр туп транспорт йөри торган юлга тәгәрәп чыкса, нишләргә?» һ. б.). Балаларны проблемалы ситуацияләрне чишәргә генә түгел, ә бәлки үз фикерләрен әйтеп бирергә өйрәтү. Юлларда үз-үзеңне куркынычсыз тоту кагыйдәләренең кайберләрен ныгыту максатыннан, уйлап чыгарган әкиятләрдән, тормыш тәҗрибәләреннән алынган хикәяләр, шигырьләрдән, үзләре ясаган рәсемнәрдән (аппликацияләрдән) китап-җыентык төзүләрен хуплау.Мәгълүматны мөстәкыйль рәвештә эзләп табарга мөмкинлек бирү.

**Экологик аң алшартларын формалаштыру**

Табигатьтә үз-үзеңне тоту культурасын формалаштыруны дәвам итү. Туган як табигате өчен куркыныч булган кайбер чыганаклар турында сөйләү (агачларны кисү, урман янгыннары, көчле салкыннар, сулыкларны пычрату һ. б.).Табигать белән кешенең үзара бәйләнеше, әйләнә-тирәнең кешенең сәламәтлегенә йогынтысы турында күзаллаулар булдыру.Балаларны хуҗасыз хайваннар белән очрашканда мөмкин булган куркыныч хәлләр турында искәртү.

| Укыту эшчәнлеге формасы | | |
|---|---|---|
| **Непосредственно образовательная деятельность** | **Режим моментлары** | **Балаларның үзаллы эшчәнлеге** |
| **Балаларны оештыру фрмасы** | | |
| Индивидуаль<br>Өлешчә группа белән<br>Группа белән | Индивидуаль<br>Өлешчә группа белән<br>Группа белән | Индивидуаль<br>Өлешчә группа белән |

| | | |
|---|---|---|
| • Бергә эшләү<br>• Күзәтү<br>• Әңгәмә<br>• Уку<br>• Мультфильм, Видеофильм, телетапшыруларны карау ёщм анализлау.<br>• Эксперимент үткәрү | • Бергә эшләү<br>• Күзәтү<br>• Әңгәмә<br>• Уку<br>• Уен<br>• Проект эшчәнлеге<br>• Мультфильм, Видеофильм, телетапшыруларны карау ёщм анализлау. | • Тиешле предметлы-үстерелешле мөһит булдыру. |

**«Куркынычсызлык» белем бирү өлкәсенә перспектив план**

| Тема | Эчтәлек | Методикалымнар<br>**Шөгыльгә җиһазлар**. |
|---|---|---|
| **1Бала һәм аның сәламәтлеге.** | Балаларның үз һшм башка кеше сәламәтлекләренә карата куркынычсызлык кагыйдәләре турынд күнекмәләрен уамилләштерү һәм киңәйтү. | Әңгәмә:"Мин үземнең сәламәтлегем турында ничек кайгыртам?" Уку: К.Чуковский «Айбо-лит».Д/у:«Перваяпомощь»,С/р-уен: «Шифаханә». |
| 1Үзебезнең тән төзелешен өйрәнү. | Кешенең тән төзелеше турында мәглумат бирү. | |
| 2 Авырулар каян барлыкка килә. | Сәламәтлек, чир, микроб турында белешмә бирү. | Кул яулыклары, тәмәке тартучы һәм тартмаучы кеше сурәтләре. |
| 3.Кеше тормышында витаминнарның урыны. | Кеше тормышында витаминнарның урыны турында сөйләү. | Табышмаклар, рәсемнәр.. |
| 4.Күзләр күрсен өчен.<br>. | Күз күрүнең кеше тормышындагы урыны. | Курчаклар Здрастик и Фыркало. Гимнастика күзләр өчен. |
| 5.Колаклар ишетсен өчен. | Балаларны үз колакларының ишетүләренә игътибарлы булуларын сорау. | Колак төзелеше турында рәсемнәр, Колак чисталыгы турында мәглумәт |
| 6.Гәүдәне төз тоту. | Умыртка сөяге турында сөйләү,аның кирәклеге. | Курчаклар Здрастик һәм Фыркало, дөя рәсеме, кешенең умыртка баганасы төшерелгән рәсемнәр . |
| 7.Тешләр һшм аларны тәрбияләү. | Сөт һәм тамыр тешләр турында мәглумәт, теш чистарту ысуллары. | Теш сурәте төшкән рәсемнәр, схемалар. |
| 8.Ашкайнату органнары. | Шәхси гигиена турында белемнәрне ныгыту,яшелчәләрне юып ашарга кирәклеген төшендерү. | Кул юу, ашау,туп, салфетка турында рәсемнәр карау. |

| | | |
|---|---|---|
| 9.Бала сәламәтлеген ничек сакларга. | Табиб һөнәре турында күзаллау, дарулар турында мәглумәт бирү. Сәламәтлек турында күзаллауны ныгыту. | КурчакБелмәмеш. |
| **2.Юл йөрү кагыйдәләре.** | Җәмәгать урыннарында куркынычсызлык кагыйдәләрен белү, юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнү. | Транспортны күзәтү.Рәсем карау.Д/у:" Тап һәм әйт", "Бер төслене тап", "Домино", "Транспорт"-С/р-уен |
| 1.Песигә кагыйдәләр турында сөйлик | Юл йөрү кагыйдәләрен кабатлау. | Песи уенчыгы; Юл йөрү кагыйдәләре турында шигырьләр. |
| 2.Балалар бакчасына барганда | Җентекләп юлны тиешле җирдән чыгу турында аңлату. | Светофор рәсеме, юл билгеләре:"Балалар", "Җәяүле", "Игътибар". |
| 3 Юл йөрү кагыйдәләре белән танышу. | Урамда юл йөрү кагыйдәләрен үтәү, "куркынычсызлык утравы" дигән төшенчәне искә төшерү. | Шигырь В. Алексеева"Өч дус" "Кем беренче светофорны җыя","Иң яхшы җәяүле" уены өчен җиһазлар. |
| 4.Юлчылар булырга без әзерме? | Транспорт үз-үзеңне тота белү, кагыйдә буенча утырып йөрү. | Автобус. Трамвай. Метро төшерелгән рәсемнәр. |
| 5.Җәмәгать урынында үзеңне тоу | Транспорт үз-үзеңне тота белүне өйрәнүне дәвам итү.<br>. | "Светофор" уены өчен җиһазлар,шигырьләрдән өзекләрК. Чуковский «Буталчык»; С. Маршак «Песи өе»; С. Михалков «Степан абый». |
| 6.Машина һәм машина йөртүченең эшен күзәтү. | Юлдагы куркыныч вакыйгалар турында сөйләү, урам киселеше турында сөйләү. | Урам кисешкән урынны күзәтү. Д/у:"Юл йөрү кагыйдәләре" |
| 7.Җәяүле юл чыга | Җәяүле юл йөрү кагыйдәләрен ныгыту, җәяүле юл турында сөйләшү. | Җәяүле юл макеты трамвай юлы кырында, ике яклы юл кырында. |
| 8.Юл куркынычсызлыгы. | Юлда куркынычсызлык кагыйдәләрен белү кирәклеген төшендерү. | Юл билгеләре төшкән табличкалар. |
| 9Җәмәгать транспортындаҮзеңне тоту кагыйдәләре | Транспорт үз-үзеңне тота белү, кагыйдә буенча утырып йөрү,кызыксыну уяту.. | КурчакБелмәмеш; Автобус. Трамвай. Метро төшерелгән рәсемнәр. |
| **Уткуркынычсызлыгы Турында кагыйдәләр.** | Өйдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, электр җиһазлары, кайнар предметлар белән сак булырга | Янгын сүндерүчеләр турында әңгәмә, ут белән сак булу,"Ут белән уйнарга ярыймы?","Пешмәс өчен нәрсә эшләргә?"Уен:"Әгәр янгын чыкса", " янгын чыкканда нәрсә эшләргә?" Уку:С. Я. Маршака «Янгын». Шырпы кабын анализлау. Янган кәгазь белән танышу. |

| | | |
|---|---|---|
| 1Ут һәм ут сүндерүчеләр. | Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышу, һөнәргә карата хөрмәт тәрбияләү, янгын сүндерүче һөнәренең авырлыгын аңлату. | Ике телефон. |
| 2.Янгын кагыйдәләре. | Янгын сүндерүче һөнәре белән таныштыру, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен һәрвакыт үтәргә кирәк. | Ике чиләк, ике бәләкәй чиләк, ике метрлы иске кул киеме. |
| 3.01-һәр кеше белергә тиеш. | Телефоннан янгын турында хәбәр итә белү | Телефон, курчаклар, аю, убырлы карчык |
| 4. «Тили – бом, тили – бом Песинең өе янды» | Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышу, һөнәргә карата хөрмәт тәрбияләү, янгын сүндерүче һөнәренең авырлыгын аңлату. Янгын чыкканда хәбәр итә белү. | Кабартылган шар. |
| 5.Төп янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре. | Төп янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән таныштыру, ут белән уйнау куркыныч икәнлеген аңлату. | Кәгазьләр, карандаш; ребуслар. |
| 6.Балаларның ут белән уйнавы һәм аның начар азагы. | Төп янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен кабатлау. | “Куркыныч предметларны сызып ату”, “Янгын чыкканда нәрсә эшләргә кирәклеген яхшы беләм” уенын уйнау. |
| 7.Сак бул, ут. | Шырпы, газ плитәсе, мич-балалар өчен уйный торган җир түгеллеген аңлату, янгын чыккан очракта телефоннан шалтырата белү, зурлардан ярдәм сорау. | Шырпы ,мич турында табышмаклар, шигырьдән өзек”Янгын” С, Маршак. |
| 8,Шырпы- янгын чыганагы. | Шырпы белән бары тик зурлар гына кулланырга мөмкин икәнлеген аңлату | Чыршы агачы, шырпы, яңа ел уенчыклары, курчак. |
| 9. «Янгыннан да куркыныч әйбер юк» | Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышу, бәлагә юлыккан кешегә ярдәм итү. | Уку С.Маршак «Песи өе». Викторина «Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре». |
| Көнкүрештә баланың куркынычсызлыгы. | Көнкүреш куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышу, очлы, уалучан әйберләр, дарулар белән сак булырга кирәклеген аңлату. | Әйберләр карау: энә, кнопка,һ.б. нәрсә эшлиләр.Әңгәмә:”Хәвеф-хәтәр китерүче предметлар”. Дару савытларын карау.Әңгәмә:” Сак бул, дарулар” |
| 1.Кукынычсызлык кагыйдәләрен без белдек | Балаларны куркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыру: дөрес аралашу, режим моментлар, шәхси гигиена, дөрес сөйләм, уйлау. | Рәсемнәр: балаларның үзләрен дөрес тотышлары турында. |

| | | |
|---|---|---|
| 2Әни өйдә юк вакытта. | Балалар өйдә үзләре генә булганда ничек үз-үзләрен тотарга тиеш, беркемгә дә ишек ачарга ярамаганлыгын аңлату | Курчак Би –ба – бо, төлке, аю , куян, бүре, песи, телефон: 01, 02, 03, 04, 911. |
| 3.Көнкүреш җиһазлары. | Көнкүреш җиһазлары турында күзаллау, алардан дөрес файдалану.Әйберләне урынына урнаштыру, балаларда зурларга буйсынуны булдыру. | |
| 4.Табигать белән аралашу. | Балаларны табигатьне сакларга кирәклеген аңлату, кош ояларын таратмаска, кырмыска оясын таптамаска кирәклеген аңлату. | Балалар өчен телеграмма, урманчы макеты, табышмаклар. Чүп пакеты |
| 5.Эт һәм песиләр-безнең дуслар. | Хайваннар белән аралашканда нәрсә эшләргә ярый, нәрсә ярамый, хайваннар тормышы белән кызыксыну | Хайваннар турында рәсемнәр. |
| 6.Куркыныч әйбернең үз урыны. | Кисә, кадый торган әйберләр белән ничек кулланырга кирәклеген аңлату,кисүче әйберләр белән тыныч кына сак эшләү. | Куян уенчыгы, хайваннар турында рәсемнәр, кайчы, энә. |
| 7.Йомры икмәк турында әкият. | Балаларга тышкы кыяфәт алдаучан булуы турында аңлату, шуңа күрә төрле хәлләр вакытында сак булырга кирәклеген , дөрес фикерләп эш итәргә кирәклеген әйтеп үтү, фаҗигагә эләккәндә зурлардан ярдәм сораргөйрәнү, таныш булмаган кешеләргә юк дип җавап бирергә өйрәнү | Йомры икмәк геройлары |

| | | |
|---|---|---|
| 8.Сак булырга өйрәнәбез. | “к кулланырга “өйрәнәбез, әйберләрне саклап тотарга өйрәнәбез, тәртипсез, шапшапк кешеләргә карата начар фикерләр туы турында искәртеп үтәбез. | Китапларны күрсәтү: А Барто К. Чуковгарского, В. Маяковского.<br>. |
| 9Сәламәтлек һәм сәламәт яшәү рәвеше иленә сәяхәт | Кабатлау, берләштерү, алган белемнәрне уртаклашу | |

**2.1.2.«Танып белү» белем бирү өлкәсе**

«Танып белү» белем бирү өлкәсе эчтәлеге балаларда танып белү ихтыяҗларын һәм акылны үстерү максатларын тормышка ашыруга юнәлтелә һәм белем бирү бурычларын билгели.

Татарстан – күпмилләтле республика. Казан – эре промышленность үзәге, Россиянең борынгы шәһәрләреннән берсе. Казан – республиканың һәм бөтендөнья татарларының башкаласы. Казанда Президент, Татарстан Хөкүмәте һәм шәһәр мэры эшлиләр. Шулар турында балаларда күзаллаулар булдыру.Балаларга туган як турында мифлар, легендалар, тарихлар сөйләү. Туган шәһәрнең (авылның) истәлекле урыннары, бик күптәнге вакыйгалары, тарихи истәлекләре, музейлары, урам-

нары белән таныштыру.Татарстан Республикасының төп символикасы (флаг, герб, гимн) белән таныштыру. Балаларга үз халкыңның бер өлеше булуларын аңлату.Татарстан Республикасының географик урыны белән таныштыру (картада яки глобуста республиканың территориясен, Кама һәм Идел елгаларын, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларын, Кабан күлен, тирә-як күл һәм елгаларын билгеләү).Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның традициләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру. Милли бәйрәмнәр (Нәүрүз бәйрәме, Корбан бәйрәме, Сабантуй, Нардуган һ. б.) турында күзаллаулар булдыру. Башка милләтләргә карата хөрмәт һәм дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү.Милли һәм бөтендөнья культураларының үткәне һәм бүгенгесе белән танышуга тарту. Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге күренекле эшлеклеләрнең (шагыйрьләр: Г. Тукай, М. Җәлил, Р. Миңнуллин һ. б., язучылар: А. Алиш, Р. Батулла һ. б., рәссамнар: Х. Якупов, Х. Казаков һ. б., скульптор Б. Урманче һ. б.) тормыш һәм иҗатлары белән таныштыру.

Аларның тормышлары һәм эшчәнлекләренә карата кызыксыну уяту. Балаларның кызыксынуларын исәпкә алып, туган як табигате турындагы белемнәрен киңәйтү.Кешеләрнең табигатьне саклау буенча эшчәнлеге белән таныштыру. Идел-Кама дәүләт тыюлыгы, «Түбән Кама» милли паркы, республиканың табигатен саклауда аларның әһәмияте турында сөйләү.

Тере һәм тере булмаган табигатькә сакчыл караш тәрбия-ләү, табигатьтә үзеңнең катнашыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, туган як табигатенә үз ихтыяҗыңны канәгатьләндерү өчен дип карау ярамаганлыгын аңлату, аны файдалануның беренчел күнекмәләрен булдыру («Әгәр мин һәм башка кешеләр дару үләннәрен тамырлары белән җыйса...»).

Туган якта ешрак очрый торган үсемлек һәм хайваннарга карата кызыксынуны үстерү. Табигать объектларын үзен чәлекләре буенча классларга һәм төркемнәргә бүләргә өйрәтү (ылыслы һәм яфраклы агачлар, куаклар, үлән үсемлекләр; урман, болын, бакча үсемлекләре; урман җиләкләре, гөмбәләр, бүлмә үсемлекләре (гөлләре); кыргый һәм йорт хайваннары, кышлаучы һәм күчмә кошлар, балыклар, бөҗәкләр һ. б.).

Республика территориясендәге хайваннарның яшәү рә-вешен, аларның тышкы кыяфәт үзенчәлекләрен (гәүдә өлеш-ләре, тәне нәрсә белән капланган), хәрәкәт итү ысулларын (шуыша, оча, йөзә), азыкларын; кайбер бөҗәкләрнең, җир-су хайваннарының, сөйрәлүчеләрнең яшәү мохитенә яраклашуларын күзәтергә өйрәтү. Хайваннарны тавышларыннан танырга булышу.

Туган як табигатенең матурлыгын, аның форма, төс, исләр байлыгын күрә һәм тоя белү күнекмәләрен үстерү

| | тема | Бурычлар һшәм бурычлар | сузлек | Җиһазлар |
|---|---|---|---|---|
| СЕНТЯБРЬ | 1.Балалар бакчасы буйлап сәяхәт. | 1. Балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның игътибарлылыкларын, куелган максатны аңлый белү сәләтен үстерү.<br>3. “Минем бакчам” дигән темага хикәя төзеп сөйләргә өйрәтү. | ашханә,<br>су коену бүлмәсе,<br>кышкы бакча,<br>ике катлы,<br>салганнар. | |
| | 2.Бакча тирәли сәяхәт- “Җәйләр үтте, көзләр җитте.” | 1. Балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксынучанлык сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Үзләштерелгән сүзлек запасына таянып агач, яфрак,үләннәрне, һава торышын тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Күзәтүләрдән чыгып, нәтиҗә ясаганда исем ясагыч һәм сыйфат дәрәҗәләрен белдерүче | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | кушымчалардан файдаланырга өйрәтү ( яшькелт, ямь-яшел, сап- сары, зәп-зәңгәр һ. б.) | | |
| | 3. Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт- “Күзге могҗиза.” | 1. Балаларда туган як табигатенә, яшелчәләргә карата сакчыл караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның иҗади күзаллауларын, күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br>3.Яшелчәләр турындагы белемнәрен системалаштыру, алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. | кисмәк, җиз бүкән, чүлмәк, яшелчәле, тәм | төрле формаларга кереп үскән яшелчәләр |
| | 4.“Туган ил кайдан башлана?” | 1. Балаларда туган якка карата ярату хисләре тәрбияләү.<br>2. Тирә-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү исәбенә сүз байлыгын арттыру, активлаштыру, диалогик сөйләмне үстерү.<br>3. Балаларның туган ил турындагы күзаллауларын киңәйтү, “кече илгә” карата кызыксыну формалаштыру. | инешләр, чишмәләр, балачак. | туган төбәккә кагылышлы булган слайдлар, фотографияләр, рәсемнәр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ОКТЯБРЬ | 1.“Башкалабыз-Казан.” | 1. Туган якка мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның диалогик сөйләмен, игътибарлылыгын үстерү.<br>3. Татарстан башкаласы Казан турында белемнәрен тирәнәйтү, Татарстан символикасы һәм аның мәгънәсе белән таныштыру. | әләм, тугра, башкала. | ТР картасы, символика-сы (тугра, әләм), милли курчаклар, слайдлар, фоторәсем-нәр, аудиоязма. “Туган җирем-Татарстан” ( Г.Зәйнашева сүзләре, А. Ключарев көе.) |
| | 2.“Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел!” | 1. Балаларда туган илне ярату, башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның хәтерен, логик фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен, кызыксынучанлыкларын үстерү.<br>3. Балаларның Россиянең башкаласы Мәскәү турындагы белемнәрен баету, Россиянең символикасы турында мәгълүмат бирү. | әләм, тугра, бөркет, калкан. | лайдлар, рәсемнәр, символика, уен өчен рәсемнәр |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 3.“Игенче хезмәте белән танышу.” Әңгәмә -“Икмәк – тормышның нигезе.” . | 1. Балаларда игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Табышмаклар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү.<br>3. Яңа очраган сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүзлек запасын баету, игенче хезмәтенең авыр һәм мактаулы эш икәнен аңлату | сабан, механизатор , комбайнчы, тракторчы, агроном | слайдлар, рәсемнәр, аудиоязма “Чайкала иген кырлары”.( Г. Латыйп сүзләре, И. Шәмсетдинов көе.) |
| | 4.“Икмәк – тормышның нигезе.” | 1. Икмәккә сак караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның игътибарлылыгын, хәтерен, фикер йөртә белү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларга икмәкнең әһәмиятен аңлату, ипи үстерүдә катнашучыларның хезмәте турында белемнәрен ныгыту. | ярма, орлык, башак, бөртек, тегермән. | слайдлар, эчтәлекле рәсемнәр, “Алтын бөртекләр” мультфильмы |
| НОЯБР. | 1.“Җир өсте, һава, су транспорты.” | . Балаларда урамда игътибарлылык һәм транспорт хезмәткәрләренә ихтирам тәрбияләү.<br>2. Транспорт турындагы күзаллауларын киңәйтү, фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү, аларның исемнәрен истә калдыру, кулланылышын белү. | коры җир, су юлы, тимер юл, һава юлы. | төрле транспорт рәсемнәре, төрле транспорт йөртүчеләрнең рәсемнәре : “Тракторч, “Машинист, Комбайнчы”Очучы”, “Машина йөртүче”. |
| | 2. .“Су, һава һәм кояш-безнең белән гел юлдаш!” | 1. Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның үз фикерләрен дөрес итеп җиткерә белү күнекмәләрен үстерү, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш булдыру.<br>3. Балаларга сәламәтлекне саклауда табигатьнең әһәмиятен аңлату, чыныгу чаралары белән таныштыру.<br>**Матур әдәбият**: К.В.Закирова “Балачак аланы” 306 бит. | талпына, армый-талмый, чыныккан, таза. | рәсемнәр, слайдлар. |
| | 3. Савыт-саба кибетенә сәяхәт | Балаларда савыт- сабага карата сакчыл караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү.<br>3. “Савыт- сабалар” кибете турында белемнәрен тулыландыру, тәрбияче үрнәгендә кечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү. | чынаяк, чәнечке, пычак, чәйнек, кәстрүл, кашык, чүмеч, сатучы, сатып | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | алучы, киштә | |
| | 4. Кием – салым кибетенә сәяхәт. | 1Балаларда киемнәргә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү.<br>2. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Тормышта тышкы кыяфәтнең дә мөһимлеген аңлауларына ирешү.Өс-баш, аяк киемнәрен чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтү | бизи, шәл, бүрек, башлык-баш киемнәре, өс ( аяк ) киемнәре | эшчәнлек кием- салым кибетендә уздырыла |
| | 5. .“Милли киемнәр.” | 1. Халык сәнгате аша балаларда зәвык, матур итеп киенергә теләк тәрбияләү.<br>2. Балаларның логик фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү.<br>3. Милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен ачыклау, төсләрнең берләшүенә игътибар итү. | лалә, өчяфрак, канәфер чәчәге, милли. | милли киемнән курчаклар, милли киемнәр, кисмә рәсемнәр |
| | 1. .“Без суыктан курыкмыйбыз.” | 1. Кышкы табигатьнең матурлыгына соклана белү сыйфатларын тәрбияләү.<br>2. Балаларның иҗади күзаллауларын, бәйләнешле сөйләмен үстерү.<br>3. Кыш турында белемнәрен тирәнәйтү, авазларның дөрес әйтелешен ныгыту. | алсу, ыжгыра, бөтерелә, оча, шуам, тәгәрәтәм | кыш турында слайдлар яки рәсемнәр |
| | 2. Балалар бакчасы тирәли экскурсия - “Җимнәр сибәм кошларга.” | 1. Балаларда кошларга сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.<br>2. Чагыштыру, күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык күнекмәләрен үстерү.<br>3. Балаларның кошлар турында белемнәрен баету, өлкәннәр ярдәмендә җимлекләр куярга өйрәтү.<br>**Матур әдәбият**: Ф.Ю. Юсупов “Гөлбакча” 70 бит. | җим, җимлек | кышлаучы кошларның битлекләре, җимлек, эшчәнлек табигатьтә үтә. |
| | 3.”Кыш бабайга хат” | 1.баларда бәйрәмгә карата уңай мөнәсәбәт,үз фикереңне бер юнәлештә туплый һәм аны башкаларга ңиткерә белү сыйфаты тәрбияләү.<br>2.бәйләнешле сөйләм телен,иңади куззаллауларын үстерү. | Эри Юлдаш, гөр килә. | Конверт,ка-ләм,кагәзь. |
| | 4 ” Кайда ничек кышлыйлар” | 1.Балаларда кыргый хайваннарга карата кызыксыну һәм скчыл караш тәрбияләү.<br>2. Уеннар һәм тирә- юнь белән танышу барышында балаларның бәйләнешле сөйләм телен, логик фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Кыргый хайваннар һәм аларның үзенчәлекләре турында белемнәрен баету. | бурсык, маймыл, арслан, фил. | өстәл өсте зоопаркы, уенчыклар, рәсемнәр. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| ЯН ВАРЬ | 1. Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү.- “Ишегалдында.” | 1. Балаларда барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. Аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү.<br>2. Балаларның бәйләнешле сөйләмен , бер- берсен тыңлый, башкаларның җавапларын тулылындыра алу сәләтен үстерү.<br>3. Рәсемнәр аша балаларның йорт хайваннары һәм кошлары турындагы күзаллауларын системалаштыру, кешенең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру. | бозау, колын, көчек, чеби, бәбкә. | уенчыклар, авыл өе макеты. |
| | 2. . Тәҗрибә – “Бер хәлнең икенче хәлгә күчүе.” | 1. Туган як табигатендәге үзгәрешләргә карата кызыксынучанлык тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзәтүчәнлеген, фикерләү сәләтен һәм сөйләмен үстерүне дәвам итү.<br>3. Кайбер әйберләрнең бер халәттән икенче халәткә керүен сынап карау юлы белән балаларның белемнәрен тирәнәйтү. | карлану, кар салу, карлы-бозлы, карлы-буранлы | эшчәнлек табигатьттә уза,тәҗрибә өчен фильтр. |
| | 3. .“Машина йөртүче һәм җәяүлене кисәтүче куркынычсызлык билгеләре.” | 1. Балаларда урамда, җәмәгать транспортында, торак зонасында үз-үзеңне тоту культурасын тәрбияләү.<br>2. Юлларда күзәтүчәнлекне, фикерләү мөстәкыйльлеген, дикъкатьлелекне үстерү.<br>3. Юл билгеләрен аера белү, юлда хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү. | тыючы, боеручы, мәгълүмат бирүче, кисәтүче, хезмәт күрсәтү. | урам макеты, юл билгеләре, рәсемнәр руль |
| | 4.“Велосипед-минем дустым.” | 1. Балаларда юлда үз- үзеңне тоту культурасын тәрбияләү.<br>2. Бирелгән мәгълүматне тыңлый белү һәм үзләштерүне формалаштыру, мөстәкыйль фикер йөртә белү, коммуникатив сәләтләрен үстерү.<br>3. Велосипедта хәвефсез йөрү кагыйдәләрен өйрәтү.<br>**Матур әдәбият**: К.В.Закирова “Балачак аланы” 414 бит. | велошлем, терсәкчә, руль, утыргыч, чылбыр, багажник | юл билгеләре, велосипедның өлешләре төшерелгән рәсемнәр, шәһәр макеты, велосипед |
| Февраль | 1Төзелеш булган җиргә сәяхәт яки рәсем карау. “Хезмәткә хөрмәт.” | 1. Балаларда хезмәт кешесенә, төзүче һөнәренә хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле сөйләм һәм танып белү эшчәнлеген үстерү.<br>3. Балаларның өлкәннәр хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү, төзүчеләр хезмәте белән таныштыру. | һөнәрләр, штукатурчы, ташчы, буяучы. | слайдлар, рәсемнәр, туп |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2.“Исемең матур, кемнәр куйган.” | 1. Балаларда башка кешеләргә карата игътибар, исемнәргә кызыксынучанлык тәрбияләү.<br>2. Логик фикерләүне, хәтер сәләтен, хәрәкәт активлыгын үстерү.<br>3. Балаларга һәр исемнең аерым бер мәгънә белдерүе турында төшенчә бирү, үзеңнең дә, иптәшләреңнең дә исем- фамилиясен, кыскартырга, үзгәртергә, бозарга ярамаганлыгын аңлату. | ышанычлыт урылыклы, куркусыз, тынычланды ручы, дәвалаучы, мәгънәле. | курчак, яулык. |
| | 3. Тәҗрибә. - “Суның үзенчәлекләре.” | 1. Яшәү чыганагы булган суга сак караш тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзаллауларын, мөстәкыйль фикер йөртә белү сәләтен үстерү.<br>3. Гади тәҗрибәләр һәм уеннар аша балаларның су үзенчәлекләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү | халәт, салават күпере. | бал кашыгы, сулы , сөтле стакан, тоз, елга комы, термос, пыяла, күбекле су, салам таякчык-лары. |
| | 4.“Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар.” | 1. Балаларда кыю, батыр солдат булу теләге уяту, әтиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү.<br>2. Ватанны саклаучылар турындагы күзалллауларын киңәйтү, бәйләнешле сөйләмне үстерү.<br>3. Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар турында белем бирү, аларның мөһимлеген аңлату. | пехотачы, танкист, диңгезче, очучы, артилле-рия, чик сакчылары | слайдлар, рәсемнәр, таякчыклар. |
| Март | 1. .Балалар бакчасы тирәли максатчыл күзәтү. | 1.Туган ягыбызда була торган язгы табигать күренешләренә соклану хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү.<br>3. Максатчыл күзәтү аша балаларны язгы табигать күренеше белән таныштыру | саба җиле, йомшак җил, гөрләвек, каурый, бүртте, ләйсән яңгыр. | эшчәнлек табигатьтә уза. |
| | 2. Терәк сораулар буенча рәсемгә карап чагыштырма хикәя төзү. “Сыерчык белән карга, яз килүгә шатлана.” | 1. Кошларга сак караш һәм кайгыртучанлык хисе тәрбияләү.<br>2. Балаларның күзаллау, тасвирлый белү сәләтен үстерү.<br>3. Кошлар турында белешмә бирү, тышкы билгеләренә карап сыерчыкны һәм карганы танырга өйрәтү, кешеләрнең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру | сыерчык оясы, моң-көең. | сыерчык рәсеме, карга рәсеме, сыерчык оясы, карга оясының рәсеме. |
| | 3. Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау | 1. Балаларда бер- берсен игътибар белән тыңлый, иптәше сөйләгәнне тулыландыра, аның эшчәнлегенә дөрес бәя бирә белү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2. Халык авыз иҗаты белән таныштыру аркылы балаларның сүзлек | тәти, күк күлмәк,келәт . | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | байлыгын, диалогик сөйләмнәрен, хәтер, иҗади уйлау сәләтләрен үстерү.<br>3. Яз турында эндәшләр, тизәйткечләр, әйтенүләр, сынамышлар өйрәтүне дәвам итү. | | |
| | 4. Тәҗрибә үткәрү.<br>- "Суган утырту". | 1. Балаларда суган үстерү теләге тудыру, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның логик фикер йөртү күнекмәләрен үстерү.<br>3. Суганның файдалы яшелчә икәне турында төшенчә бирү, суган үстерү турында белемнәрен тулыландыру. | җылылык, яктылык, итләч, йомры. | чиләк, туфрак, тартма, утырту өчен суганчалар, сулы лейка, тартмада һәм түтәлдә үскән суган рәсемнәре |
| Апрель | 1. ."Минем яраткан спорт төре." | 1. Балаларда ихтыяр көче, сабырлык, кыюлык, уен кагыйдәләрен үтәү сыйфатлары тәрбияләү.<br>2.Танып белү һәм мөстәкыйль фикерләү эшчәнлеген үстерү.<br>3.Үз теләкләрен башкаларныкы белән яраклаштырырга, иптәшләре алдында җаваплылык хисе тоярга өйрәтү. | көрәшче, милли көрәш, баскетбол,волейбол, футбол, теннис | спорт төрләре турында слайдлар, яисә рәсемнәр, уеннар өчен спорт җиһазлары, аудиоязма "Мин спортчы." (Р.Вәлиева сүз., И. Якупов көе) |
| | 2. Уен "Планетарийга сәяхәт." | 1. Балаларда беренче очучы, Ю. Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горурлык хисләре тәрбияләү.<br>2. Балаларның образлы күзаллауларын, иҗадилыкларын, хәтерен үстерү.<br>3. Балаларга кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту.<br>**Матур әдәбият**: К.В.Закирова. "Балачак аланы" 432 бит | галәм, орбита, планета, глобус, космонавт, ракета, кояш системасы | слайдлар, рәсемнәр, глобус, "Космоска очучы" рәсеме. |
| | 3. Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты." | 1. Балаларда Г. Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү.<br>2. Шигырьнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белү, фикерләү, хәтер сәләтен үстерү.<br>3. Г. Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру, әдәби әсәрләрне тыңлый, эчтәлеген сөйли белүләренә ирешү. | шәкерт, буыннар, ятим. | Г.Тукай портреты, китаплар, аудиоязма "Туган тел" җыры. |
| | 4. Тукайның эссәрләре белән | 2. Шигырьнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белү, фикерләү, хәтер | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | танышу<br>Шигырьләрен уку<br>Мультфильм карау. | сәләтен үстерү.<br>3. Г. Тукайның әдәби әсәрләрне тыңлый, эчтәлеген сөйли белүләренә ирешү. | | |
| Май | 1.Сугыш ветераннары белән очрашу. “Бөек җиңү.” | 1. Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү.<br>3. Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында белемнәрен арттыру. | ветеран, хәтер, кыю, батыр, патриот, парад. | аудиоязма “Марш.” ( Р.Еникеев көе), слайдлар, “Хәтер” китабы, “Хәтер көне” күргәзмәсе, чәчәкләр |
| | 2.“Яңгыркаем яу, яу!” | 1. Табигатькә сак караш һәм мәхәббәт тәрбияләү.<br>2. Балаларның фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен, игътибарлылыкларын үстерү.<br>3. Табигатьтә була торган үзгәрешләр турында балаларның күзаллауларын киңәйтү, яңгырның каян килеп чыгуын аңлату.Табигатькә соклана һәм аның гүзәллеген күрә белергә өйрәтү. | ләйсән яңгыр, эре яңгыр, яшенле яңгыр, суалчан | слайдлар яки рәсемнәр |
| | 3. Урман почмагына экскурсия. “Кызыл китап нәрсә ул?” | 1. Балаларда урманга һәм аның байлыкларына сак караш тәрбияләү.<br>2. Кызыл китапка кертелгән хайван һәм үсемлекләрне кызгану, алар өчен борчылу хисләре уяту, табигатькә карата сак караш тәрбияләү.<br>3.Балаларның әйләнә - тирә дөнья белән кызыксынуларын, бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү.<br>4. Балаларны сирәк калган һәм югалып бара торган хайваннар, үсемлекләр турындагы китап белән таныштыру, аның әһәмиятен аңлату. | кыр кәҗәсе, кондыз, бөркет, дельфин, аккош, лачын, тыюлык-лар туп. | кызыл китап, слайдлар, рәсемнәр, кызыл китап |
| | 4. “Хуш исле нәфис гөлләр.” | 1.Балаларда бүлмә гөлләренә карата сак караш тәрбияләү.<br>2. Бәйләнешле сөйләм,чагыштыра белү, фикерләү сәләтен үстерү.<br>3. Бүлмә гөлләренең үзенә генә хас үзенчәлекләре буенча танып,бер-берсеннән аерырга өйрәтү,кеше тормышында гөлләрнең әһәмиятен аңлату. | бүлмә гөле, фикус, алоэ, үрмә гөл, кактус. | бүлмә гөлләре яисә рәсемнәр, дидактик уен өчен материал. |

**Иң гади математик күзаллауны формалаштыру**. Зурлар төркемендә эшчәнлекнең әкренләп гамәлнең предмет белән модельдән математик график модельгә күчүе яңа караш булып тора.Шул максаттан чыгып, эш дәфтәрләре кулланыла ,балаларга мөстәкыйль проблемалы ситуация бирелә. <u>Предметларны чагыштыру.</u> Балалар предметларны үзенчәлекләре буенча төркемнәргә аералар,

бөтен һәм өлеш арасында бәйлелекне, артык предметны табалар; пердметларның төс, форма, зурлыгын символлар белән билгелиләр; төркемдәге предметлар тигез түгеллеген билгеләр белән язалар, 10 га кадәр саныйлар. Саннар предметлар белән дә, график юл белән дә билгеләнә, кушу һәм алу арифметик гамәлләре формалаша башлый.
Зурлык. Зурлар төркемендә предметлар шартлы билге белән үлчәнә. Балалар төрле киңлектәге, биеклектәге, озынлыктагы предметларны үсә яки кими бару тәртибендә урнаштырырга, урнашу тәртибен белергә, үлчәмнәре буенча чагыштырырга өйрәнәләр. Чагыштыру өчен алынган предметларның берсенең шартлы үлчәме ярдәмендә ике предметны зурлыклары(озынлыгы, киңлеге, биеклеге) буенча чагыштырырга өйрәнәләр. Предметларның зурлыгын (озынрак-кыскарак, биегрәк-тәбәнәгрәк, киңрәк-таррак) күз күләме белән билгеләргә өйрәнәләр.
Форма.Түгәрәк һәм турыпочмаклыкны чагыштыру нигезендә , балаларны овал белән таныштыру. Дүртпочмак турында аңлату: квадрат һәм турыпочмаклыкныңдүртпочмак төрләре икәнлегенә төшендерү. Формалары буенча таныш предметларны чагыштыру, якын тирәдә бертөрле һәм төрле формалы предметларны танып белергә өйрәтү(китап, картина,өстәл- турыпочмаклы һ.б.)
Тирә-юньдә һәм вакытта ориентлашу. 5-6 яшьтәге балалар тирә-юньдә ориентлашуны үзләштерә башлыйлар (сулда, уңда, аста, өстә, алда, алдында, артында, арасында, янәшә). Үзенең яки башка предметның торышына карап, теге яки бу предметның урынын билгеләү.Бирелгән юнәлештә хәрәкәт итә белү, сигнал буенча һәм маршрут күрсәткечләренә (уклар) карап үз торышыңны билгеләү; әйләнә-тирәдәге предметларга карап үз торышыңны билгеләү.Балаларны кәгазь битендә ориентлашырга өйрәтү(сулда, уңда, аста, өстә). Иртә, көндез, кич, төннең тулы бер тәүлек тәшкил итүе турында күзаллау бирү. Атна көннәрен эзлекле рәвештә исемнәре белән атап чыгарга, бүген нинди көн, кичә нинди көн иде, иртәгә нинди көн икәнен әйтергә өйрәтү

| № | Занятия темасы<br><br>Тема занятия | Занятия максаты,<br>Программа эчтәлеге<br>Цель занятия,<br>программное содержание | Искәр-мә<br><br>Примечание |
|---|---|---|---|
| 1<br>2 | Мониторинг<br><br><br><br>Мониторинг | Кабатларга сигезгә кадәр тәртип исәбен, санын һәм саннар 1-8. Сан белән санда предметларны туры китерүдә актуаләштерү,санлы рәд төзү белү.Геметрик фигурларның формаларын кабатлау,чагыштыру ысуллары белән предметларның озынлыгын юлы белән (наложения) кушымталар. Күнектерергә уйлау операциясен, үстерергә коммуникатив сыйфат.<br>Повторить порядковый счёт до восьми, числа и цифры 1-8, актуализировать умение соотносить цифру с количеством предметов, умение составлять числовой ряд.Повторить формы геометрических фигур, способы сравнения предметов по длине путем наложения (приложения).Тренировать мыслительные операции, развивать коммуникативные качества. | Метод. Рек.Л.Г Петерсон «Игралочка ступенька к школе» ч.3 стр.19 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | Предметлар үзлекләре һәм сим-воллар<br><br>«Свойства предметов и символы» | Кабатларга геометрическ фигураларның яссы формаларын,пространства мөнәсәбәтләрен "өстә - аста", "сулдан - уңнан";предметларның үзлекләрен – форма, төсе,күләме. Билгесе ярдәмендә предметларның үзенчәлекләре турында тәкъдим итү формалаштырырга. Үстерергә игътибарын, сүз, фантазию, кулларның вак моторикасын.<br>Повторить формы плоских геометрических фигур, пространственные отношения «вверху- внизу», «слева - справа» свойства предметов - форма, цвет, размер, уточнить представление о цифре как знака, обо-значающем число ( количество предметов). Сформировать представ-ление о способах обозначения свойств предметов с помощью знаков (символов), опыт придумывания и использования таких обозначе-ний.Развивать внимание, речь, фантазию, мелкую моторику рук. | Ч. 3 стр. 27 |
| 4 | Предметлар үзлекләре һәм сим-воллар<br><br>Свойства предметов и символы | Символлары кулланырга һәм аңларга белү күнектерергә.Кире кагу "түгел" турында ничек билгеләргәтурында тамаша формалаштырырга. Кабатларга исәп 8кадәр, плоскии геометрик фигур формаларын (треуголь-нигы, квадрат, прямоугольник)кабатларга. Пространства мөнәсәбәтләрен "өстә" – "аста", "сулда" - "уңнан". Балаларда тәрбияче житәкчелегендә кыенлыклары мөстәкыйль жиңеп чыгу тәжрибәсе формалаштырырга . Үстерергә игътибарлык, хәтер, сөйләм, воображение, логик фикерләү, гадәттәгечә үзләренең инициативаларын, иждади сәләтен, коммуникатив сыйфат, кулларның вак моторикасын<br>Тренировать умение понимать и использовать символы, сформировать представление о том, как обозначить отрицание «не» с помощью за-черкивания (на примере отсутствия у предмета некоторого свойства – не красный, не прямоугольник и др.);<br>Повторить счет до 8, форму плоских геометрических фигур (треуголь-ник, квадрат, прямоугольник),пространственные отношения «вверху» – «внизу», «слева» - «справа»;<br>Сформировать опыт самостоятельного преодоления затруднения под руководством воспитателя на основе рефлективного метода, опыт са-моконтроля, закрепить способ действий «если что-то не знаю ,придумаю сам ,а потом проверю себя по учебнику»;<br>Тренировать мыслительные операций - анализ, синтез, сравнение и обобщение, развивать внимание, память, речь, воображение, логиче-ское и вариативное мышление, творческие способности, инициатив-ность, мелкую моторику рук. | Часть 3 стр.33 |
| 5 | Таблицы-лар.<br><br>Таблицы | таблица, строка һәм столб турында формалаштырырга тәкъдим итү счет сәләтен күнектерергә.Файдаланырга пространства мөнәсәбәтләре белән "сулда",-"уңнан", "өстә"-"аста". Счетн сәләтен кунектерергә. ". Балаларда тәрбияче житәкчелегендә<br>кыенлыклары мөстәкыйль жиңеп чыгу тәжрибәсе формалаштырырга . Үстерергә игътибарлык, хәтер, сөйләм, воображение, логик фикерләү, гадәттәгечә үзләренең инициативаларын, иждади сәләтен, коммуникатив сыйфат, кулларның вак моторикасын<br><br>Сформировать представления о таблице, строке и столбце, первичный опыт определения и выражения в речи места фигуры в таблице;<br>Тренировать счетные умения, умения определять и называть форму, цвет и размер плоских геометрических фигур, пользоваться простран-ственными отношениями «слева»,-«справа», «вверху»-«внизу»; Сфор- | Часть 3 стр.39 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | мировать опыт самостоятельного преодоления затруднения под руководством воспитателя на основе рефлексивного метода, опыт самоконтроля ,закрепить способ действий «если что-то не знаю, придумаю сам, а потом проверю себя по учебнику»;Тренировать мыслительного операции- анализ, сравнение, обобщение, классификацию, синтез, развивать внимание, память, речь, воображение, логическое мышление, творческие и коммуникативные способности, инициативность. | |
| 6 | 9 саны.<br><br>Число 9.<br>Цифра 9 | 9 саны белән танышу,тәртиб исәбе белән 9 кадәр.9 саны белән исәп белү формалаштырырга.Сан белән санда предметларны туры китерүдә актуаләштерү,санлы рәд төзү белү. Геметрик фигурларның формаларын кабатлау.Балаларда тәрбияче җитәкчелегендә кыенлыклары мөстәкыйль җиңеп чыгу тәҗрибәсе формалаштырырга Үстерергә игътибарлык, хәтер, сөйләм, воображение, логик фикерләү, гадәттәгечә үзләренең инициативаларын, иҗади сәләтен, коммуникатив сыйфат, кулларның вак моторикасын<br><br>Познакомить с цифрой 9,порядковым счетом до 9 ,сформировать умение соотносить цифру 9с количеством; сформировать опыт самостоятельного преодоления затруднения под руководством воспитателя на основе рефлексивного метода, опыт самоконтроля, закрепить способ действий «если что- не знаю, придумаю сам, а потом проверю себя по учебнику» ; тренировать умение сравнивать численность двух групп предметов путем пересчета и составления па, различать изученные геометрические фигуры, умение ориентироваться в пространстве относительно себя; тренировать мыслительные операций – анализ, сравнение, обобщение ,абстрагирование, развивать, внимание, память, речь, воображение, логическое мышление, творческие способности ,инициативность. | Часть 3 стр. 44 |
| 7 | 0 саны.<br><br>Число 0.<br>Цифра 0 | 0 саны белән танышу,0саны һәм исәбе белән таныштырырга. Сан белән санда предметларны туры китерүдә актуаләштерү,санлы рәд төзү белү.Вәзгыять булмаган предметлар саны 0 белү формалаштырырга. Геметрик фигурларның формаларын кабатлау.Балаларда тәрбияче җитәкчелегендә кыенлыклары мөстәкыйль җиңеп чыгу тәҗрибәсе формалаштырырга . Үстерергә игътибарлык, хәтер, сөйләм, воображение, логик фикерләү, гадәттәгечә үзләренең инициативаларын, иҗади сәләтен, коммуникатив сыйфат, кулларның вак моторикасын<br><br>Сформировать представление о числе 0,познокомить с цифрой 0 сформировать умение соотносить цифру 0 с ситуацией отсутствия предметов; сформировать опыт самостоятельного преодоления затруднения под руководством воспитателя на основе рефлексивного метода , опыт самоконтроля, закрепить способ действий «если что - не знаю ,придумаю сам, а потом проверю себя по учебнику»; тренировать умение узнавать и называть геометрические тела, умение считать до 9 и соотносить цифры 1-9 с количеством;<br>Тренировать мыслительные операции – анализ, сравнение, обобщение, абстрагирование, классификацию, развивать внимание, память, речь, воображение, логическое мышление, творческие способности, инициативность. | Часть 3 стр.49 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 8 | 10 саны.<br><br>Число 10. Запись числа 10 | 10 кадәр санарга белү формалаштырырга,10 санын язуда аера белү һәм аның белән эшчәнлеге юнәлешләрен туры китерү.Туры һәм кире санау 10 кадәр.Санлы рәд төзү белү. Балаларда тәрбияче җитәкчелегендә кыенлыклары мөстәкыйль җиңеп чыгу тәҗрибәсе формалаштырырга . Үстерергә игътибарлык, хәтер, сөйләм, воображение, логик фикерләү, гадәттәгечә үзләренең инициативаларын, иҗади сәләтен, коммуникатив сыйфат, кулларның вак моторикасын<br><br>Сформировать умение считать до 10 ,различать запись числа 10 и соотносить ее с деятельностью предметами; сформировать опыт самостоятельного преодоления затруднения по руководством воспитателя на основе рефлексивного метода, опыт самоконтроля ,закрепить способ действий «если что - не знаю ,посмотрю в учебнике»; тренировать умение сравнивать количество путем путём пересчета и путем составления пар, соотносить цифры1-9 с количеством ,прямой и обратный счет до 10 ,умение составлять числовой ряд; тренировать мыслительные операции- анализ, сравнение, обобщение ,абстрагирование ,развивать внимание ,память, речь, фантазию, воображение ,логическое мышление ,творческие способности, инициативность, мелкую моторику рук. | Часть 3 стр.54 |
| 9 | Предметлар ны чагыштыру “= “билгесе.<br><br>Сравнение групп предметов. Знак = | Бер төрле предметларны чагыштыру,= билгесе белән таныштыру, предметларны бер –берсенә куеп тигезлекләрен һәм аермасын белү,10га кадәр саннарны кабатлау, күз үлчәме, сөйләм үсешен, чагыштыру, анализ фикерләүне арттыру.<br><br>Сформировать представление о равных группах предметов ,умение устанавливать их равенство путем составления идентичных пар, познакомить со знаком =; сформировать опыт самостоятельного преодоления затруднения под руководством воспитателя на основе рефлексивного метода, опыт самоконтроля, закрепить способ действий «если что-то не знаю, придумаю сам, а потом проверяю себя по учебнику»; тренировать умение выделять и называть свойства предметов ,умение сравнивать предметы по длине путем наложения и приложения, закрепить счет до 10 ,умение соотносить запись чисел с количеством; тренировать мыслительные операции: анализ, сравнение обобщение, абстрагирование ,развивать внимание .память, речь, воображение, логическое и вариативное мышление ,творческие способности ,инициативность, мелкую моторику рук. | Часть 3 стр.59 |
| 10 | Предметлар ны чагыштыру =һәм =/билгеләре. Сравнение групп предметов. Знаки = и ≠ | Тигез һәм тигез булмаган предметларны чагыштыру, аларны тигезлек һәм тигезсезлек билгеләре аша билгеләү. Предметларны аера белү, охшашлыкларын табу, предметларны биеклек буенча билгеләү,10 га кадәр саннарны искә төшерү,уйлау сәләтен үстерү.<br><br>сформировать представление о равных и неравных группах предметов, умение устанавливать равенство и неравенство групп предметов путем составления идентичных пари фиксировать результат сравнения с помощью знаков = и ≠.сформировать опыт самостоятельного преодоления затруднения под руководством воспитателя на основе рефлексивного метода, опыт самоконтроля, закрепить способ действий «если что-то не знаю, придумаю сам , а потом проверю себя по учебнику»; тренировать умением выделять и называть свойства предметов, умение сравнивать предметы по высоте, закрепить счет в пределах 10 | Часть 3 стр.65 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | ;тренировать мыслительные операции - анализ ,сравнение, обобщение, абстрагирование, развивать внимание, память, речь, воображение, логическую и вариативное мышление, самостоятельность, инициативность, мелкую моторику рук, творческие способности. | |
| **Кисеп ябыштыру.<br>Тема: «Җиләк-җимешләрдән ризык”** | Түгәрәк һәм озынча формада кисә белүне ныгыту. Кузалладан чыгып кисәргә өйрәнүне ныгыту. Чиста итеп ябыштыру, бергәләп эшләүне формалаштыру. | Т. С. Комарова,. 43бит. |
| **Октябрь.** | | |
| **Рәсем.<br>Тема: «Яңгыр ява».** | Әйләнә-тирәдәге күренешләрне рәсемдә күрсәтә белү. Рәсемнең композициясен төзү. Гади һәм төсле карандашлар белән ршсем ясау. | Т. С. Комарова, 43 бит. |
| **Әвәләү.<br>Тема: «Яфраклар бии-бии агачка әйләнәләр”** | Әвәләү картиналары ясау теләге уяту. Рельефлы әвәләү белән таныштыру. Төс һәм композицияне тоя белү. | И. А. Лыкова, 46 бит |
| **Кисеп ябыштыру<br>Тема: «Тәрәзәдәге яфраклар».** | Төркемне бизәү өчен киселгән яфракларны бергәләп композицич төзеп ябыштыру, карандашлар белән буяу. Бергә дус-тату эшләү. | И. А. Лыкова, 48 бит. |
| **Рәсем<br>Тема: «Көзге яфрак-лар»** | Балаларны чын яфрактан карап ясарга өйрәтү.Төрле төсләр алу өчен төсләрне кушарга өйрәнү. Үзләренең теләкләрен искә алып рәсем ясау. | И. А. Лыкова, 50 бит |
| **Әвәләү.<br>Тема:”Атлар”.** | Халык уенчыклары үрнәгендә әвәләүне дәвам итү, сузып , бөгеп пычак белән кисәргә өйрәтүне дәвам итү, тоякны икегә кисәргә өйрәтү. Пөхтәлек тәрбияләү. | Т. С. Комарова, 46 бит |
| **Рәсем<br>Тема: «Дымка уенчыклары»** | Дымка уенчыкларының тбизәкләрен ныгыту, декоратив-гамәли сәнгать предметларының бизәкләрендәге үзенчәлекле элементлары белән таныштырү. Матурлыкны күрә белү. | Т. С. Комарова, 47 бит И. А. Лыкова, 62 бит |
| **Кисеп ябыштыру.<br>Тема: «Алтын каен-нар».** | Лирик әсәр аша алтын каен агачы ясарга кызыксыну уяту. Алтын яфракларны һәм ак кәүсәсен ясаганда характерлы үзенчәлекләренә игътибар итү. Төс һәм композицияне тоя белү. | И. А. Лыкова, 68 бит |
| **рәсем.<br>Тема: «Матур күлмәкле кыз».** | Кеше фигурасын ясарга өйрәнү: Күлмәк формасын бирә белү, гәүдә төзелешенә игътибар итү. Бөтен битне тутырып рәсем ясаарга өйрәнү. Рәсемне карандаш белән буяуны ныгыту. Балаларга бер-берсенең рәсемнәрен чагыштыра белүне булдыру. Мактый белү. | Т. С. Комарова, 48 бит |
| **Ноябрь.** | | |

| | | |
|---|---|---|
| **Рәсем.**<br>**Тема:”Бизәк-ле ат. Әвәләү** | Декоратив рәсемне нокта һәм туры линия белән бизәргә өйрәтү .Кисточканың очы б-н,калын кисточка б-н эш итә белү.Халык сәнгатенә мәхәббәт уяту. | Лыкова , 62бит. |
| **Тема:”Яңгыр- да кем чыланган?”** | Хайван фигураларын хәрәкәттә әвәләргә өйрәтү,үзлектән әвәләргә өйрәнү,сузу,бөгү.<br>Тырмау ысулларын куллана белү. Пөхтә итеп эәләү. | .И. А. Лыкова, 52 бит |
| **Рәсем.**<br>**Тема” Хохлама элементлары б-н рәсем ясау”** | Декоратив гамәли сәнгатьәсәрләре белән таныштыруны дәвам итү. Үсемлек элемнтларын таныргa өйрәнү,кисточканың очы б-н эшләргә өйрәнүне дәвам итү., гамәли сәнгатькә соклану тәрбияләү. | И. А. Лыкова 66 бит |
| **Ябыштыру**<br>**Тема: Куян-куркак һәм батыр**<br><br>**Рәсем**<br>**Тема:Чигүле тукыма**<br><br>**Әвәләү**<br><br>**Тема**:<br>**Йонлач ,каурыйлы, энәле.** | Әдәби геройларның кәефләренә, үз-үзен тотышларына карап рәсемдә төшереп китап ясау, матур әдәбияткә мәхәббәт тудыру, чиста-пөхтә эшләү.<br><br>**Б**алаларны төрле узорлар ясап бөтен битне тутырып рәсем ясарга өйрәтү, фонга карап төсне таба белү, кисточканы дөрес итеп тоту элементларын искә төшерү.<br><br>Хайваннарның, кошларның тән атөзелешендәге охшашлыклары һәм аермалыкларын күрә белү һәм шуны ясарга өйрәнү. Батынкы рельеф белән бизәү күнекмәләрен үстерү. | И. А. Лыкова 72 бит<br><br>И. А .Лыкова84 бит<br><br>И. А. Лыкова 70 бит |
| | | |
| **Рәсем.**<br>**Тема:**<br>**«Мыеклы-буйлы»** | Рәсемдә песи образын бирү.Кисточка һәм краска беләнхайваннарны ясый белүне ныгыту.Ясалган рәсемгә шатлана белү. Рәсемнең төрлелеген күрә белү. | Т. С. Комаро-ва,. 70бит |
| **Ябыштыру**<br>**Тема:**<br>**«Төсле зонтиклар»** | Табигать күренешләрен ясаганда ябыштыру композици-ясен булдырырга өйрәтү. Рәсем ясау алымнарын ныгыту:зонтикның йомры өлешен ясаганда дөрес итеп кисәргә өйрәтү, кырларын матурлап очлы итеп кисү . | И. А. Лыкова, стр. 54, заня-тие № 20. |
| **Декабрь.** | | |
| **Рәсем.**<br>**Тема: « Агач кунага городец рәсеме төшерү».** | Городец рәсеме шаблоннарын ясарга өйрәтү. Рәсемнең декоратив элементларын аера белү.Төс, ритм, композицияне үстерү. | Т. С. Комарова. 65бит,. |
| **Әвәләү.**<br>**Тема: «Тун кигән кыз».** | Балаларны кеше гәүдәсе, киемен дөрес пропорцияләрдә бирергә өйрәтү, Бер-берсенә | Т. С. Комарова, 67 бит. |

| | | |
|---|---|---|
| | тоташтыра белүне ныгыту, үзеңнең ясаган әйбереңне билгели белү. | |
| **Рәсем.**<br>**Тема: «Зур һәм кечкенә наратлар»** | Киң юлга урнаштыра белү, яшь һәм карт агачларны төсенә, биеклегенә , билгеләренә карап чагыштыра белү, матурлыкка омтылу. | Т.С.Комарова, 63бит,. |
| **Ябыштыру**<br>**Тема: «Зур һәм кечкенә бокал».** | Икегә бөкләнгән кәгазне симметрия буенча кисәргә өйрәтү .Чиста итеп ябыштыруны ныгыту. Ясалган бокалны бизәү теләге уяту. | Т. С. Комарова. 65бит,. |
| **Рәсем.Тема: «Тылсымлы кар бөртекләре**.” | Симметрик рәвештә нурларны җибәреп түгәрәк бизәкне үзәктән төзергә өйрәтү, бизәк ясаганда түгәрәк, туры формалар куллану, кисточкадан оста файдалану. | И. А. Лыкова, 9 бит |
| **Әвәләү**<br>**Тема: «Яңгыраучан лаләләр».** | Тозлы камырдан зур кул эшләре ясарга өйрәнү, шардан лалә чәчәген формалаштырып һәм басу техникасы белән ясауны ныгыту.чиста эәләүне ныгыту. | И. А. Лыкова, 104 бит. |
| **Ирекле рәсем.**<br>**Тема: «Яңа ел бәйрәмен көткәндә»** | Рәсемнең эчтәлеген сайларга өйрәтү, рәсем битенең , карандашның, красканың төсен сайлау. Кызыклы рәсем сайлап алу һәм бу рәсемне ник сайлап алганлыгыңны аңлату. | Т. С. Комарова,. 66бит, |
| **Ябыштыру ирекле рәвештә**<br>**Тема: «Яңа ел белән котлау открыткасы».** | Максат:бәйрәмгә багышланган открыткаларны эчтәлегенә туры килерлек итеп сайларга өйрәтү.Бөкләнгән гәгазне тигез итеп кисә белү. Кисә белүне һәм ябыштыруны ныгыту<br>. | Т. С. Комарова, 68 бит<br>И. А. Лыкова, 102 бит |

**Гыйнвар. 3 нче атна**

| **Эшчәнлек төре. Шөгыльнең темасы, №** | **Программа эчтәлеге** | **Методик алымнар** | **Материаллар** |
|---|---|---|---|
| **57. Күмер белән рәсем ясау: «Кышкы экият».** | • Балаларны күмер белән рәсем ясау техникасы, аның сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыру.<br>• Рәсем сюжетын һәм аны ничек сурәтләүне балаларның үзләреннән уйлатып, аларның иҗади омтылышларын көчәйтү.<br>• Сурәтләү эшчәнлегендә | Яңа сурәтләү материалының мөмкинлекләрен (штрихлау, күләгәләү, контурлар сызу яки күләмне җиткерү) күрсәтеп, аның белән кызыксыну уяту. Нәфис сүз аша шөгыль темасына нәфасәти мөнәсәбәт булдыру. Эш нәтиҗәләрен күреп соклану, аларга бергәләп бәя бирү. | А4 форматлы кәгазь бите, әзерләнгән күмер, салфеткалар. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | төрле материаллар кулланып, балаларның кызыксынуларын, белемнәрен арттыру. | | |
| **58. Әвәләп ясау: «Кунаклар көтәбез».** | • Пластилинны тасма рәвешендә сузып, чынаяк ясарга, аның формасын һәм төп өлешләре пропорциясен дөрес итеп җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Өслекне тигезләү, шомарту алымнарын ныгыту.<br>• Кунакчыллык тәрбияләү, тормышның билгеле бер ситуацияләрендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре һәм нормалары кысаларында эш итәргә күнектерү. | Кунакчыллык йоласы турында сөйләшү, тасма рәвешендә әвәләп ясау алымнарын күрсәтү, өслекне тигезләү, шомарту алымнарын искә төшерү. Әвәләп ясау барышында индивидуаль ярдәм, әзер эшләрнең иң яхшыларын аерым бәяләп үтү. | Пластилин яки балчык, әвәләп ясау өчен такталар, салфеткалар, сыгылмалы таякчык, мөһерләр (басып сурәт төшерү өчен). |
| **59. Рәсем ясау: «Кыш бабай һәм Кар кызы».** | • Кыш бабай һәм Кар кызының әкияти образларын рәсем аша җиткерергә өйрәтүне дәвам итү, предметларның зурлыклары буенча аермаларына, өлешләре пропорцияләренә игътибар юнәлтү.<br>• Фигураларның хәрәкәтләрен рәсемдә күрсәтү күнекмәсен ныгыту.<br>• Рәсемне тулыландырганда һәм шуның буенча хикәя төзегәндә, иҗади сәләтләр ачылуга этәрү. | Яңа елны бәйрәм итү, бәйрәмнең төп персонажлары турында сөйләшү. Кыш бабай, Кар кызы рәсемнәрен карау, аларның зурлыклары, гәүдә өлешләре пропорцияләре аермаларын табу. Фигуралар хәрәкәтләрен рәсемгә төшерү алымнарын өлешчә ясап күрсәтү. | А4 форматлы кәгазь бите, пумалалар, акварель буяулар, салфеткалар, сулы банка, Кыш бабай һәм Кар кызы рәсемнәре. |
| **60. Кору: «Кояшлы шәһәр» (күмәк эш).** | • Балаларны күмәк эшләргә, кайсы эшне кем башкарасын үзара килешеп, үз корылмаларын алдан ниятләнгәнчә берләштерергә өйрәтү.<br>• Үз корылмаларын ничек төзергә икәнлеген һәм аны планлаштыру этапларын анализ нигезендә табу күнекмәсен ныгыту.<br>• Язучы Н. Носовның «Белмәмеш Кояшлы | «Незнайка в Солнечном городе» мультфильмы өзекләрен карап, һәм аның турында фикер алышып, биремне дәлилләү корылмаларын күзәтеп, шул хакта әңгәмә оештыру, эш эзлекле л еген аңлату, һәр балага эш бирү. | Һәр балага кору материаллары җыелмасы яки «Лето» конструкторы, вак уенчыклар, Н. Носовның «Белмәмеш Кояшлы шәһәрдә» әсәренә иллюстрацияләр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | шәһәрдә» әсәренең өзекләрен укып фикер алышулар аша һәм күмәк хезмәт ярдәмендә балалар арасында дуслык мөнәсәбәтләре тәрбияләү. | | |
| **Гыйнвар. 4 нче атна** | | | |
| **61. Рәсем ясау: «Казлар-аккошлар».** | • Кошларның канат җилпеп очуларын киң буялыш аша җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Кошлар гәүдәсе өлешләренең пропорциональ чагыштырмаларын пумала белән төрлечә буял (пумала очы белән, пумаланы җәеп), рәсем аша җиткерә алу күнекмәсен ныгыту.<br>• А. Н. Толстой эшкәртүендәге «Казлар-аккошлар» («Гуси-лебеди») рус халык әкиятенә иллюстрацияләр ясау аша матур әдәбият белән кызыксынуны арттыру. | А. Н. Толстой эшкәртүендәге «Казлар-аккошлар» («Гуси-лебеди») рус халык әкиятенә ясалган иллюстрацияләрне карау, нәфис сүз куллану, кошларның канат җилпеп очуларын киң буялыш аша күрсәтү, балалар эшләренә анализ ясау. | А4 форматлы соры (зәңгәр) төстәге кәгазь бите, пумалалар, ак гуашь, салфеткалар, сулы банка, «Казлар-аккошлар» рус халык әкиятенә иллюстрацияләр. |
| **62. Кисеп ябыштыру: «Кар бөртек-ләре».** | • Үзәк аша берничә кат бөкләнгән кәгазьдән кар бөртекләре кисәргә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Квадрат кәгазь битенең якларын һәм почмакларын тәңгәл китереп, төрле юнәлештә пөхтә итеп бөкләү күнекмәсен ныгыту.<br>• Кар бөртекләре бизәкләрен үзләре күзаллаганча ясатып, балаларның фантазияләрен үстерү. | Кар бөртекләре ясалган рәсемнәрне, үрнәкләрне, схемаларны җентекләп карау, күрсәтеп аңлата бару. Индивидуаль ярдәм, кон-троль, бәяләү. | Кар бөртекләре рәсем-нәре, схемалар, үрнәкләр, һәр бала өчен квадрат кәгазь битләре (өчәр). |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **63. Рәсем ясау: «Кыш-лаучы кошлар».** | • Гади карандаш белән сызгалап рәсем төшерергә, туган ягыбызда кышлаган кошларга (карабүрекләр, песнәкләр, чыпчыклар, саесканнар) хас үзенчәлекле билгеләрне (каурыйлары, зурлыклары, гәүдә әгъзалары пропорцияләрен) рәсем аша Іҗиткерә белергә өйрәтү.<br>• Кошлар хәрәкәтләрен рәсем аша җиткерү күнекмәсен ныгыту.<br>• Туган як табигатен, тереклек дөньясын күзәтүчәнлекне үстерү. Кошларга, аеруча кыш айларында, кайгыртучан мөнәсәбәт тәрбияләү. | Карабүрек, песнәк, чыпчык, саескан сурәтләнгән иллюстрацияләрне җентекләп карау. Кошларны сурәтләү тәртибен күрсәтү (кошларның иң зур гәүдә әгъзаларыннан башлап гади каран-даш белән сызгалап рәсем ясау). Кирәкле төсмерләрне китереп чыгару өчен, буяулар тактасында төсләрне кушу. Инди-видуаль ярдәм. Ясалган кош турында хикәя төзеп анализ ясау. | А4 форматлы кәгазь бите, пумалалар, сулы банка, буяулар тактасы, кошлар рәсемнәре. |
| **Февраль. 1 нче атна** | | | |
| **64. Рәсем ясау: «Барыня».** | • Балаларны рус халкының декоратив-гамәли сәнгате белән таныштыруны дәвам итү. Дымково барынясына бизәк төшерү кагыйдәләре белән таныштыру, бердәй нокталар ясау өчен, бөтереп ишелгән кәгазь белән басарга өйрәнү.<br>• Пумала белән төрле | Дымково барыняларының (су ташучы, бала караучы, купшыбикә) итәк бизәкләре вариантларын, кокошнигы һәм итәге, төсләре ярашуын күзәтү-өйрәнү. Нәфис сүз куллану, бөтерелгән кәгазь белән басып рәсем төшерү алымын күрсәтү, киң һәм нечкә пумаланы эштә куллану. | Барынялар силуэтлары, пумалалар, акварель буяулар, салфеткалар, сулы банка, палитра, иллюстрацияләр, Дымково барынялары бизәкләре схемасы. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | юнәлешләрдә буяу күнекмә-сен ныгыту, төрле зурлыктагы пумалалар куллану осталыгын камилләштерү.<br>• Үзләре ясаган уенчыкларны караганда, балаларның нәфасәти кабул итүләрен үстерү. | | |
| **65. Әвәләп ясау: «Федора кайгы-сы».** | • Балаларны балчык яки пластилинны тасма рәвешендә сузып, шуннан савытлар әвәләп ясарга өйрәтүне дәвам итү, шул эштә савыт өлешләренең пропорциональ чагы-штырмасын күрсәтә белүләренә, детальләрне ялгап һәм сылап, өслекләрен шомартып эшләүләренә ирешү.<br>• Әвәләп ясауда кулай алымнарны сайлый белүләрен ныгыту, уйланган эшне ахы-рына җиткерүләренә ирешү.<br>• Кеше хәленә керә белү һәм рәхимлелек, әйберләргә сак мөнәсәбәт тәрбияләү. | К. И. Чуковскийның «Федорино горе» әкияте, башка шигырьләр һәм әкиятләрдән өзекләр уку, аларга ясалган иллюстрацияләрне карау, әвәләп ясау ысулларын күрсәтү. Ба-ларның мөстәкыйль эшләүләре. | Балчык яки пластилин, әвәләп ясау такталары, уенчык савыт-саба, салфеткалар. |
| **66. Алдан уйлап, рәсем ясау: «Зоопаркта нәрсә бар?»** | • Хайваннарның гәүдә формаларын, әгъзалары пропорцияләре чагыштырмасын үзең күзаллаганча алдан уйлап рәсем аша җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Композиция төзү күнекмәләрен ныгыту, төрле | Шөгыль темасы турын-да әңгәмә кору. Жираф, фил, арыслан һ. б. хай-ваннар рәсемнәрен һәм уенчыкларын җентекләп карау. Аларны рәсемгә төшерү алымнары ту-рында фикер алышу. | Жираф, фил, арыслан һ. б. хай-ваннар рәсем-нәре һәм уенчыклар. А4 форматлы кәгазь бите, пумалалар, гуашь, салфет-калар, сулы банка. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | климат зоналары хайваннарын аера белүгә ирешү.<br>• Хайваннарны сурәтләгәндә, рәсемне тулыландырганда иҗади омтылышларны хуплау. | | |
| **67. Кәгазьдән кору: «Умыр-заялы кәззин».** | • Балаларны өлге буенча корырга (зур квадраттан 16 квадрат бөкләп куярга, бер рәт квадратны кисеп алып, өстән һәм астан кисеп ждгоәреп, ачык тартма ясарга) өйрәтү.<br>• Әзер эшләнмәне үзең күзаллаганча пластилиннан чәчәкләр ясап тулыландыру күнекмәсен ныгыту.<br>• Конструктив фикерләүне үстерү, өстәмә детальләрне сурәтләү ысулларын мөстә-кыйль уйлап табуга ирешү. | Балаларны шөгыль темасына җәлеп итү өчен, язучы С. Я. Маршакның «Двенадцать месяцев» әкияте сюжетын куллану. Үрнәк кәрзинне җентекләп карау, эшләү ысулла-рын күрсәтеп, конст-руктив күнекмәләр формалаштыру. | 20х20 см лы йомшак картон яки сыек тон-дагы тыгыз кәгазь, чәчәкләр ясау өчен пластилин, сабаклар өчен нәзек ботаклар яки теш чистарткыч, аскуйма, пумала, җилем, һәр балага салфеткалар. |
| **Февраль. 2 нче атна** | | | |
| **68. Рәсем ясау: «Э безнең тәрәзәбез-дән Кызыл мәйдан кү-ренә...»** | • Балаларның композицион күнекмәләрен үстерү, сурәтләрне киң яссылыкта урнаштырырга, предметла-рның кайда урнашуларына карап (алгы, урта, арткы планда), аларның күләмнәре аермасын рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтү.<br>• Ясарга ниятләгәнне сюжет аша җиткерә белү күнекмәләрен ныгыту. • Үз | Шөгыль темасына якын килү макса-ты-нда, С. Михалковның «А что у вас?» шигыре өзеклә-рен уку. Бала-ларның нәрсә ясарга ниятләүләре турында, сюжет сызыгын җентекле тасвирлап, әңгәмә оештыру. Пред-метларның кайда урнашуларына ка-рап (алгы, урта, арткы планда), күләмнәре аермасын рәсем аша күрсәтү кагыйдәләрен үтәүләренә анализ ясау. | Төсле карандашлар (акбурлар, флома-стерлар), альбом би-те, сюжетлы иллю-страцияләр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | шәһәрләренә (авыл яки салаларына) карата мәхәббәт һәм горурлык хисләре тәрбияләү. | | |
| **69. Кисеп ябыштыру: «Күңелле әйлән-бәйлән».** | • Гармун күрегедәй итеп берничә кат бөк-ләнгән кәгазьне кисү алымын өйрәтү.<br>• Материалларга сакчыл мөнәсәбәт тәр-бияләү.<br>• Эшләнмәне өстәмә детальләр белән ту-лыландыруда мөстәкыйльлекне үстерү. | Әйлән-бәйлән иллюстрацияләрен карау, үрнәкне күзәтү, тулысынча аңлатып эшләп күрсәтү, һәр балага ярдәм итү. Контроль, балаларның дөрес эшләүләрен бәяләү һәм иҗади омтылышларын хуплау. | Әйлән-бәйлән иллю-страцияләре, буйга урталай бүленгән А4 форматлы кәгазь би-те, җилем, җилем пу-малалары, һәр бала өчен клеёнка, төрле төстәге һәм фактура-дагы кәгазь кисәкләре салынган «иҗат тарт-масы». |
| **70. Рәсем ясау (кисеп ябыштыру элемент-лары белән): «Вален-тинка».** | • Хохлома бизәкләре һәм татар орнаменты үрнәкләренә карап, симметрияле форма-да бизәкләр төзергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Симметрияле итеп кисү (турыпочмаклы кәгазь битенең почмакларын һәм якларын тәңгәл китереп бөкләү, кискәндә бөкләү сызыгыннан тотып тору) күнекмәләрен ныгыту.<br>• Бизәкне формада урнаштыру ысулын сайлаганда, композицияне тоемлау хисен үстерү. | Йөрәк формасындагы открыткаларны, хохлома бизәкләре, татар орнаменты элементларын җентекләп күзәтү, бизәк элементларын урнаштыру вариантлары турында әңгәмә кору, төрле элементларны рәсемдә ясау алымнарын искә төшерү. | А4 форматлы кызыл, сары төстәге кәгазь битләре, гуашь, нечкә пумала, сулы банка, аскуйма, салфетка, кайчы, йөрәк формасындагы отк-рыткалар, хохлома бизәкләре һәм татар орнаменты элементлары. |
| **Февраль. 3 нче атна** | | | |
| **71. Рәсем ясау: «Кышкы урман» (тал төшерү, таякчык белән өрү).** | • Балаларны рәсем ясауның төрле техникалары (тап төшерү, таякчык белән өрү) белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Балаларның композиция төзү күнекмәләрен ныгыты-рга, сурәтләрне предметларның кайда урнашуларына карап | Кыш турында әңгәмә оештыру, иллюстрацияләр карау. Эш мате-риалларын күрсәтеп, балаларның агачлар ясаганда кәгазь битенә пумала белән тап төшереп, аны таякчык | А4 форматлы кәгазь бите, гуашь яки ак-варель, нечкә пумала, сулы банка, аскуйма, салфетка, коктейль таякчыгы, алда әйтеп үтелгән рәссамнар картиналарына иллю- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | (алда, уртада, арткы планда), аларның күләмнәре аермасын күрсәтеп урнаштырырга өйрәтү.<br>• Иҗади фантазияләрен, кызыксынучан-лыкларын, пөхтәлекләрен үстерү. | белән өрү алымын, алгы һәм арткы пландагы предметларны сурәтләү кагыйдәләрен искә | страцияләр. |
| **72. Әвәләп ясау: «Хәрби танклар».** | • Танк өлешләрен (корпус, түбәсе, тубы (пушкасы), пулеметы, командир люгы, тәгәрмәч чылбыры, тәгәрмәчләре) ныклап ялгап ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Предметның кайбер өлешләрен сыгылмалы таякчык белән ясау күнекмәсен формалаштыруны дәвам итү.<br>• Россия Хәрби көчләре турында күзаллауларны киңәйтү. | Язучы Н. Иванованың «Танкист» шигырен уку, танк өлешләрен ясау ысулларын бергәләп хәл итү. Әвәләп ясаганда өлешләрне ялгау, өслекне тигезләү, эшне сыгылмалы таякчык белән формалаштыру ысулларын өлешчә эшләп күрсәтү. | Пластилин, такта, салфетка, сыгылмалы таякчык. |
| **73. Рәсем ясау: «Китап бите кыстыргычы».** | • Балаларны Россия халыкларының деко-ратив-гамәли сәнгате үрнәкләре (Городец бизәге) белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Бизәкне озынча яссылыкта (полосада) урнаштыру күнекмәсен ныгыту.<br>• Халык осталары эшләнмәләрен күреп соклана белүне үстерергә, чәчәк бәйләмнәре төсләре, формалары ярашу гүзәллеген күрергә өйрәтү. Халык иҗатына карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү. | Балаларны Городец бизәкләре тө-шерелгән предметлар белән таныштыру. Шигырь сөйләп, шөгыль темасына якынайту. Городец бизәкләре төшерелгән иллюстрацияләр карау, эш алымнарын тулысынча эшләп күрсәтү. | Гуашь, сары төстәге А4 форматлы кәгазьнең яртысы, уртача һәм нечкә пумала, сал-феткалар, сулы банка, Городец бизәкләре тө-шерелгән иллюстра-цияләр һәм предмелар. |
| **74. Цилиндр рәвешенә китерелгән кәгазьдән кору: «Кыргый хайваннар».** | • Балаларны әзер өлге буенча эшләргә (турыпочмаклы тыгыз кәгазьне цилиндр рәвешендә) төрергә һәм ябыш-тырырга, детальләрдән җәнлек сынын төзергә өйрәтергә.<br>• Формаларны салмак кисеп ясауга кү-нектерү.<br>• Образлы фикерләүне үстерү. | Нәфис сүз куллану. Үрнәк уенчыкларны җентекләп карау, формаларын ачыклау, аларның ясалу ысулын хәл итү. Эшләп күрсәтү, балаларга ярдәм итү, хуплау. | Үрнәк уенчыклар, уен-чык өлгесе ясалган А4 форматлы кәгазь бите, кәгазь әзерләмәләр, җилем, җилем пума-ласы, һәр балага салфеткалар. |
| | **Февраль. 4 нче атна** | | |
| **75. Рәсем ясау: « Куәтле армиябез».** | • Балаларны махсус транспорт өлешләренең чагыш-тырмача зурлыкларын һәм пропорцияләре чагыштыр-маларын рәсемдә күрсәтеп тасвирларга өйрәтү.<br>• Сайлап алынган техника | Нәфис сүз куллану, хәрби темага уенчыклар, иллюстрацияләр күрсәтү, аларны бергәләп карау, биремне мөстәкыйль үтәү. Индивиду-аль ярдәм. Эшләргә анализ | Төсле карандашлар, альбом бите, уенчыклар, хәрби техника рә-семнәре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | предметына мөстәкыйль анализ ясау күнекмәсен ныгыту.<br>• Россия армиясенә, Ватанны саклаучы хәрбиләргә хөрмәт хисе тәрбияләү. | ясау. | |
| **76. Кисеп ябыштыру: «Кораблар, пароход-лар».** | • Кораб өлешенең формасына карап, кисүнең төрле алымнарын кулланырга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Кайчы белән салмак кисү техникасын ныгыту.<br>• Сурәтне образлы бәяләүгә этәрү. Б. Заходерның «Если мне подарят лодку» шигыре белән таныштыру. | «В порту» мультфильмыннан өзек карау. Б. Заходерның «Если мне подарят лодку» шигырен уку аша шөгыль темасы белән кызыксыну уяту. Кораб төрләре, аларны хәрәкәткә китерү ысуллары турында әңгәмә кору. Җилкәнле кораб, пароход, катер һ. б. рәсемнәрен (зурлыклары, төсләре, өлеш-ләренең урнашуы) карау. Эшләү алымнарын бергәләп хәл итү. | Кораб рәсемнәре, кайчы, җилем, салфеткалар, А4 форматлы зәңгәр кәгазь бите, кораб корпусы өчен 15х6 см лы турыпочмаклы төрле төсләрдәге кәгазь, палубалар өчен 13х2, 11х2, 9х2 см лы төрле төсләрдәге турыпочмаклы кәгазьләр, җилкәннәр өчен 11х6, 7х4 см лы турыпочмаклы кәгазьләр, төрле төстәге һәм фактурадагы кәгазь кисәкләре салынган «иҗат тартмасы». |
| **77. Рәсем ясау: «Хохлома подносы».** | • Хохлома бизәкләре элементлары кулланып, түгәрәк кәгазь битендә сурәт ясарга өйрәтү, пумала белән ясауны (сабаклар, яфраклар, чәчәкләр) мамык таякчыклар белән баскалау (җиләкләр) ысуллары белән аралаштырьга эшләү.<br>• Гуашь, нәзек пумала белән эшләү күнекмәләрен, туган як үсемлекләре турындагы белемнәрне ныгыту.<br>• Нәфасәти кабул итүне үстерү. | Балалар тәҗрибәсен арттыруга юнәлтелгән сораулар бирү. Хохло-ма поднослары үрнәкләрен (бизәк урыны, элементлары, төсләр ярашуы) бергәләп карау-өйрәнү, сурәт-ләрнең аерым элементларын үзара яраштырып тоташтыру алымнарын аңлата барып, өлешчә ясап күрсәтү. | 10 см радиуслы кара төстәге түгәрәк тыгыз кәгазь, сары, кызыл һәм яшел төстәге гуашь, пумалалар, аскуйма, су, салфетка, мамык таякчык. |
| **Март. 1 нче атна** | | | |
| **78. Рәсем ясау: «Әниемә Городец такта-чыгы».** | • Агач тактага, формасына туры китереп, Городец бизәге төшерергә өйрәтү.<br>• Балаларның композиция ясау күнекмәләрен үстерүне дәвам итү һәм бизәкләрнең таныш элементларын мөстәкыйль куллануларына ирешү.<br>• Якыннарының күңелләрен күрү теләге уяту, аларга игътибар | Алда көтелгән бәйрәм (8 Март) турында әңгәмә үткәрү, Городец бизәкләре турында күзаллау тудыру өчен, шигырьләр уку, иллюстрацияләр карау, бизәкләрне аңлату; эш барышында ярдәм итү. | Эшкәртү тактасы, нечкә һәм уртача пумала, гуашь, салфеткалар, сулы банка, Городец бизәкләре элементларыннан гыйбарәт иллюстрацияләр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тәрбияләү. | | |
| **79. Әвәләп ясау: «Чынаяк кир-печ».** | • Халык иҗаты белән та-ныштыруны дәвам итү. Рус халык чынаяк кирпечләренә (кафель) охшатып, декора-тив пластиналар ясарга өйрәтү.<br>• Ниятләнгән эшкә туры килә торган әвәләп ясау алымнарын сайлап ала белү күнекмәсен ныгыту.<br>• Эш эчтәлеген сайлауда мөстәкыйльлекне үстерү. | Тәрбияче әңгәмә үткәреп, табышмаклар әйтеп, чынаяк кирпеч иллюстрацияләрен карап, ясалачак эшләнмә эчтәлегенә анализ ясый, үзе эшләп күрсәтә. | Балчык, тактачык, сулы савыт, пумала, салфетка, сыгылмалы таякчык, чынаяк кирпеч иллюстрацияләре» |
| **80. Рәсем ясау: «Песиле тал бота-гы».** | • Песиле тал ботагын нату-радан карап ясарга өйрәнү, рәсемдә аның урнашу үзенчәлекләрен күрсәтү, тиешле төсмерләр табу өчен төсләр кушу.<br>• Төрле калынлыктагы пумалаларны куллану күнекмәләрен ныгыту.<br>• Балаларның композиция ясау күнекмәләрен үстерү. | Иллюстрацияләр карау, песиле тал үрентеләрен ясаганда буяулар кушу, уртача һәм киң пумала белән ясау алымнарын тулысынча эшләп күрсәтү, нәфис сүз куллану, аңлата бару. | Гуашь, киң, уртача һәм нечкә пумалалар, сулы банка, салфетка, А4 форматлы кәгазь бите, вазага куелган песиле тал ботагы. |
| **81. Табигый материалдан кору: «Чәчәкләр белән бизәлгән рам».** | • Табигый материал кулланып бизәү элементлары белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Бизәк элементларын турыпочмак-лыкның почмакларына, ян-якларына, капмакаршы почмакларына урнаштыру күнекмәсен ныгыту.<br>• Мөстәкыйльлекне, иҗади күзаллау-ларны үстерү. | Фоторамалар һәм аларның бизәк-ләрен җентекләп карау, бизәү алымнарын күрсәтү, балалар ясаган үзенчәлекле эшләргә, аларның матурлыгына соклану, анализ ясау. | Орлыклар һәм каурыйлы орлыклар, төрле төстәге пластилиннар, фотографияләр өчен төсле картоннан кисел-гән рам. |
| **Март. 2 нче атна** | | | |
| **82. Рәсем ясау: «Март ишек төбендә».** | • Балаларны дымлы кәгазь битендә аква-рель буяулар кулланып рәсем ясау алы-мы белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Якын һәм ерак пландагы предметларны сурәтләү күнекмәсе формалаштыруны дәвам | Балалар бакчасы участогында табигатьне күзәтү, табигать күренешләре иллюстрацияләре карау: М. Х. Аладжалов. «Авылда яз»; Р. А. Берггольц. «Гатчинада җепшек көн»; И. И. Бродский. «Яз»; Ә. Мәҗитов. «Апрель»; Ю. А. Левицкий. «Умырзая- | Акварель буяулар, киң, уртача һәм нечкә пумалалар, сулы бан-ка, салфетка, А4 фор-матлы кәгазь, алда санап үтелгән рәссамнар картинала-рына иллюстраци-яләр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | итү.<br>• Алдан уйлап эшләү күнекмәсе булдыру өчен, табигатьтә ел фасылларының үзгәреп торуы турында күзаллау формалаштыру. | лар»; А. И. Куинджи. «Каен урманы»; И. С. Остроухов. «Иртә яз»; П. Сезанн. «Фон-тенбло урманында җепшек кар». Балаларның нәрсә ясар-га уйлаулары турында сөйләшеп алу, дымлы кәгазьдә акварель буяулар белән рәсем ясап күрсәтү. | |
| **83. Кисеп ябы-штыру: «Гөлләрем-чәчәкләрем».** | • Үзәк аша берничә кат бөкләнгән кәгазьдән чәчәкләр кисәргә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Чәчәк бәйләме ясап, композиция төзү күнекмәләрен ныгыту.<br>• Урта полосадагы үсемлекләр дөньясы белән таныштырып, нәфасәти кабул итүне үстерү. | Шөгыль темасына кызыксыну уяту өчен, шигырьләр уку, иллюстрацияләр карау, кисү алымнарын күрсәтү. Балалар ясаган эшләрне бергәләп ка-рау, бәя бирү. | Төрле зурлыктагы квадрат төсле кәгазьләр, җилем, пу-мала, клеенка, А4 форматлы ачык төстәге кәгазь бите, сабаклар һәм яфрак-лар ясау өчен флома-стерлар/карандашлар. |
| **84. Рәсем ясау: «Әнием портреты».** | • Балаларны портрет жан-ры белән таныштыру.<br>• Кеше йөзенә хас билгеләрне (формасы, төсе, күз уемы, чәч рәвеше) рәсем аша күрсәтә белергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Иң кадерле һәм иң якын кеше буларак анага карата мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү, балаларның аңа игътибарлы, ихтирамлы булуларына ирешү. | Ә. Мәҗитовның «Дымково уенчы-гын ясаучы Безденежных портреты», Ф.К. Винтерхаль-терның «Императрица Мария Александровна портре-ты»н, А. ван Дейкның «Карла I нең өч баласы» картиналарына иллюстра-цияләрне карау. Балаларга портрет ясау алымнарын күрсәтү, аңлату. Нәфис сүз куллану. | Акварель буяулар, киң, уртача һәм нечкә пумала, сулы банка, салфетка, А4, форматлы кәгазь, портретлар иллюстрацияләре. |
| **Март. 3 нче атна** | | | |
| **85. Рәсем ясау: В. Бианкиның «Куыш» әсәре буенча.** | • Балаларны төрле материалларның (күмер) сурәтләү мөмкинлекләре белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Корылмалар пропорцияләрен, хайваннарның үзенчәлекләрен рәсем аша җиткерә белү күнекмәләрен ныгыту.<br>• В. Бианкиның «Куыш» әкияте белән танышу аша балаларда хайваннар тормышына, аларның яшәү тирәлегенә, үзара мөнәсәбәтләренә кызыксыну уяту. | В. Бианкиның «Теремок» («Куыш») әкиятенә Е. Чарушин иллюстрацияләрен карау, сурәтләү ысулы, график материаллар турында сораулар бирү; корылмага, аның өлешләре пропорция-ләренә, хайваннар үзенчәлекләренә игътибар юнәлтү; күмер белән рәсем ясау алымнарын күрсәтү - күмер кисәгенә басу көчен көйләп, штрихлар сызарга һәм нокталар төртергә (күләмне, фактураны күрсәтергә өйрәтү). | Әзерләп куелган күмер, дымлы салфетка, А4 форматлы ачык төстәге кәгазь бите, В. Бианкиның «Куыш» әкиятенә Е. Чарушин ясаган иллюстрацияләр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **86. Әвәләп ясау: «Кувшин».** | • Балаларны савыт-саба ясауның әйләнмәле сылау кебек яңа ысулы белән таныштыру.<br>• Алдан уйлап куелган форманы ясау күнекмәсен ныгыту.<br>• Балаларның нәфасәти карашларын киңәйтү өчен, дөнья халыкларының балчык савыт-сабалары (керамика) белән таныштыру. | Татар, украин һ. б. халыкларның балчык кув-шиннары, тар муенлы чүлмәкләре һ. б. Керам-ик савыт-саба иллюстрацияләрен җентекләп карау, нинди материалдан ясалулары, аларны ясау ысуллары турында әңгәмә кору; савыт-саба ясауның әйләнмәле сылау ысулын күрсәтү; балаларның үз эшләнмәләре турында сөйләшү. | Балчык, такта, сулы савыт, пумала, салфетка, сыгылмалы таякчык, төрле ха-лыкларның керамик савытлары иллюстрацияләре. |
| **87. Рәсем ясау: «Тәүге чәчәкләр».** | • Рәсем ясаганда төрле сурәтләү материалларын (балавыз, акбурлар, аква-рель буяулар) куллана белү.<br>• Композиция ясау күнекмәләрен форма-лаштыруны дәвам итү.<br>• Балаларны туган якның тәүге чәчәкләре белән таныштыру. | Шөгыль темасына карата кызыксыну уяту өчен нәфис сүз куллану, иллюстрацияләр карау: Ю. А. Левицкий. «Умырзаялар»; О. Ренуар. «Яз чәчәкләре бәйләме»; кайбер чәчәк рәсемнәрен ясау ысулларын күрсәтү. | Балавыз акбурлар, ак-варель, пумала, салфетка, сулы савыт, пумала куйгыч, А4 форматлы кәгазь бите. |
| **88. Кәгазь-дән ко-ру: «Пара-шют».** | • Конус рәвешенә ките-релгән кәгазьдән күләмле уенчыклар ясарга өйрәтү.<br>• Эшләнмәне формасына карап бизәү кү некмәсен ныгыту.<br>• Балаларны уенда аралашуга этәрү. | Парашют ясалган иллюстрация-ләрне карау, әзер парашют үрнәген күзәтү, түгәрәк кәгазьдән бөтереп конус ясауны, тоташкан урыннарны ябыштыруны, парашют арканна-рын бәйләп яки ябыштырып кую-ны күрсәтеп аңлата бару. | Түгәрәкне бизәү кагый-дәләрен искә төшерү. Парашют сурәтләнгән рәсемнәр, радиус бу-енча кисү сызыгы ясалган түгәрәк, пара-шютны бизәү өчен әзерләмәләр. |
| **Март. 4 нче атна** | | | |
| **89. Рәсем ясау: «Нәүрүз».** | • Балаларны үзләре күзаллаган яз обра-зын рәсемдә күрсәтергә өйрәтү.<br>• Кеше сынын пропорциональ сурәтләү күнекмәсен ныгыту.<br>• Табигатьтә яз көне күзәтелгән үзгәрешне күреп соклана белергә өйрәтү. | Тәрбияче, яз турында әңгәмә үткә-реп, балаларны шөгыль темасы белән кызыксын-дыра. Язны каршылау - «Нәүрүз» бәйрәме турында сөйли, балаларның язны ничек күзаллауларын ачыклау өчен сораулар бирә. | А4 форматлы ак кәгазь бите, карандаш-лар, акбурлар, Ә. Мә-җитовның «Апрель» һәм И. Остроуховның «Иртә яз» картина-ларының иллюстрация-ләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **90. Кисеп ябыштыру: «Лаләлар».** | • Ике төстәге кәгазь алып, бер төсне икенчесе өстенә куеп, чәчәкләр кисәргә өйрәтү.<br>• Симметрияле кисү алымнарын (турыпочмаклы кәгазь битен урталай бөкләп, битне бөкләү сызыгы буенча тоткан килеш яртылаш кисү) ныгыту.<br>• Балаларның әйләнә-тирә дөньяны Нәфасәт и кабул итүләрен үстерү. | Якты һәм җылы яз чәчәге образы турында әңгәмә үткәреп, аның белән соклану хисләре уяту. Нәфис сүз куллану. Эш алымнарын күрсәтү. | Ачык яшел төстәге фон, кызыл һәм кара төсләрдәге 6х4 см лы өчәр турыпочмаклык. Ачык һәм караңгы яшел төстәге 11х4 см лы ике турыпочмак-лык. Сабак-лар өчен кәгазь тасма, җилем пумалалары, җилем, һәр балага салфеткалар. |
| **91. Рәсем ясау: «Әкияти гжель».** | • Балаларны рус халкының декоратив-гамәли сәнгате үрнәкләренең берсе - балчык савытларга гжель бизәге төшерү белән таныштыруны дәвам итү.<br>• Пумала белән төрле ысуллар кулланып эшләү күнекмәләрен ныгыту.<br>• Кәгазь тасмага гжель бизәге элементлары ясаганда, балаларның иҗади бизәү сәләтләрен формалаштыру. | Тәрбияченең гжель һөнәрчелеге турында сөйләве. Декоратив гамәли сәнгать предметларын һәм аерым элементлары схемаларын җентекләп карау, элементлар (чә-чәк бөресе, чәчәкләр, яфраклар) рәсемнәрен ясап күрсәтү. | А4 форматлы кәгазь битенең яртысы, ак-варель буяулар, төрле юанлыктагы пумала-лар, салфетка, аскуй-ма, су, декоратив-гамәли сәнгать предметларының һәм аерым элементлары схемасының иллюстрацияләре. |
| **Апрель. 1 нче атна** | | | |
| **92. Рәсем ясау: «Әкияти кош».** | • Гжель бизәкләренең яңа элементларын (кош һәм ат) ясау алымнары белән таныштыру.<br>• Предмет силуэтларын гжель чәчәк бәйләмнәре белән бизәү күнекмәсен ныгыту.<br>• Силуэтларны бизәүдә балаларның иҗади | Гжель һөнәрчелеге турында әңгәмә үткәрү. Гжель бизәкләренең яңа элементларын (кош һәм ат) ясау схемаларын карау, аларны ясап күрсәтү. Гжель чәчәк бәйләмнәрен, ат яки кошларны рәсемдә кайда урнаштыруны бергәләп | Чәйнек, тәлинкә силуэтлары, акварель буяулар, төрле юан-лыктагы пумалалар, салфеткалар, аскуйма, су, декоратив-гамәли сәнгать предметлар-ының һәм аерым элементларын ясау схемаларының иллюстрацияләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | активлыкларын, мөстәкыйльлекләрен үстерү. | хәл итү. | |
| **93. Әвәләп ясау: «Кре-пость» (күмәк эш).** | • Пластилиннан ясалган кирпечләрдән корырга, крепость сурәтен төзергә өй-рәтү.<br>• Үзара килешеп, күмәк эшләү күнекмә-сен ныгыту.<br>• Өстәмә предметларны әвәләп ясаганда, иҗади сәләтләрне үстерү. | Тәрбияченең крепостьның башка биналардан аермасы турында әңгәмә үткәрүе. Бергәләп иллюстрацияләр карау, кирпеч ясау ысулларын һәм крепостьны өю эзлеклелегенең (кирпечләрне нигездә бер рәткә тезеп һәм нигез өстенә стена күтәреп, стеналарда тәрәзә уемнары калдырып) бергәләп хәл итү. | Пластилин, әвәләп ясау так-талары, салфеткалар, сыгылмалы таякчык. |
| **94. Рәсем ясау: «Төзелеш»** | 1• Балаларга, транспортка хас үзенчәлекләрне (төзелгән катлар саны, кран, бульдозер кебек махсус машиналар) рәсемгә төшерергә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Алгы һәм ерак пландагы предметларны күрсәтеп, сюжет сурәтләү күнекмәсен ныгыту.<br>• Балаларны үз рәсемнәре турында сөйләүгә этәрү. | Иллюстрацияләр карау, якындагы төзелешкә экскурсия вакытында күргәннәр турында әңгәмә үткәрү. Төзелеш машиналарының өлеш-ләре, формалары, детальләре үзен-чәлекләрен табу, балалар эшчән-легенә бәя бирү. | А4 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар, иллю-страцияләр, уенчык маши-налар. |
| **95. Кору: «Коя-шлы шәһәр архи-тек-торлары».** | • Балаларда архитектор профессиясе турында күзаллау уяту. Үзләре ниятләгәнчә биналар ко-руда күнекмә бирү.<br>• Чынбарлыкта әлегә булмаган, ләкин киләчәктә төзеләчәк йортларны күз алдына китереп эшләүгә ирешү.<br>• Бинаны корганда сабырлык һәм пөхтәлек тәрбияләү. | Н. Носовның «Белмәмеш Кояшлы шәһәрдә» әсәренә ясалган иллюстрацияләрне бергәләп карап, игътибарны бирем эчтәлегенә юнәлтү. Әсәр эчтәлеге турында фикер алышу, уен ситуациясе тудыру. Гадәти булмаган йортлар иллюстрацияләрен карау, биналар кору кагыйдәләрен искә төшерү: бөтен өлешләренең дә булуы, бинаның төзелеше аның нинди максатларга хезмәт итүе белән бәйле булуын төшендерү. Балалар корган биналарга бергәләшеп бәя бирү. | Гадәти булмаган йортлар рәсемнәре, кору матери-аллары җыелмасы яки «Лего». |

| Апрель. 2 нче атна | | | |
|---|---|---|---|
| **96. Рәсем ясау: «Барлык професси-яләр мөһим».** | • Алдан уйлап куелганнар-ны рәсемдә җиткерә белер-гә, эшне эзлекле төстә алып барырга, предметларны кайда урнашуларына карап һәм зурлыклары буенча киң полосада ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Балаларның профессияләр турындагы белемнәрен ныгыту, кеше тормышында хезмәтнең әһәмиятенә төшендерү; төрле профессия вәкилләренә хөрмәт һәм уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.<br>• Балаларның, рәсемне үзләре теләгәнчә төрле детальләр белән тулыландыруларына ирешеп, алдан уйлап эшли белү сәләтләрен үстерү. | Хезмәт кораллары тутырылган «Сихри капчык» дидактик уены. С. Михалков-ның «А что у вас?» шигырен уку, Б. Ма-яковскийның «Кем быть?» шигырендәге профессияләрне искә төшерү, бу ши-гырьләргә ясалган иллюстрацияләрне карау, балаларның нәрсә ясарга ният-ләүләре турында сөйләшеп алу, эшчәнлекләренә бәя бирү. | А4 форматлы кәгазь бите, карандашлар, иллюстраци-яләр. |
| **97. Кисеп ябышты-ру: «Урман агач-лары».** | • Төп детальләрнең кисеп ясалган өлгеләре астына кәгазь куеп, астан яктыр-тып аппликацияләр ясарга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Кәгазьдән симметрияле итеп кисеп, әзер формаларны билгеле бер тәртиптә (башта ерак пландагы, аннары урта, соңыннан алгы пландагы предметлар) ябыштыру күнекмәсен кабатлау.<br>• Балаларның туган як үсемлекләре турындагы белемнәрен ныгыту. | Нәфис сүз куллану, иллюстрация-ләр карау, агачлар турында сөйләшү (охшаш һәм аермалы билгеләре), эшләп күрсәтү һәм аңлата бару, балаларның эшчәнлекләрен бәяләү, хуплау. | Төрле агач рәсемнәре, әзер үрнәкләр, каен һәм чыршы өчен әзерләмәләр (ак һәм көрән төстәге турыпочмаклыклар), җилем, пу-мала, салфетка, А4 форматлы яшькелт-зәңгәр төстәге кәгазь бите. |
| **98. Рәсем ясау: «Мас-карад».** | • Балаларны хәрәкәтле һәм театральләштерелгән уеннар өчен битлекләрне мөстәкыйль әзерләргә өйрәтү.<br>• Персонажның йөз-кыяфәтен җентекләп анализлау һәм рәсемдә күрсәтә белүләрен камилләштерү.<br>• Яңа төр эшчәнлек белән таныштыру аша балаларның иҗади | Маскарад турында, битлекләрне нәрсә өчен киюләре, аларны тагын кайда кулланулары, барлык бит-лекләрнең дә уртак билгеләре (ке-ше йөзен тулысынча яки өлешчә каплыйлар, күз турысында тишемнәре була) турында әңгә-мә кору. Хайван кыяфәтендәге битлекләрне бергәләп | Үзәгендә 15 см диа-метрлы түгәрәк сызылган һәм күзләр өчен тишем киселгән А4 форматлы кәгазь. ПВА лейлеме белән катнаштырылган гуашь, төрле зурлыктагы пумалалар, сулы банка, пумала өчен аскуйма, сал-фетка, битлек иллюстрацияләре. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | сәләтләрен үстерү. | карау, төп формага детальләрне ясап бетерү, «җавап тап» формасында анализ ясау. | |
| **Апрель. 3 нче атна** | | | |
| **99. Рәсем ясау: «Галәм».** | • Балаларны сурәтләү сәнгатенең пейзаж жанры һәм аның төрләре белән та-ныштыруны дәвам итү.<br>• Балаларда Галәм киңлекләре һәм күк җисемнәре турында күзаллау булдыру өчен, аларны бергәләп кәгазь битендә ясау.<br>• Безне чолгап алган дөнья киңлекләре белән кызыксыну тәрбияләү. | Галәм киңлекләре һәм күк җисемнәре, космонавт профессиясенең катлаулылыгы турында әңгәмә үткәрү, космонавт А. Леоновның «Галәм таңы» иллюстрацияләрен карау. | А4 форматлы куе зәңгәр яки кара төстәге кәгазь бите, гуашь, төрле зурлыктагы пумалалар, аскуйма, су, салфетка. |
| **100. Әвәләп ясау: «Кос-мо-навт» .** | • Балаларны ел саен билгеләп үтелә торган Космонавтика көне (12 апрель), космонавтлар хезмәте белән таны-штыруны дәвам итү, әлеге профессиягә хас үзенчәлекләрне әвәләп ясаганда күрсәтә белергә өйрәтү.<br>• Космонавт һәм ракетаны ясау ысулын мөстәкыйль сайлау күнекмәсен ныгыту, өлешләрне салмак кына ялгап, сылап һәм өслекләрен тигезләп, тиешле формага китерү.<br>• Дөньяның беренче космонавтын тәрбияләп үстергән туган илебез белән горурлык хисләре тәрбияләү. | Космонавтика көне, космонавт профессиясе авырлыклары турында әңгәмә корып, А. Леонов иллюстрацияләрен («Кеше планета өстендә») карап, космонавт про-фессиясенә хөрмәт уяту. Космонавт скафандры өлешләрен җентекләп күзәтеп, ал арның пропорциональ чагыштырмаларына игътибар итеп, балаларда әлеге форма турында күзаллау булдыру. Юнәлеш бирүче сораулар кулла-нып, балаларны мөстәкыйль эшләүгә этәрү. | Пластилин, әвәләп ясау өчен такталар, салфет-калар, сыгылмалы таякчык. |
| **101. Рәсем ясау: «Киләчәк машиналары».** | • Дөньяда булмаган гаҗәеп машиналар уйлап таптырып, аның төп өлешләрен (кузов, ишекләре, тәрәзәләре, | Гаҗәеп машиналар сурәтләнгән рәсемнәрне бергәләп карап, шөгыль темасына кызыксыну уяту, ул | А4 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар, гаҗәеп машиналар ясалган рәсемнәр. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | тәгәрмәчләре) рәсемгә төшереп, балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.<br>• Карандашлар белән пөхтә итеп буярга күнектерү.<br>• Үз рәсемең турында сөйләргә өйрәтү. | машиналарның төрле өлешләренең кайда урнашуларын карап өйрәнү, киләчәк машиналары турында сөйләшү, балаларның мөстәкыйль эшләү омтылышларын хуплау. | |
| **102. Кору: «Авто-парк».** | • Машиналарның вазифаларына бәйле рәвештә ясалган төп өлешләрен күрсәтеп, төрле машина-лар корырга өйрәтүне дәвам итү.<br>• Кору өчен кирәкле материалларны мөстәкыйль сайлау күнекмәсен үстерү.<br>• Коруның әлеге төре белән кызыксыну, уйлап чыгарып кору теләге уяту | Балаларда шөгыль темасы белән кызыксыну уяту, үзләре уйлап табып коруларына ирешү. Әлеге темага иллюстрацияләр карап, һәр балага ярдәм итеп, кору күнекмәләре формалаштыру. | Конструкторлар. |
| **Апрель. 4 нче атна** | | | |
| **103. Рәсем ясау: «Хуш исле чәчәкләр».** | • Натурадан карап, тирә-юнебездәге гүзәллекне (чәчәкле гөл) күрергә һәм рәсемдә шуны күрсәтә белергә өйрәтү.<br>• Ачык һәм караңгы төсмерләрне аера белү, төсләрне сыеклау һәм куерту күнек-мәләрен ныгыту.<br>• Табигать объектларын күзәтү аша әйләнә-тирә дөньяны нәфасәти кабул итәргә өйрәтү. | Чәчәкләре ачылган бүлмә гөлен күреп (әңгәмә үткәреп, карап-күзәтеп, нәфис сүз аша), соклану хисләре уяту. Биремне аңлату, гөлне күрсәтеп, аны сурәтләү ысулларын аңлату, тырышлыкларын хуплау. | А4 форматлы кәгазь бите, төрле юанлыктагы пумалалар, акварель буяулар, салфеткалар, чәчәк аткан бүлмә гөле. |
| **104. Кисеп ябыштыру: «Витамин әфлисуннар».** | • Үзәге аша берничә кат бөкләнгән бер төстәге кәгазьдән ур-талай бүленгән әфлисун кисеп алыр-га өйрәтү.<br>• Төп форма астына | Аппликация үрнәген карап, шул рәвештә кисеп ябыштыруны күрсәтеп аңлата бару, һәр балага ярдәм итеп, кисеп ябыштыру күнекмәләрен камилләштерү. | Сары һәм әфлисун төсләренең ачык һәм караңгы төсмерләрен-нән гыйбарәт 5 һәм 4 см диаметрлы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | шундый төсмерле кәгазь салып ябыштыру күнекмәсен ныгыту.<br>• Төрлечә кисеп ябыштыру ысуллары белән таныштырып, балаларның да әлеге күнекмәләрен үстерү. | | түгәрәк кәгазьләр, А4 форматлы кәгазь бите, җилем, җилем өчен пумалалар, салфетка-лар. |
| **105. Рәсем ясау: «Натюр-морт».** | • Балаларны сурәтләү сәнгате жанрлары белән (натюрморт) таны-штыруны дәвам итү.<br>• Җиләк-җимешләрне бергә туплап сурәтләргә өйрәтү.<br>• Балаларны үтенечләргә игътибарлы булырга, татар һәм рус телләрендәге таныш үтенеч сүзләрен кулланырга өйрәтү. | Биремне кунак үтенече аша аңлату. Тәрбияченең сурәтләү сәнгатенең натюрморт жанры турында сөйләве. И. Ф. Хруцкийның «Җимешләр һәм кавын», Э. Маненың «Җиләк-җимешләр кәрзине» натюрмортла-рын карау. | А4 форматлы кәгазь, төрле калынлыктагы пумалалар, акварель буяулар, салфеткалар, 3-4 җиләк-җимеш. |
| **Май. 1 нче атна** | | | |
| **106. Рәсем ясау: «Кремль».** | • Балаларны баш-калабызның архи-тек-турасы белән таныштыруны дәвам итү, Казан Кремленең тарихи биналарының, һәйкәлләренең рәсемен ясарга өйрәтү.<br>• Биналарга хас үзенчәлекләрне рәсемдә күрсәтә белү күнекмәсен формалаштыру.<br>• Туган шәһәребез, аның гүзәллеге һәм бөеклеге белән горурлану хисен үстерү. | Туган шәһәребезнең тарихын гәүдәләндерүче архитектура һәйкәлләре турында сөйләшү, шәһәр күренешләрен күрсәтүче видео, слайд һәм иллюстрацияләр карау, Казан Кремле биналарын күзәтү. Балалар ясаган рәсемнәрне фотографияләр белән чагыштырып анализ ясау. | А4 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар яки балавыз ак-бурлар. |
| **107. Әвә-ләп ясау: «Өй зоопаркы».** | • Балаларның җәнлекләрне әвәләп ясау ысулын мөстәкыйль сайлап | Уен ситуациясе, карау-күзәтү, эш алымнарын өлешчә күрсәтеп, аңла-тып бирү. Ты-рышлыкларын хуплау, инди-видуаль ярдәм. | Пластилин, әвәләп ясау такталары, салфеткалар, сыгылмалы таякчык. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | эшләү күнекмәсен ныгыту.<br>• Җәнлекләр фактурасын сыгылмалы таякчык белән яки өслекләрен тигезләп ясарга өйрәтү.<br>• Балаларның үз эшләре турында сөйләү-ләренә ирешү һәм җәнлекләр өчен җавап-лылык хисе тәрбияләү. | | |
| **108. Рәсем ясау: «Җиңү көне».** | • Әлеге тема белән бәйле предметлар-ны сурәтләп, Җиңү көне турындагы үз хис-кичерешләрен мөстәкыйль җиткерә белергә өйрәтү.<br>• Сурәтне бөтен битне тутырып яки киң полосада урнаштыру күнекмәсен ныгыту.<br>• Алда көтелгән 9 Май көненә карата балаларның игътибарын һәм ихтирамын көчәйтү. | Әлеге темага багышланган иллюстрацияләрне карау, көтелгән бөек бәйрәм турында сөйләшү, биремне аңлатканда шигырь уку, бала-лар ясаган эшләргә бәя бирү, күргәзмәләр оештыру. | A4 форматлы кәгазь бите, төсле карандашлар. |
| **109. Күзаллап кору: «Джек төзегән йорт».** | • Балаларны корылачак бина зурлыгы, өлешләре турында үзара килешеп, күмәк эшләргә өйрәтүне дәвам итү.<br>• Балаларны үзләре корасы бинаны гомуми конструк-ция белән үзара чагыштырып эшләргә күнектерү.<br>• С. Маршак тәрҗемә иткән «Джек төзегән йорт» дигән инглиз такмазасы белән таныштыру. | Уен ситуациясе тудыру - «Джек төзегән йорт» әсәренең барлык геройлары өчен йорт төзү турындагы үтенеч язылган хат килү. Инди-видуаль эш, контроль, бәяләү. | Төзү ма-териалла-ры җыел-масы яки һәр бала өчен «Ле-го» кон-структо-ры. |
| **Май. 2 нче атна** | | | |
| **110. Рәсем ясау: «Кызыл калфак».** | • Балаларны әдәби әсәргә иллюстрация ясарга өйрәтү. Ш. Перроның «Кызыл кал-фак» әкиятен укыгач туган тәэсирләрне рәсемдә күрсәтә белүгә ирешү.<br>• Төп геройларны аера белү, рәсем ясаганда аларны кәгазь битенең уртасына урнаштыру | Әкият эчтәлеге турында сөйләшү, үз әкият китабыңны әзерләргә тәкъдим итү, биремне аңлату, төп геройларны балавыз акбурлар белән ясап, | A4 фор-матлы кәгазь би-те, бала-выз ак-бурлар, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күнекмәсен үстерү.<br>• Эшләгәндә төрле материаллар кулланып, шөгыль темасына кызыксыну уяту. | акварель белән буяп күрсәтү, балаларны мөстәкыйль эшчәнлеккә этәрү өчен сораулар һәм юнәлеш бирүче җаваплар әйтү. Геройларның хәрәкәтләрен, позаларын бала-лар рәсемдә ничек күрсәтүгә анализ ясау. Өстәмә детальләр кертүләрен хуплау. | киң пума-ла, аква-рель буяулар, сулы бан-ка, иллю-страция-ләр. |
